PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2020 ФЕВРАЛЬ № 2

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

танышулар САЙТЫ

аралашу мәйданымы, табышумы

баланы... ҖИҢЕЛЕРГӘ ДӘ ӨЙРӘТӘБЕЗ

әни көндәлеге

ИСПАНИЯГӘ...

җәяү

мин ачкан дөнья

Фәридә ХӘЙРУЛЛИНА:

«Бездә тормышка мәхәббәт, яшәү теләге зуррак»



Хәтер – мәңгелек...

Бөек Җиңүгә миллионлаган гап-гади кешеләрнең каһарманлыгы бәрабәренә ирешә алдык. Алар арасында безнең татар егетләре, татар кызлары да байтак. Минем бабам, синеке, аныкы... Сугыш афәте кагылмаган, сугыш ишек шакымаган капка, гаилә калды микән? Җиңү таңы безгә шуңа да кадерле... Инде бу хакта бүгенге яшьләребезгә дә аңлатасы, төшендерәсе, күңелләрендә горурлык хисләре уятасы килә. Бу проект – шул хакта. Мондый ядкарьләр, бәлки, сезнең гаиләләрдә дә сакланадыр. Юк икән, аларны шушы сайттан табып алырга мөмкин: https://pamyat-naroda.ru. Бабаларыгызга орден-медальләр ни өчен бирелде икән? Балалар, оныклар белән бергә утырып эзләп карагыз әле. Әлеге тарихи документларны үз күзләре белән күргәч, Җиңү сүзенә алар инде берничек тә битараф калалмас... Табышларыгызны безнең белән дә уртаклашыгыз. Хатларыгызны көтәбез.

«Хәмит Котдусов. 1922 елда туган. 1942 елның мартында хәбәрсез югалган». Татарстанның «Хәтер китабы»нда аның турында нибары шушы бер җөмлә бар. Хәтта исеме дә «Хамат» дип язылган. Нидер сораштырырга авылда беркеме дә калмаган: алар гаиләсе 1934 елда йорт-җир, мал-мөлкәтләреннән мәхрүм ителгән – нәсел өзелгән.

Сугышта булган авылдашларны барлап яза башлаган китабымда аның турында шушы гына мәгълүматым бар иде. Нигәдер узган җәйдә Хәмит абыйның «Кутузов» дип эзләп карарга уйладым. Безнекеләрнең исем-фамилияләре документларда ничек кенә бозылып язылмаганын байтактан аңладым инде... «Память народа» сайтыннан шул фамилия белән эзлим. Бар! Таптым Хәмит Котдус улын! Ленинград, Берлин өчен барган сугышларда бик зур батырлыклар күрсәткән икән авылдашым. «Батырлык өчен медале», Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән. Өченче дәрәҗә Дан орденына тәкъдим ителгән булган. Бүләкләү кәгазендә Ной-Кэров өчен барган сугышларда каты яраланган взвод командирын алыштырып, взводны атакага күтәрүе хакында әйтелә. «Бу сугышта взвод 32 дошман солдатын һәм офицерын юк итте. Ул үзе 16 немец солдатын юкка чыгарып, 2 немец солдатын әсир итеп алды», – диелә. 1945 елның 18 апрелендә Хәмит Котдусовны ике тапкыр Кызыл Байрак орденлы һәм икенче дәрәҗә Суворов орденлы 313 нче укчы дивизия командиры полковник Асафьев Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләү турында боерык чыгара. «Память народа» сайты батыр авылдашыбызны билгесезлектән кайтарырга ярдәм итте. Өметне өзмәскә кирәк дип юкка гына әйтмиләр – хәбәрсез югалганнар да бер кайта!

Люция ШӘРӘФИЕВА.
Саба районы, Олы Кибәче авылы.

Все графы заполнять полностью

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество Кутузов Хамид
2. Звание Сержант 3. Должность и часть Командир отделения 1070 стрелкового полка 313 стрелковой Петрозаводской Краснознаменной дивизии 19 армии.

Представляется к Ордену Славы третьей степени

Год рождения 1923 5. Национальность татарин 6. Партийность Член ВКП(б)

7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне (где, когда) Карельский фронт с 20.05.42 г., 2-й Белорусский фронт с 20.02.45 г.

8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне не имеет

9. С какого времени в Красной Армии с 1942 года 10. Каким РВК призван Сабинским РВК Татарской АССР.

Чем ранее награжден (за какие отличия) Медаль „За отвагу" пр. 1070 сп № 030 от 26.04.44 г.

Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес

Полевая почта 08763-Щ

1. КРАТКОЕ, КОНКРЕТНОЕ ИЗЛОЖЕНИЕ ЛИЧНОГО БОЕВОГО ПОДВИГА ИЛИ ЗАСЛУГ

Ранее награжденного медалью „За отвагу" приказом по 1070 стрелковому полку № 030 от 26.04.44 года за истребление 9 финских солдат и вторично за то, что в боях за населенный пункт „Ной-Кэров" был тяжело ранен командир взвода, тов. Кутузов принял командование взводом на себя и повел его в атаку. Задача была выполнена в этом бою взвод истребил 32 немецких солдат и офицеров, сам лично из своего автомата уничтожил 16 немецких солдат и взял в плен 2 солдат немецкой армии.

Достоин награждения правительственной награды Орденом Славы третьей степени.

Командир 1070 стрелкового полка подполковник (Пильщиков)

Начальник штаба 1070 стрелкового полка майор (Зак)

Командир (начальник) (подпись)

14 апреля 1945 г.

VI. ОТМЕТКА О НАГРАЖДЕНИИ

Приказом частям 313 стрелковой Петрозаводской дважды Краснознаменной и орд. Суворова 2 ст. дивизии № 045 от 18 апреля 1945 г. награжден орденом Красной Звезды

22.4.45 г.

Начальник отделения кадров 313 СП ККС Д капитан /Орехов/

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019



Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Тышлыкта:
Фәридә Хәйруллина
Фото: Анна Арахамия

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова

Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина

Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Верстка:
Резеда Галиуллина

Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева

Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева

Фотокорреспондент
Анна Арахамия

Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 7.02.2020 ел.
Заказ А-287
Тираж 4054

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+

23 ФЕВРАЛЬ – ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ


Гөлзадә БӘЙРӘМОВА

* * *

Сәясәтне, әйдә, ирләр язсын,
Алар сүзе күпкә акыллы.
Акыл белән хис янәшә түгел,
Безнең йөрәк хисле-ялкынлы.

Сәясәтне, әйдә, ирләр язсын,
Алар китә сугыш кырына.
Безгә язган һаман сагынырга
Һәм янарга сагыш утында.

Сәясәтне, әйдә, ирләр язсын,
Без җырларбыз сөю турында.
...Илләр гаме – ирләр гаме булсын,
Ил тоткасы – ирләр кулында.





Саҗидә СӨЛӘЙМАНОВА

Ир-егеткә

Җир кызларын фәрештәдәй күргән,
садәлекне сөйгән ир-атлар,
кер кундырмый аны саклар өчен
сездә көч бар, сүнмәс гайрәт бар.

Гүзәллекне сез бик яратканга
дәвам итә безнең яшәү дә, –
яңа кеше белән өмет туа
киләчәкне күреп яшәргә.

Вакланмаучы, акланмаучы җаннар,
саклау, кадерләүгә сез лаек.
Никадәрле сездә ирлек булса,
шулкадәрле башсыз малайлык.

Абайламый агу биргән дә сез,
саранланмый ширбәт эчергән.
Шуңа да бит без, хатыннар, сезне
мең кат каргап, мең кат кичергән.

Сез ул – якты көндә ут уйнатып,
башын ташлап биючеләр дә,
афәт купса илдә, янгын чыкса,
башлап утка керүчеләр дә.

Үлемнәрдән өстен ир-егетләр,
сезнең белән көчле Ватаным.
Үзеннән дә алда киләчәккә
яхшы аты бара атаның.

Яшәп туймас гомер дәвамчысы,
һәрчак беренчеләр сафында,
кылычтан да үткен чор чатында
син торасың тормыш сагында.

Безнең тышлыкта



«Үз башыңнан кичермичә күп нәрсәне аңлап булмыйдыр. Тик бу бөтен кешегә дә сынаулар аша үтәргә дигән сүз түгел...»

10 Бер бәхет тарихы
Гөлнур Сафиуллина

Заман һәм без

6 Капкын
Чулпан Галиәхмәтова





16 Укытучы
Гөлнур Сафиуллина

20 «Ризасызлыгымны иҗатым аша җиткерәм»
Эльмира Закирова

24 «Үз көчеңә ышанырга кирәк!»
Раилә Хәялиева

Татар дөньясы



26 Эх, пошалым чанасы!
Лилия Гәрәева

Мәдәни тормыш



30 Минзәлә сандугачы
Әхтәм Зарипов

36 Тел белмәгәч
Мөхәммәт Мәһдиев



40 Туң йөрәк
Айгөл Хөснуллина

Яшәеш

46 «Табам, кочам, җибәрмим!»
Раилә Хәялиева



50 Син янымда булган чакта гына...
Раилә Хәялиева



52 Испаниягә... җәяү
Полина Трояновская

Хуҗабикә



60 «Кышкы чия» пирогы

Үсмерләр җинаятьне оешып кыла башлаган. Татарстан Эчке эшләр министрлыгының еллык эш нәтиҗәләренә багышланган коллегиядә министр Артем Хохорин 90 нчы елларга кайтмаячакбыз дип вәгъдә бирде бирүен. Тик әлегә статистика ышанып бетәргә ирек бирми. Балалар һәм үсмерләр катнашындагы җинаятьләр үсә. Узган елгы күрсәткеч элеккеләреннән 13 процентка арткан. Ә иң куркынычы – яшүсмерләрне туплаган җинаятьчел төркемнәр барлыкка килгән. Узган ел Чаллыны «Бельчата» төркеме дер селкетеп алды. Эчке эшләр министры шәһәрдә шундый сигез төркем барлыгын әйтте. Шундый ук җинаятьчел төркемнәр республиканың башка шәһәрләрендә дә бар, әйтик, Казанда, Түбән Камада, Алабугада, Әлмәттә, Яшел Үзәндә. «Аларның кайберләре үзләрен АУЕ формаль булмаган яшьләр хәрәкәтенә керүләрен белдерә», – ди министр. «Арестантский уклад един» дип аталган субкультура балигъ булмаганнар арасында криминаль дөнья һәм төрмә төшенчәләрен пропагандалый. Гади итеп әйткәндә, үзләрен АУЕда дип санаганнар криминаль законнар буенча яшәргә тырыша. Башка җинаятьчел агымнарга ияру дә үсмернең бөтен язмышын бозарга мөмкин. Фаҗига дә шунда: бу балалар – безнең киләчәгебез.

КАПКЫН



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

16 ел белән генә котылу – бәхет

Аның белән җомга намазыннан соң мәчет янындагы кафеда очраштык. Ерактан ук минем белән баш кагып исәнләште дә, намаздан соң тамак ялгарга кергән барлык ир-атлар белән кочаклашып, күрешеп чыкты. Чандыр гына гәүдәле, яшьләрчә киенгән. Маңгаенда – тирән сырлар. Ә күзләре – төпсез: йә гел йөгереп тора, йә үтәли тишеп карый. Кайбер чакта карашы белән сине менә хәзер сытар кебек! Ниндидер моңсулык чалымнары да сизелгән ул күзләргә карап берни аңлап булмый. Телендә – бары тик Аллаһы Тәгалә. Сораулы карашымнан аңлап булса кирәк: «Мин Аллаһы Тәгаләгә сыенам. Бу фани дөньяда барысын да ул хәл итә», – диде. Моннан дистә еллар элек җаннар кыеп йөргән кешедән мондый сүзләр ишетүне күңелем кабул итә алмый, ә акылым белән аңлыйм – тәүбәгә килергә бервакытта да соң түгел. Ул тәүбә чын күңелдән булса. Сүзем узган гасырның 90 нчы еллары ахырында Казанны дер селкетеп торган «Жилка» җинаятьчел төркеменең киллеры, криминаль дөньяда «Снежок» кушаматы белән билгеле булган Алексей Снежинский хакында. Кылган җинаятьләре өчен 16 ел төрмәдә утырып чыккан. Шунда ислам динен кабул иткән, иманга килгән, үзенең кечкенә бизнесы бар. Тоткынлыктан азат ителүчеләр өчен оештырылган реабилитация һәм адаптация үзәгенә ярдәм итә.

– Ә бит ул тәвәккәл яшь егетләрнең күпме потенциаллары бар иде. Ялгыш юлга кереп китеп, хәзер җәһәннәм утында яналар. Бу – 90 нчы еллар фаҗигасе. Кайберәүләр уйлаганча, анда бернинди романтика юк, – ди ул. Минем белән очрашуга да бары бер шарт белән килде: җиде юл чатында басып торган яшьләргә аңлатасы иде, ди. – Җинаятьчел төркемгә 14 яшемдә эләктем. Ул еллар бик болганчык еллар иде, хәерчелек хөкем сөрә. Әни хезмәт хакы алгач, «Сникерс» шоколады белән «сыйлый». Бер шоколадны өчкә бүлеп ашыйбыз... «Икенче хезмәт хакы алгач, «Баунти» алырмын», – ди ул. ...Халыкның киләчәккә өмете юк. Урамда милиция түгел, «төркем»нәр тәртип урнаштыра. Алар белән булсаң, син – текә, юк икән – чушпан. Тирә-ягымда гел җинаять белән бәйле кешеләр. Күршем чия төсендәге 99 нчы маркалы машинада йөри иде. Аңа кызыгып карыйм. Ә аның ничек акча эшләве белән беркем кызыксынмый иде, иң мөһиме: ул – бар. «Бөтен кеше урлаша», – дип, аның криминалда торуына да шаккатмадылар бугай. Миңа ул вакытта «ярамый», «башкача яшәү юлы да бар», дип әйтүче булмады. Ә аның юлы булган икән. Ул елларда Мәскәүдән сагыз, шоколад алып кайтып сату иткән егетләр, хәзер әнә миллионерга әйләнде... Көннәрдән бер көнне дәрес әзерләп утырган җиремнән китабымны ябып куйдым да, урамга – «сбор» булган урынга киттем. Кертүен кертә, тик чыгармый икән ул дөнья. Көчле, текә, дусларым бар дигән иллюзия туа. Тик андагы кабахәтлек күренми кала: бүген алар – дуслар, иртәгә – дошманнар: бер-беренең маңгайларына терәп атарга мөмкиннәр. Һәм ул шулай булды да... Хәзер яшьләр өчен мөмкинлекләр зур – тырышсаң, үзеңне күрсәтергә була. Психикаң үзгә булып, атышып кан коясың килә икән, рәхим итеп Сириягә кит. Үлемнән калсаң, пенсияң, медаль-бүләкләрең булачак. Үз илеңдә герой булып йөрисең.

– Ул чорда да Чечняда сугыш бара иде. Нигә китмәдегез?

90 нчы елларда бик күп үсмерләрне капкынга эләктергән оешкан җинаятьчел төркемнәрне хәтерлисезме? Чарасын күрмәсәк, тарих кабатланырга мөмкин...

– Кечкенә чакта кук белән җенләнә идем. Ул хыялым чынга ашмады, Чечняга китеп карыйм дип уйлап, «старший»лар янына бардым. Тик алар мине җибәрмәде. «Нинди Чечня? Монда сугыш бара. Син монда кирәк», – диделәр. (Бандитлар сүзен сөйләгәндә төзек сөйләм тиз арада төрмә жаргоннары, «блатной дөнья»дагы кыланмышлар белән «баетыла». – *Ч. Г.*) Җинаятьчел төркемнәрне хәерчелек китереп чыгарды. Акчасы булмаган кеше югалтыр әйберем юк дип саный. Ә хәзер җәмгыятьнең күп өлеше барлыкта яши. Яшьләр тели икән – спорт белән шөгыльләнә, тели икән фәнгә йә бизнеска кереп китә. Бары тик алар өчен абруйлы ата-ананың юл күрсәтүе, вакытында ярдәм итүе генә кирәк. Ата кеше эштән кайта, хатынын кыйнамый, балалары белән сөйләшә, аларга нәрсә яхшы, нәрсә начар икәнен аңлата икән, бу – сәламәт гаилә. Безнең гаиләдә мөнәсәбәтләр бик авыр иде. Күзенә генә карап торган хөрмәтле әтием булса, аның каты кулын тойган булсам, бу үкенечле хәлләргә тарымас та идем, бәлки. Хәзер үземнең кечкенә ике балам өчен үрнәк әти буласым килә.

– Бүген кабат оешкан җинаятьчел төркемнәр, АУЕ кебек төрмә «романтика»сы белән яшәгән субкультуралар баш калкыта...

– Әйе, бу безнең җәмгыятьнең проблемасы. Мине инде болар берсе дә кызыксындырмый, чөнки үз вакытында күп «ашарга» туры килде (муенынннан сызып күрсәтә). Әйтәм бит, контроль кирәк. Үсмер ишегалдында трай тибеп йөри икән, төрмәдән чыккан берәү хәзер аны эләктереп алачак, чөнки элекке криминаллар үз йогынтыларын кабат ныгытырга, үз тәртипләрен урнаштырырга тели. Бандитлар дөньясында бәясе сукыр бер тиен тормаса да, малайларны үз янына җыеп, кайберәүләр үзен кәттә кеше итеп күрсәтә, бандитлар тормышын романтикага төреп сөйли. Төзелеш алга барсын өчен идарәчеләр түгел, кара эшчеләр күп булу кирәк. Монда да шундый ук алгоритм.

...Ике сәгатьләп сөйләшеп утырганнан соң, ул сәгатенә күз сала башлады.

– Эшкә ашыгасызмы?

– Юк, намаз вакыты җитеп килә. Ә мин намазны калдырмыйм.

Һәр кашык ризыкны бисмиллаһ әйтеп капкан Алексей кабат мәчеткә юнәлде. Намаз укып дога кылганда нәрсә тели икән ул? Үтергән кешеләренең якыннарыннан гафу сорыймы? Аллаһы Тәгаләдән ярлыкауны үтенәме? Әллә бөтен кылган гөнаһлары өчен 16 ел гомере белән генә «түләвенә» сөенеп, рәхмәтен укыймы?

Куркыныч дөнья капканы

Беренче тапкыр АУЕ турында 2010 елда Краснодар краендагы Белореченск тәрбия колониясендә күпләр катнашындагы тәртип бозулар вакытында ишетелә. Аннан бөтен Россиягә җәелә. Бигрәк тә Байкал аръягы, Чиләбе, Читада киң таралган. Хәерче төбәкләрне тәмам камап алган. Татарстан социаль-икътисадый күрсәткечләр буенча алга киткән төбәк булуга карамастан, АУЕ капшавычларын безнең республикага да җибәрде. 2014 елда ук Юдинода җинаять кылган үсмерләрнең дә әлеге субкультурага керүләре мәгълүм.

Аңа үсмерләрне ник җәлеп итәләр соң? Әлеге проблеманы тикшергән белгечләр әйтүенчә, 5-6 нчы сыйныф укучысына югары сыйныф укучылары килә дә урам, төрмә төшенчәләре белән сөйләшә башлый. Юк, алар аны куркытмый. Янаулар әле соңрак булачак. Әлегә аның белән зурларча

Фото: www.pixabay.com

гәп коралар. Монда психологик фактор күп роль уйный. Беренчедән, зурлар килеп сөйләшкәч, 5 нче сыйныф баласының (балачакта 4-5 яшь аерма бик зур ул!) мин-минлеге үсә; икенчедән, олылар янында аның «салага» булып күренәсе килми; өченчедән, билгесез лексика кызыксыну уята. Ә балаларга кызыксыну хас. Бала алар белән сөйләшә башлый икән, ул инде үзен әкренләп югалта дигән сүз, чөнки әңгәмәдәшләре – олылар, тәҗрибәләре зур. Алар «общак» өчен акча алып килергә куша. Өйгә кайткач, бала бу хакта ата-аналарына хәбәр итми, сөйләшми икән, башка бер дөньяга эләгә. Ул анда беркем түгел, аннан бары тик сорыйлар гына. Башта – акча алып килергә, торабара – җинаять кылырга. Бу дөньядан чыгу бик авыр. АУЕ постулатларының берсе: «Төрмәнең әле беркемне дә җибәргәне юк».

«13–15 яшьтә, бу миңа нигә кирәк, болар белән мин кая барып чыгармын, дип уйламыйсың. Көтү булып яшәү теләге малайларда бик зур ул», – дип сөйли Рөстәм (исеме үзгәртелде). Аның гаиләсе Казандагы социаль яктан начар саналган районнан фатир ала. Мәктәбе үзәктә урнашса да, укудан соң ул шушы районга кайта. Кичләрен ишегалдына чыга. Анда – урам малайлары. Араларында – төркемне тотып торган егетләр. Шуларга ошыйсы килә башлый. Һәм ул үзеннән-үзе урам малайларына ияргә.

– Урам төркеме пирамида кебек: биш баскычтан тора. Башта шуның иң аскы катламына – яшьләргә кердек. Безнең өчен билгеле бер кагыйдәләр бар иде. Кагыйдәләрне бозсаң, өлкәннәр кыйный, – дип искә ала бүгенге көндә инде югары белем алып, дәүләт оешмасында карьера ясаучы Рөстәм. Бәхетенә, җинаять дөньясы белән танышмый кала ул. Криминаль авторитетларны төрмәгә утырта башлагач, өлкәннәр аларны җыя да: «Таралышабыз», – дип игълан итәләр.

«Урам» тарихы бәхетле тәмамлануга карамастан, Рөстәмнең үкенече бар. «Кичләрен трай тибеп йөргән көннәрне чит тел өйрәнеп үткәрсәм йә берәр җитди шөгыль тапкан булсам, күпкә яхшырак булыр иде», – ди ул. Урам белән бәйләнүен дә контроль булмауда күрә. Әти-әниләре көне-төне эштә. «Хәзер мин ата-аналарның яхшырак районда яшәргә, баласын үрнәк мәктәпкә бирергә теләвен аңлыйм. Белем алудан битәр, мохит бар», – ди ул.



Татарстан Фәннәр академиясенең ислам тикшеренүләре үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының деструктив яшьләр идеологиясе буенча эксперты Валерий ГОРШУНОВ: *«Халыкара мәктәптә сез АУЕ тапмассыз. Ул субкультурага, нигездә, эшчеләр кварталында яшәүчеләрнең, уңышлы булмаган гаиләләрнең балалары керә. Бигрәк тә моношәһәрләрдә яши бу проблема...»*

Гаилә – яклаучы

– Гаиләдә ата-аналар эчсә, өйдә тавыш-гауга купса, көн саен тормыштан зарланса, якты киләчәккә өмете булмаса, һәм бу хакта даими рәвештә үсеп килүче баласына сөйләсә, билгеле, үсмердә җәмгыятькә карата каршылыклы фикерләр туа. Үзе кебек уйлаучы яшьтәшләре белән очраша икән, аларга кушылып китүенә шик юк, – дип сөйли Татарстан Фәннәр академиясенең ислам тикшеренүләре үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты, негатив субкультураларга эләккән үсмерләр белән эшләүче Валерий Горшунов.

Аның фикеренчә, кешеләр җәмгыятьтә үз төркемнәрен эзли. Бу, нигездә, 13-14 яшьләрдә башлана. Яшүсмер бу яшьтә инде үзен олыга саный, ата-ана аңа абруй булмый башлый, алар тарафыннан контроль дә югала. Үсмер егетнең акчасы юк, абруе да юк, шул ук вакытта кызлар да кызыксына аның белән. Ул социаль статус эзли. Җитмәсә, урамга чыккач, аңа башка үсмерләр бәйләнә. Аның саклану механизмы эшли башлый: ярдәм итә алырдай төркемеңне тап! Ярый ла бу вакытта авторитет булырдай өлкән абыйларың, абруйлы әтиең булса, ә юк икән – урам төркемнәре кармагына кабасың. Криминаль дөньяны хәтта сталинизм да җиңә алмаган, чөнки ул йогышлы чир кебек: кайда йомшак, шунда баш калкыта. Балаларны әлеге криминаль комбайннан ничек саклап калырга соң?

– Иң беренче шарт – тулы гаилә, – ди Валерий Горшунов. – Әти кеше баласы бүлмәсенә Терминатор фотосын элеп куеп: «Менә, улым, Арнольд Шварценеггер кебек бул. Ул көчле һәм шәп кеше», – дип әйтергә генә тиеш түгел инде. Ясалма образ бернәрсә бирми. Гаиләдә абруе булган үрнәк ата белән мөнәсәбәтләр үзара ышанычка корылган булырга тиеш.

Кызганыч, хәзер тулы булмаган гаиләләр күбрәк шул. Анда үскән балаларның урам төркемнәренә элэгү ихтималы бермә-бер арта. Шуңа күрә дә холыкларыбыз туры килми дип кенә аерылышу дөрес түгел. Иң элек бала хакында да уйларга кирәк! Үсмер янында үз-үзен тотышы үрнәк булырдай ир-ат торырга тиеш. Юк икән, ул аны субкультуралардан эзли башлый.

Балаларда идеологияне 14 яшьтән түгел, 4-5 яшьтә үк тәрбияли башлау мөһим. Кечкенәдән үк күңеленә ятышлы шөгыль табу да урам афәтеннән алып кала ала. Страйкбол кебек хәрби хәрәкәтләр

йә спорт ярдәм итәр. «Спортның да артык нык популяр булмаган төре», – ди белгеч.

Ярый, уку елы буена бала шөгыльләнә, аның бернәрсәгә вакыты калмый, ди. Каникуллар җитә дә бала ирекккә чыга, читлектән чыккан кош кебек анда-монда бәргәләнә башлый. Җәйге каникуллар – урам төркемнәренә кереп китү өчен иң кулай чор. «Баланы шәһәрдән алып китәргә кирәк», – ди Валерий Горшунов.

АУЕ идеяләре тарата торган тагын бер мәйдан – социаль челтәрләр бар әле. Монысы тагын да хәтәррәк. Өйдә компьютер артында утырган бала көннәрдән бер көнне танымаслык булып үзгәрергә мөмкин. Интернеттагы АУЕ социаль тормыштан аерыла кебек миңа. Ул күбрәк криминаль фольклорга охшаган. Челтәрләрдә бу идеяләрне тараткан төркемнәрдә утыручылар саны бик күп. Дөрес, ул төркемнәрне тыеп та карадылар, тик алар башка адрес белән кабат ачылган. Мәкалә язганда үзен Татарстаннан дип күрсәткән бик күп үсмерләргә хат язып, аралашып карадым. Барысы да диярлек: «Кызык бит, шуңа язылдым», – диләр. Төркемнәрдә утыручылар криминал белән бәйле дигән сүз түгел түгелен. Тик уеннан уймак чыкмагае! Шуңа күрә дә бу хакта үсмерләр белән әледән-әле сөйләшү кирәктер. Үсмер малае булган берничә танышымнан: «Бу хакта улың белән сөйләшеп карыйм әле йә үзең кызыксынып кара», – дип сорадым. Берсе дә ризалашмады. Күбесе: «Ул бу хакта берни белми, аңа белергә дә кирәк түгел», «сөйләмим, алайса кызыксына башлар», – диделәр. Ә үзләре баласының социаль челтәрләрдә нинди төркемдә утыруы хакында артык төпченмәүләрен таныды. Бәлки, алар «белми» дигән бала инде күптән АУЕ символларын кулланадыр? Шул рәвешле алар үзләрен әлеге субкультурага керүен таныта.

Боз кузгалдымы?

Бу субкультураны административ алымнар белән генә туктатып куеп булмый. Аны башка субкультура белән алыштырырга яки йогынтысын киметергә генә мөмкин. Ә бу эш белән дәүләт шөгыльләнергә тиеш. Бу җәһәттән безнең илдә уңышлы тәҗрибә бар инде. Узган гасырның 20 нче елларында урамда калган балалар саны 10 миллионга җитә. Билгеле, балалар җинаяте дә үсә. Әлеге вазгыять бары тик Макаренко системасы аша гына үзгәртелә. Илдә яңа субкультура – пионер оешмалары барлыкка килә, һәм анда барлык катлам балалары да керә. Бәлки, безнең җәмгыятькә дә игътибарны талантлы балалардан тормыш упкынында калган балаларга күчерергәдер? Комплекслы системалы эш алып барырга вакыт җиткәндер, күрәсең. Дөрес, бу проблема хакында чаң суга башладылар инде. Җаваплы министрлыклар авыр яшүсмерләр белән эшләү мәйданнарын булдыру кирәклегенә тукталып, бу мәсьәләне хәл итү юлларын күрсәтә. Тик бу сүздә генә калмасын иде. Юкса бүген баш бирми торган үсмерләрнең зурлар тормышына күчкәч, җинаятьчел төркемнәрнең сафын тулыландыруы бар. Ә бу дәүләт өчен 90 нчы еллардагыдан да куркынычрак баш авыртуына әйләнергә мөмкин.

БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ



Вадим СТРУЛИС, психолог

Үсмернең АУЕ яки башка криминаль структураларга бәйлелеген ничек белергә?

- Үз-үзен тотышы үзгәрә. Сөйләшүләрдән кача.
- Күп вакытын урамда йә сәүдә үзәкләрендә уздыра.
- Сез алып бирмәгән яңа әйберләре барлыкка килергә мөмкин йә, киресенчә, ул һәрвакыт акча сорый. Нигә икәнен төгәл генә аңлатмый.
- Үсмернең тәнендә күгәргән урыннар күренә башлый. Аның каян килеп чыкканын анык кына аңлата алмый.
- Хокук саклау органнары тарафыннан тоткарланырга мөмкин. Бу әле зур җинаять кылган дигән сүз түгел. Бәлки, подъездда шаулашканнар, сугышканнардыр.
- Тәнендә криминаль дөнья символикаларыннан тату ясый. Нигездә, ул сигез очлы йолдыз. Тәненә рәсем төшермичә, социаль челтәрләрендәге авкаларга, китап-дәфтәр тышларына, телефонына ул символиканы ясарга яки ябыштырып куярга мөмкин.
- Сөйләмендә үзенчәлекле сленг яки жаргон барлыкка килә.
- Криминаль төркем белән бәйләнгән үсмерләргә элекке шөгыльләре яки хоббие кызыксызга әйләнә. Укуыннан артта кала.
- Хәзерге «төркем»нәр элеккеләреннән аерыла. Элек спорт белән шөгыльләнүгә өстенлек бирелсә, хәзер тәмәке тарту, наркотик куллану гадәти хәлгә әйләнде. Үсмернең психоактив матдә дә куллануын да белеп була. Ул төрле дәрәҗәдә исерек хәлдә кайта, аннан үзенчәлекле ис килә, кесәсендә аңлаешсыз әйберләр табыла. Мәсәлән, фольга йә пластик шешәдән конструкцияләр.

Бу очракта ата-аналарга нишләргә?

- Паникага бирелмәскә. Үсмер белән җайлап сөйләшеп карарга. Тәнкыйтьләмәскә. Аның дуслары белән сөйләшү җаен табарга.
- Диалог барып чыкмый икән, психологка мөрәҗәгать итәргә. Үз гаиләгездәге атмосфераны да җентекләп анализлагыз: бәлки, проблемагыз бардыр, һәм үсмер шул рәвешле аңа каршылыгын белдерәдер.
- Эш зурга китсә (җинаять эшләре ачылу куркынычы бар), йә үсмернең әлеге компаниядән чыгасы килеп тә, аны җибәрмәсәләр, бу очракта бердәнбер юл: башка урынга күченеп китәргә. Андый мөмкинлек булмаса, үсмерне ябык уку учреждениеләренә бирергә.

– Реанимациядә мин бәхетле булып уяндым... Операция өстәлендә аңыма килеп: «Мин кайда? Минем белән нәрсә булды?» – дигәнемне беләм. Соравыма җавап биргәнче, башта аяк бармакларымны селкетергә куштылар. Селкеттем. Аннан соң гына: «Сез юл фаҗигасенә очрадыгыз», – диделәр. Тагын каядыр төшеп югалдым... Светофорның яшел уты, кузгалам... Юк, башка берни дә хәтерләмим... Дәрвишләр бистәсенә, анда урнашкан «Эдельвейс» кибетләренең берсенә баруы була Фәридәнең: ул тарата торган кондитер әйберләренең кайсы сатылып беткән, кайсын китерергә кирәк – сәүдә үзәге саен кереп, белешеп йөрүе. Трассада, руль артында ул аңын җуя. Идарәсез калган машинасы каршы як юлга кереп китә. Зур тизлектә бер машинага бәрелә, икенчесенә, өченчесенә... Операциядән соң унике сәгать узгач кына ул чынлап торып аңына килә. Бер аягы – бот төбенә кадәр гипста, икенчесе – тоташ тимердә: анысында өч (!) Илизаров аппараты. Яңа тормышы шул көнне башлана. Дөресрәге, тормышының икенче өлеше.

Гөлнур САФИУЛЛИНА

БЕР БӘХЕТ ТАРИХЫ



Иң яраткан курчагым улыма охшаган. Чәче генә бөдрә. Аннары кайсы булыр, белмим.

Ә бит бу коточкыч фаҗигане урап узарга да мөмкин иде дип саный ул хәзер. Ходай безне беркайчан да алдан кисәтмичә калмый. Тик, кызганыч, еш кына без аның нидер әйтергә теләвен күрмибез, белмибез, аңламыйбыз. Фәридәне дә кисәтә ул. Бер түгел, ике мәртәбә! Авариягә ике көн кала, өйдә аңын җуеп егыла. Иртәнге сәгать дүрттә мәчесен ашатырга торгач. Аның дөбердәп егылган тавышына куркып улы уяна... Аңына килгәч, «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртыйк», – дип үрсәләнгән улын тынычландыра да, кабат йокларга ята. Табибка күренү, иң гади анализларны булса да биреп карау турындагы уй, нигәдер, башына да килми. Күрәчәккәдер... Өянәк ике көннән тагын кабатлана.

Бүген дә һәр мизгеле истә булган бер төш тә бар әле. Әтисе: «Кызымм-м», – дип дәшә, аны бәхилләшергә чакыра икән. Аңарда яман шеш икәнен, бу көрәшүнең соңгысы булачагын төшендә дә хәтерли Фәридә. Аякларына кара итекләр кия дә, әтисе янына чыгып йөгерә. Аяк асты боз, су... Ул су һаман арта, күтәрелә, итекләргә тула, атларга ирек бирми һәм Фәридә туктап кала. Әтисе чакырган якка бик барасы килә, әмма баскан җирдән кузгалып китә алмый... Кара итекләр! Аягына кигән кара итекләр! Менә нәрсәгә булган икән... Реанимациядән аны дүртенче көнгә генә чыгаралар. «Исәнлегемне әтигә дә хәбәр итим, ул да борчылып торадыр», – дип телефонга үрелә. Әнисе кулыннан тотып туктата: «Өлгерерсең, балам...» Бу хәл берничә тапкыр кабатлана. «Нәрсә булды соң, аңламыйм?» – дигән кызына әнисе авыр хәбәрне ике көннән соң гына җиткерә. «Әтиең киткән, Фәридә...» – ди. Нәкъ аны реанимациядән палатага күчергән сәгатьләрдә! Башка гаиләдә яшәсә дә, ата белән кызның аралары бик якын була шул... Барысы да төштәгечә кабатлана: әтисе белән саубуллашырга өлгерми кала. Аның каберенә барганчы инде икенче кыш җиткән була.

Бер ел! Озын-озак бер ел! Башта әле ян-якка борылырга, утырырга да ярамый. Ярамый түгел, булмый! Аз гына селкенсәңме, тәнгә мең энә







кадала. Ул сызлануларны иң көчле дарулар да басмый.

– Әмма «башка йөри алмам» дигән уй ялгыш та башыма кермәде! Өметне өзмәдем! Кыл өстендә торган мизгелләр булды югыйсә... Табиблар консилиум җыйды, минем бер аякны кисәргәме, юкмы икәнен хәл иттеләр. Әйбәт хирургка эләктем. «Син бит әле бик яшь, 37 дә генә – алда башланмаган тормышың», – дип, ул бик тырышты. Ялгап булмый дигән сөякләрне дә ялгады... Күпмедер вакыт узгач, авыртуларга ияләшәсең икән. Күнәсең... Ярты елдан соң... Юк, юк, беренче адымны ясамадым әле. Аңа кадәр торып басасы бар бит. Әни саный: «Бер, ике, өч...» Нәкъ өч секунд! Шуннан артыгы берничек булмый. Андый әрнүләрне берәүгә дә теләмим... Нинди «адымнар» белән алга барганны шуннан чамалагыз... Ян-якка борылып ятарга ярамый иде әле – энәләр сорап алдым: бәйли башладым. Картиналар ясадым. Тегү машинамны яныма китереп куйдылар – тегәргә керештем. Бераздан заказлар ала башладым. Вакытым шундый күп иде бит минем. Яңа көн туган саен – егерме дүрт сәгать!

Курчаклар ясау остасы Фәридә Хәйруллина – Казан кызы. Кечкенәдән шундый – аның беркайчан да буш вакыты булмаган. Музыка мәктәбен, хор классын тәмамлаган. Алтынчы сыйныфта укыганда Пионерлар йортына, тегү түгәрәгенә йөри башлаган. Үзе исә... хирург булырга хыялланган. Ә язмыш аны кинәт башка сукмакка борган. Унынчыда укып йөргәндә, тегү түгәрәге җитәкчесе: «Ә син кем булырга телисең?» – дип сорый. Җавапны ишеткәч: «Кан эчендә кайнарга түгел, матурлык өчен тугансың бит син, Фәридә!» – ди. Шул бер җөмлә җитә... («Ә бит миннән яхшы хирург чыгар иде. Һәрхәлдә, иң матур җөйләр миндә булыр иде!» – дип елмая.)

Мәктәпне тәмамлагач, Мәскәү көнкүреш хезмәте күрсәтү институтына укырга керә – инженер-технолог һөнәрен сайлый. Киләчәк инде күренеп тора: аның урыны ательеда булачак! Институтка эш тәҗрибәсе булмаганнарны алмыйлар: аңа кадәр бер ел Модельләр йортында эшли.

Фото: Анна Арахамия

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

Ходай сынауларны кешенең сабырлыгына, түземлегенә карап өләшә бугай.



Трикотаж тукыма белән эшләргә шул вакытта өйрәнә. Ә бер өйрәнгән һөнәрнең тормышта кирәге чыкмый калганы юк әле…

Читтән торып Мәскәүгә укырга керә һәм ул арада Казанда яңа һөнәр үзләштерә: «чәчтараш» дипломы алырга өлгерә. (Юк, вакытның бер минутын да бушка уздыра торган кеше түгел ул!) Кияүгә чыга. Улы Эдвардка 3 яшь тулганда инде Фәридә тол кала. Әйе, хәсрәтнең мондыен да кичерә… Ире җәй азагында югала. Аны ноябрьдә генә табалар. Ярты гәүдәсен…. Шул елның маенда гына ике бүлмәле фатир алган булалар. Яраткан кешеңне кара гүргә салуның авырлыгын башыннан кичергәннәр генә белә… Әмма яшәргә кирәк: баланы үстерергә, фатирга ремонт ясарга, көн итәргә… Кулындагы һөнәр коткара – тегә башлый.

– Кайда гына эшләсәм дә, кичләрен гел тегү машинасы артында идем. Тегү миңа тормышны алып барырга, улымны үстерергә булышты. Әнием, апам исән-сау, эти… Улым үсеп килә. Дөньям түгәрәк, бернәрсәгә хәсрәтләнергә кирәкмәгән юкса… Хәзер шулай уйлыйм. Әмма тормыштан, үз-үземнән канәгать булмаган чаклар да күп иде шул. Соңгы елларда еш кына бер сәбәпсез боегып йөрдем, нигәдер моңсуландым… Ходай барысын да үз урынына куйды. Реанимациядә шуңа да бәхетле булып уяндым. Бер яктан, исән калуыма сөенүем дә булгандыр бу. Иң якын кешеләрем – әнием, улым янымда: бәхет өчен тагын ни кирәк?! Күземне ачуга шул хакыйкатьне аңладым… Шуңа да үз-үземә: «Бу сынау нигә килде?» – дигән сорауны ялгыш та биргәнем булмады.

Юл фаҗигасе бик күп нәрсәне үзгәртә. Фәридәнекен генә түгел, аның тирә-юнендәгеләрнекен дә. Әнисе алар янына күченеп килә: ике йортны берләштерәләр. 15 яшьлек улы олыгаеп китә, урында яткан әнисен карау мәшәкатьләре аңа да шактый эләгә. Дуслар… Алар өчен дә зур сынау була бу: кемдер кинәт югала, икенчеләре, киресенчә, тагын да якыная, яңалары табыла.

– Танышлар бер массажист ханымны тәкъдим иттеләр ул чакта. Әфганстан чигендә урнашкан шәһәрдә эшләгән, сугышта яраланган егетләрне аякка бастырган – тәҗрибәсе зур. Күпне күргән… Юлымда ул очрамаса, бәлки, мин дә кабат йөреп китә алмаган булыр идем… Унике ел булды менә – әле дә аралашабыз, якын кешеләргә әйләндек… Ходай юлыма нинди яхшы кешеләр чыгарганын санап та бетерә алмам!..

Әлеге коточкыч авария 2007 елны була. Аякка тәмам басканчы ике ел уза. Аннан соңгы елларда Фәридәгә заказлар, үзе әйткәндәй, «ишелеп килә». Туй күлмәкләре, кичке күлмәкләр… Аларын бигрәк тә яратып тегә – монда бит иҗатка чикләр юк! Чираттагы дефолтны ул инде тыныч күңел белән каршы ала. Улы инде институт тәмамлаган, эшли. Фатирларына искиткеч ремонт ясалган – кергән кешенең чыгасы килми. Клиентлар азрак килүе, буш вакыт калуы әйбәт кенә, димәк, курчакларга тотынырга вакыт җиткән.

– Хыяллана идем! Мин, ниһаять, моңарчы туплаган бөтен тәҗрибәмне күрсәтә алам. Теккән киемдә дә чагыла ул, әлбәттә. Әмма курчаклар барыбер башка! Аларның хәтта җаны бар кебек. Бөтен барлыгымны салып эшләгәнгәдер…

Еш кына якыннарының туган көннәренә курчак ясавымны сорыйлар. Фотосын җибәрәләр, ул кеше турында сөйлиләр. Аннан курчакны кулга алалар да: «Холкына кадәр күренә!» – дип гаҗәпләнәләр. Ничек шулай килеп чыга, үзем дә белмим… Кемнеңдер гардеробындагы берәр деталь кабатлана, холкының берәр сыйфаты. Кайсыбер курчакларымны үземә дә охшаталар.

Яңа курчакка тотынсаң, туктыйм димә. Тизрәк аның нинди булганын күрәсе килә. Кайчак төнге өчләр җитә… Иң авыры йөзе, әлбәттә. Башта күзләр урынына ике нокта гына ясый идем, хәзер инде күзләре дә бар, авызы да, борыны да. Һәр яңа курчак алдагысыннан яхшырак килеп чыга: кул эшли-эшли остара. Саннары йөзгә тула бит инде…

Курчакларны капрон оеклардан ясаганда, башта оекларны кайнатырга кирәк. Монысы – әни өстендә. Ул аның тәртибен төнлә уятып сорасаң да белә: күпме кайнатасын, ничек чайкыйсын, элэсен… Икенче төрле техника белән эшләгәндә, курчаклар эченә холлофайберны да әни тутыра: нәкъ мин теләгәнчә тыгыз итеп. Безнең әни бер дә саран түгел, киресенчә. Әмма курчакларны беркемгә дә бирәсе килми аның! Аларга күпме көч салганымны күргәнгәдер, бәлки. Җаның ярату, җылылык белән тулы икән, ул ташып чыга – курчакларыңа да күчә. Һәм алар витринада торганчы, шушы энергетиканы алып, кемгәдер киткәнгә куанам гына: башкаларны да сөендерсеннәр. Мин шуның белән яшим… Узган ел грипп белән авырып яттым, «Ашыгыч ярдәм» чакыртырга туры килде. Төнге унике иде. Табиб кызның күзе, әлбәттә, курчакларга да төште. Сөйләшеп киттек… Мин аларны лифтка кадәр озата чыктым. Әни көлә: «Авырганыңны онытттыңмы әллә?» – ди. Эшемә сокланулары белән терелттеләр!

Мәрхүм иремнең апасы узган җәй юбилеен үткәрде. Мин аларны бик

хөрмәт итәм. Ирем белән дүрт кенә ел яшәп калсак та, туганнары белән гел аралашып тордык. Кайнанама әле дә «әни» дип дәшәм. Эдвард та һәрвакыт аларга барып йөрде: улым минем әнине дә, аны да бертигез ярата. Туганнар артык булмый... Мәҗлескә, әлбәттә, портрет-курчаклар белән бардым. Тамада: «Шушы курчаклар өчен генә булса да юбилейны оештырырга кирәк иде», – диде. Гөрләтеп кул чаптылар. Шундый рухланып кайттым!

Мастер-классլар үткәргәнемне белеп: «Нәрсәгә өйрәтә аласыз?» – дип шалтыраталар. «Нәрсә теләсәгез – шуңа, – дим. – Кисәргә, тегәргә, курчаклар ясарга...» Бер укучым: «Юк, курчакны үзем дә тегәм. Мине күлмәк тегәргә генә өйрәтегез», – дип килде. Кистек күлмәкне, өй эше биреп җибәрдем. Икенче дәрестә исә: «Әйдә, күлмәкне читкә куеп торыйк. Сезнеке кебек курчаклар тегәргә өйрәнәсем килә. Минекеләр курчак түгел икән әле», – диде.

Минекеләр башка шул. Үз дигәннәренә ирешә торганнар. Ышанмыйсызмы? Бер шундый очрак булды. Заказ биргәндә: «Ул кызның туристлык агентлыгы бар. Үзе дә сәяхәтләрдән кайтып керми», – дип сөйләделәр. Аңа ясыйсы курчакны шунда ук күз алдыма китердем: чәчен, күзлеген, чемоданын, сумкасын, биек кунычлы итеген... Барысы да мин уйлаганча килеп чыкты, тик итегенә минә көн җитмәде – бик матур туфлиләр тектем. Аларны кидертеп бастырдым курчакны, ә ул... шунда ук егылып китте. Берни аңламыйм. Сүтеп, яңа аяклар тектем. Җиңел генә эш түгел бит әле бу... Аягына кидертеп бастырып карыйм – тагын егылды. Туфлинең табанын калынайттым. Юк, егыла гына! Курчакны күтәреп бәрдем... Әни йөгереп барып аны тизрәк кулына алды. Шул вакыт икебезнең дә күзе витринадагы бер курчакка төште: аңарда шундый озын кунычлы итекләр ләбаса. Нәкъ мин теләгән! Кидертеп бастырдык – басып тора! Нәрсәнедер дөрес эшләмәдем дияр идем – бу инде җитмешенче курчагым...

Фәридә курчаклар турында бик озак сөйли ала. Бик озак! Соңгы вакытта бөтен шатлыгы да, борчуы да шул курчаклар белән бәйле. Борчуы дигәннән... Узган ел яз бер курчагына күзлеккә дип «Франт» сәүдә үзәгенә чыга Фәридә. Светофорны узгач, бер яшүсмер аңа велосипеды белән килеп бәрелә. Бик зур тизлектә... Болай да таяк белән йөргән кешегә күп кирәкме?! Өч ай гипста ятарга туры килә. Тагын бер авыр сынау була бу... (Гипсны салгач, иң беренче эш итеп Фәридә кабат күзлеккә чыгып китә. Заказ бирүче курчакны бер бәйрәмдә юбилярга тапшырырга тиеш була. Әмма бәйрәм үткәч: «Алып бармадым. Ул кеше аңламас, дип киңәш бирделәр», – ди. «Алай булса, син аны миңа кире кайтар», – ди Фәридә. Озак та үтми, икенче бер танышы: «Кара чәчле курчак кирәк», – дип килә һәм шушы курчакны сайлый. Шулай, язмышлар монда да төрле-төрле.)

Бәхет тарихы дидем. Әйе, бернигә дә карамыйча, Фәридә үзен бәхетле саный!

– Фаҗигагә кадәр бик чибәр идем. Зифа буйлы идем, матур киенергә яраттым. Бии идем! Һәм боларның барысыннан да мәхрүм калдым. Аягымда җөй өстенә җөй. Юанаеп та киттем. Тик боларның берсе дә мине борчымый. Җанымда – гармония. Әйе, мин бүген – II группа инвалид. Начар йөрим. Әмма моңа кыенсынганым юк. Элек миңа: «Аяклары нинди төз! Киеме нинди матур!» – дип борылып карыйлар иде. Башкалардан аерылып тору шундый ошый иде. Хәзер дә борылып калалар! Күпләр аяк киемемне карарга борыла. Мин аларны үзем бәйләдем: туфли, итек... Авариядән соң башка аяк киеме кия алмадым... Тормышым кайнап тора! Мин гел эштә, гел аралашуда. Җәен бакчага баруга, ашыгып кире өйгә кайтам: клиентларым көтә. Хәзер минә – курчакларым... Плиткалар ясыйм – алары аерым бер тарих. Пэчворк белән мавыгам.

Үз башыңнан кичермичә күп нәрсәне аңлап булмыйдыр. Тик бу бөтен кешегә дә сынаулар аша үтәргә дигән сүз түгел... Инвалид та шундый ук кеше. Тормышка мәхәббәте зуррак та, яшәү теләге, кеше хәленә керә белүе күбрәк. Ул да шундый ук хисләр кичерә. Минем хәтта минә биисем дә килә. Биим дә! Читтән караганда сәеррәктер, әлбәттә. Булса соң! Европада әнә кешенең гарипләгенә бөтенләй игътибар итмиләр. Ә бездә тәрбия җитми...

Мине кызганырга кирәкми. Булды, барысы да булды. Яратуның да ни икәнен беләм, югалтуның да. Барысын да кичердем. Һәр хатынкыз кебек... Ә хәзер башка тормыш җитте. Авыртулы, сызланулы... Әйе, алар һәрвакыт бар. Адым саен... Әмма бу әрнүләр үзе белән шундый зур ярату алып килде. Тормышымны матур буяуларга төрде. Дус кызларым нәрсәдәндер зарланганда, гел әйтәм: «Көнләшегез, минем бар да әйбәт! Мин бәхетле!» – дим. Артык берни дә кирәкми. Кеше нигә боларны сынау кичергәч кенә аңлый, белмим...




■ Иң мөһим кешеләрем икәү – әни һәм улым. Бер конфет бирсәләр дә, Эдвард шуны минем белән бүлешеп үсте. Шөкер, бүген дә шулай... Ә әнием – бер нур кебек. Таянычым, терәгем, аяк астымдагы җирем... Бөтен дөньям!


ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да… Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

БЕРЕНЧЕЛӘР



























Фото: Анна Арахамия

Гөлсинә ЖАНТИМЕРОВА: Герой исемен миңа бирүләре өчен гомерем буе кыенсынып яшәдем. Әйе, заводка иң беренчеләрдән булып эшкә килдем, аның төзелешендә катнаштым. Ләкин мин анда үзем генә түгел, без күбәү идек. Күз алдыма берәм-берәм хезмәттәшләремне китерәм – алар барысы да Герой исеменә лаек кешеләр.

«Кызлар, химик-аппаратчы булырга теләмисезме? Ак халатлардан гына йөрерсез...» Казан шәһәренең 119 нчы мәктәбен тәмамлап килгән бер төркем кызны әнә шулай кызыктырып куялар.

Гөлсинә Җантимерова (ул чакта Хәсәнова) шул көнне үк җавап бирергә ашыкмый, кайтып, башта әти-әнисе белән киңәшә. 1960 елда була бу. Илдә зур төзелешләр бара. Казан читендәге ялан кырда да химия заводы төзелеше башлана.

...«Җавапны иртәгә бирербез» дип кайтып китүче кызлар иртәгәсен борылып килеп, документларын ул чактагы 3 нче техник училищега тапшыра. Ак халаттан йөриячәк аппаратчылар чынлыкта лаборантлар була икән. Бераз укыгач, кызларны дүрт айга Новокуйбышевскига практикага җибәрәләр. Менә шунда инде үзләре башкарачак эш белән чын-чынлап танышалар.

...Каршымда тарихның үзе – заводның иң тәүге хезмәткәрләреннән берсе, «Оргсинтез»да беренче производство цехын эшләтеп җибәрүче Гөлсинә ханым – «Азат хатын» журналының 1976 елгы апрель саны героинясы утыра. «Органик синтез» производство берләшмәсенең аппаратчысы, КПССның XXV съезды делегаты, Социалистик Хезмәт Герое, ике Ленин ордены кавалеры. Беренче эш көнен дә бүгенгедәй хәтерли ул:

– 1961 елның 1 декабре. Заводка 183 нче номерлы комсомол путевкасы белән килдем. Без – беренче аппаратчылар – 30 кешедән торган дүрт төркем идек. Без эшләгән беренче цех 1958–1963 елларда төзелде. Заводның беренче директоры – гаҗәеп акыллы кеше, талантлы җитәкче Владимир Лушников, утырышлар залына җыеп, алга куелган максатларны аңлатты.

Завод 1963 елның 13 июлендә эшләп китте. Эссе, кояшлы көн! Халы-ы-ык! Заводны ачу тантанасына КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Фикрәт Табиев һәм партиянең Казан шәһәре комитеты беренче секретаре Рәшит Мусиннар да килгән. Без ул көнне фенол-ацетонның иң беренче партиясен җитештердек. 1971 елда заводны – яшь-яшь коллективны Октябрь Революциясе ордены белән бүләкләделәр. Директор Владимир Лушниковка Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде. Ә миңа ул көнне Ленин ордены тапшырдылар. Нибары 27 яшь иде миңа...

Икенче улымны табып, декреттан чыккан көннәрем. «XXV съездга делегат итеп сайландың, Мәскәүгә барасың!» – диләр. Карышуымны белсәгез! «Лаеклыраклар барсын», – дим. «Беренче көннән үк эшлисең, шуңа сине сайладык та инде», – диделәр. Мәскәүдә безне – җитмешкә якын кешене – химия промышленносте министры кабул итте. Өстәлләр тирәли утырыштык, кинәт исемемне әйтәләр. Бар да кул чаба, тәбрикли. Миңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелүен игълан итәләр. Коелдым да төштем, үзем елыйм. Юк, шатлыктан гына түгел. Хезмәттәшләрем күзенә ничек кайтып күренермен, миннән дә лаеклыраклар бар иде дигән көенеч яшьләре иде ул. Иң куандырганы – хезмәттәшләрем үземнән дә артык сөенде бу хәбәргә. Янә шөмдә искиткеч кешеләр иде. Без ул вакытта күңелле яшә гән без, дим. Эшләгән кешене кайгырту да югары дәрәҗәдә иде заводта. Балалар бакчалары, пионер лагерьлары, санаторийлар, ял йортлары – барысы да эшчеләр өчен төзелде. «Оргсинтез» заводы – минем яшьлегем, минем дөньям ул.

Лилия ГӘРӘЕВА

УКЫТУЧЫ




Фото: Анна Арахамия



Гөлнур САФИУЛЛИНА

– Ул укучымны – Олег Кәлимуллинны әле дә онытмыйм. Хәзер кайдагыдыр «Девон-кредит» банкын җитәкли дип беләм... Иртүк мәктәпкә чабып килгән: «Асия Фәритовна, мин теге мәсьәләнең чишелешен таптым! Төшемдә күрдем!» – ди. «Онытмадыңмы?» – дим. «Юк!» – ди... Класслары белән Мәскәү дәүләт университетының читтән торып белем бирү мәктәбендә, «Коллектив укучы» группасында укыйлар иде. Алар җибәргән мәсьәләнең берсен чишә генә алмыйбыз бит! «Булмый», – дип кул селтисебез дә килми – үҗәтләнеп тотындык. Ә аннан Олег аның чишелешен төшендә күрде... Ике ел элек, декрет ялына киткән бер укытучы өчен вакытлыча укытып торырга сорадылар. Класстагы балаларга шушы очракны сөйлим – ышанмыйлар! «Мәктәпләрдә андый укучылар юк хәзер», – диләр... Ә без бит аларны үзебез үстердек. Кайчак шәхси тормышны да онытып... Укучыларның барысы да математиканы «бишле»гә белә аламы? Аларда бу фәнгә карата мәхәббәтне ничек уятырга? Бердәм дәүләт имтиханнарына ничек әзерләнергә? Татарстанның атказанган укытучысы, «Россия Федерациясенең иң яхшы укытучылары бәйгесе» җиңүчесе, «Халык мәгарифе отличнигы», Сорос фонды премиясе иясе (1994, 1999, 2001) Асия Фәрит кызы ДАЕШЕВА белән шулар хакында сөйләшәбез.

Мәктәптән тәрбия китте.

Яшь укытучы, дәрес бетүгә, класстан укучылардан алда тизрәк чыгарга ашыга хәзер.

– Контроль эшкә әзерләнәбез. Махсус тартма булдырдым: һәр укучы класска кергәндә телефонын шунда калдыра. Гаджетларын теләмичә генә кесәдән чыгаралар: берсеннән-берсе яхшырак… «Ә икенчесе кайда?» – дим. Башта аптырап калалар. «Өлкән яшьтәге бу укытучыны алдау авыр булмас», дип уйлаганнардыр инде… Мәктәп, андагы тәртипләр соңгы вакытта бик нык үзгәргән: бөтенесе дә кучерә…

Монысы да – ике ел элек алган «ачы тәҗрибә». Ул укыткан балалар күчерүнең ни икәнен белмәгән укытучыга бу күренеш белән килешү авыррак. «Контроль эшләр вакытында: «Сезгә комачаулamыйм», – дип, гадәттә, коридорга чыгып китә идем, – ди бит. – Юк, күчерү турына уйламыйлар да иде. «Янымдагы иптәшем үз башы белән эшләп алга киткәндә, үскәндә, мин күчереп утырып аннан артта калыйммыни?» – диючеләре булды».

Аннан үзе белән булган бер очракны искә төшерә. Алабуга дәүләт педагогика институтының физика-математика факультетында укыган чагы. Матанализдан имтихан тапшыралар. «Кемнең сөйләмичә генә «өчле» аласы килә?» – ди укытучы. «Минем…» – дип ишетелер-ишетелмәс тавыш белән җавап бирә бер кыз. «Шпаргалкаң бармы?» – дип сорый укытучы һәм: «Анысы да булмагач, димәк, «икеле»лек тә белмисең, – ди. Аннан Асия утырган якка борыла: – Ә синә, Латыйпова, сөйләмәсәң дә «дүртле» куя алам. Тик шпаргалкаң булса гына». «Минем беркайчан шпаргалка әзерләгәнем дә, кулланганым да юк!» – ди ул. «Син – кыю! – ди укытучы. – Ә имтиханны бирә алмасаң нишләрсең?» Сорау арты сорау яудыра ул аңа. Асия ул көнне аудиториядән «бишле» алып чыга!

Аспирантурадан баш тарта ул: гаиләдә алар болай да өч студент, инде дүртәү булырга торалар – әтиәнисенә авырракка туры килер. Юллама белән туган ягына – Бөгелмә районы Татар Димскәе урта мәктәбенә кайта. 1975 ел бу. Мәктәпләргә математикадан реформа кергән ел. А. Н. Колмогоров редакциясендә чыккан яңа дәреслекләр буенча укытырга укытучыларның барысы да ашкынып тормый. Ә аңа – яшь белгечкә кызык кына! Дәресләрне өеп бирәләр: физика, математика, астрономия… Сыйныф җитәкчесе вазыйфасы, түгәрәкләр. Кичке мәктәп… Фатир хуҗасы Фаруҗамал әби кай көнне кастрюлләрен күтәреп кичләрен мәктәпкә үзе килә… Теорияне өйрәнеп чыкканнан соң, физика кабинетындагы телескопны күтәреп, укучылар белән авыл янындагы тауга күтәреләләр. Телескоп янына мәктәп балалары гына түгел, терлек-туарын җыеп абзарларга япканнан соң, бөтен Татар Димскәе җыела: айны, йолдызларны һәркемнең якыннанрак күрәсе килә… Мәктәптә гимнастика түгәрәге эшли башлау да авыл өчен зур яңалык була: ишеткән, күргән нәрсәмени?! Ә Асия – гимнаст, кайчандыр киләчәген зур спорт белән бәйләргә хыялланган, инде спорт мастеры кандидаты булырга әзерләнгән. Түгәрәккә мәктәптә укучы кызларның барысы да йөри башлагач: «Кемнәрнең әйбәтрәк килеп чыга – шуларны гына калдырам», – дигән таләп куя ул. Өч ел күз ачып йомганчы узып китә.

Аннан – Бөгелмә. Укыган елларда буй җитмәслек хыял булып тоелган 2 нче мәктәп! Математиканы тирәнтен өйрәнү мәктәбе! Институтта укыган чакта остазларының берсе аңа: «Мәктәп программасы белән генә беркайчан канәгатьләнеп калма», – дип киңәш бирә. Бу киңәш аны гел алга алып бара.

Бөгелмәнең 2 нче мәктәбе Асия Фәрит кызы өчен беренче чиратта Россиянең атказанган укытучысы Сажидә Заһидуллина исеме белән бәйле. 9–10 нчы сыйныфларда математиканы тирәнтен өйрәнү программасы буенча эшләүче бу өлкән укытучы яшь белгечкә беренче көннән үк игътибар итә: дәресләренә кереп утыра, үзенекеләргә чакыра. Асиянең кияүгә чыгып, Әлмәткә күчеп китәргә җыенганын белгәч тә, иң борчылган кеше ул була: «Мин бит сине үз урыныма әзерләргә теләгән идем», – ди. Әмма яшь кәләш барысын да алдан ук хәл итә: ире кайда, ул шунда булачак. Аның ризалыгын Түземе инде болай да биш-алты ел буе сабыр гына түзеп көтте…

Әлмәтнең 18 нче мәктәбенә тикшерү белән килгән инспектор күреп ала аны. «Сезгә математиканы тирәнтен өйрәнүче класс ачарга тәкъдим итмәкче булабыз», – ди. «Бу – минем күптәнге хыялым», – дип җавап бирә ул… Дүрт җиденче класстан бер математика классы туплыйлар.

– Хәзер сөйләү генә рәхәт. Ә ул чакта… Әтиәниләр соңыннан: «Булдыра алмассыз дип уйлаган идек, – диделәр. – Кечкенә генә буйлы яшь укытучы. Кулында ике бала…» Әйе, җиңел булмады. Программа юк. Мәскәүдә, Казанда андый мәктәпләр бар иде барын, ләкин андагы укытучылар читләрне үз араларына кертми. Гадәти дәреслекләр, әлбәттә, канәгатьләндерми иде – тирәнтен белем алу өчен анда материал аз. Сатуда исә башкасы юк. Сажидә Абдулловна миңа Ефремов дәреслеген рулон килеш биреп җибәрде. Күз алдына китерәсезме? Кайсыбер битләре начар басылган – укучылар аны кулдан язды. Шундый калын дәреслек килеп чыкты. Без аны класста гына тоттык. Ул елны Әлмәт больницалары кулланган барлык флюорография пленкаларын җыеп чыктык бугай. Сажидә Абдулловна өйрәтте: укучылар белән кайнар суда юып киптерәбез дә, аннары экраннан күрсәтү өчен өстенә язабыз.

PRESSA

Японнар: «Башлангыч классларга бездә тикшерүчеләр керми: бала белән укытучы гына эшли», – дип язалар. Дөрес бу!

Сигезенче класска күчкәч, аның укучылары инде шәһәр олимпиадаларында беренче урынны яулый. (Олимпиада дигәннән. 1991–2011 елларда Асия Даешева укучыларының кайсы олимпиадаларда нинди урыннар яулавын санап чыгу да мөмкин түгел. Ул исемлек озын, бик озын!.. Шушы еллар эчендә ул математиканы тирәнтен өйрәнүче 33 классны укытып чыгарган, 9 класста сыйныф җитәкчесе булган. Кайбер класста балалар саны 34 кә җиткән! «Урын җитми, парта артына өчәүләп утыралар, әмма кире китмиләр иде», – ди.)

Инде хыялның тагын да зуррагы чынга аша: Әлмәттә математиканы тирәнтен өйрәнү мәктәбе ачыла. Дөресрәге, аны Садчикова Леокадия Александровна, Набережнова Екатерина Николаевналар белән бергәләп ачалар. Бу инде үз диңгезеңә керү кебек була: 18 нче мәктәптәге математика классларын алып, Асия Фәритовна 2 нче лицейга күченә.

– Күңелдә канәгатьсезлек бар иде... Гел бер сорауга җавап эзләдем: нигә класстагы 30 укучыдан нибары икесе-өчесе генә югары уку йортларына керә? Ул чакта түләүле группалар юк иде әле... Ә башкалар? Алар да башсыз балалар түгел ләбаса. Димәк, без укыта белмибез... Ничек барысы да төшенерлек итеп аңлатырга математиканы? Нигә безнең балалар олимпиадаларда призлы урыннар яуламый? Хәтта беренче унлыкка да кермиләр.

Алгарак китеп, ашыгып булса да әйтәм: аның иң беренче чыгарылыш классында барысы да югары белемле! Дөрес, Әлфия исемле бер кызлары физматка икенче елны гына керә. Әмма керә! «Болары кергәч, башкаларыннан шикләнмәдем дә инде», – ди ул.

Инде бу уңышка ирешүнең серләрен беләсе килә.

– Минем методикам бик гади – программадан бер адым да читкә китмим. Ниндидер сәбәп белән дәрес булмый кала икән, димәк, син бит кайсыдыр теманы ахырга кадәр тикшереп бетерә алмыйсың дигән сүз. Андый очракта директорны, завучны аякка бастыра идем: «Миңа бу сәгатьне кире бирегез!» Хәзер миңа йөрүче укучылар: «Бүген физикадан «пробник» булды, укымадык. Иртәгә – химиядән, тагын укымыйбыз. Аннары – рус теленнән», – дип сөйлиләр. «Ә программаны кайчан үтәсез?» – дим. «Белмибез», – диләр. Программаны тулысынча үтмисең икән, имтиханда 80 балл турында нинди сүз булырга мөмкин?!

Класста бер-берсенә ярдәм итә торган коллектив тудырырга кирәк. Башкаларга ярдәм иткәндә, бала үзе дә югарырак күтәрелә. Моңа ирешә алдым дип саныйм. Программа үзләштерүнең юллары төрле аның... Минем һәрвакыт унберенчеләрем унынчыларга булышты: зачет алдылар. Кем кемгә зачет бирде, консультациягә дә шуңа йөрде. Класста да бер-берсенә булышалар иде: партадашына, арттагы, алдагы, яндагы күршесенә... Таләбемне беләләр: җиде тапкыр кабатлыйсың икән – истә кала. Өйгә бирелгән эшне аңлап, класстан аны эшләп диярлек китәләр иде. Аларның шулай ярдәмләшүе бик ошый иде миңа. Ә барысы да шашка, шахматтан башланды. Ринат исемле бер егет килеп кушылды класска. Карыйм – тәнәфестә карта уйный. «Математикага булыша гына ул, Асия Фәритовна!» – ди. «Синең сүзеңә ышанмаска хакым юк, әмма без башка уенга күчик әле», – дим. Кабинетка шашка, шахмат алып куйдык. Балаларны шуннан аерып та алып булмый башлады: бу аларны дуслаштырды.

Математиканы тирәнтен өйрәнү классын яңа оештырган чаклар. Сизәм, белем җитми: миңа да, аларга да. Нәрсәдер эшләргә кирәк. Без ул чакта читтән торып берьюлы ике математика мәктәбендә укыдык. Бергә укыдык! Мәсьәләне мин чишәм, алар чишә...



Өйдә аны аңласалар, киңәшләре, гамәлләре белән һәрдаим ярдәм итеп торсалар гына хатын-кыз эшендә уңышка ирешә ала. Гомер буе үзе дә җитәкче булып эшләгән Түзем ага Асия Фәритовна өчен һәрвакыт шундый терәк була.

Мәктәпкә гел иртә килә идем. Берсендә тәрәзәгә күзем төште: кабинетымда ут яна. Сүндерергә оныттымы икәнни, дим. Соң китәм бит инде... Ишекне ачсам – балалар! Бөтен класс! Тактаны язып тутырганнар. «Ничек дәрес башлыйбыз – такта кибәргә дә өлгермәячәк», – димәкче идем, туктап калдым... Мин килгәнне көткәннәр: бәхәскә нокта куярга кирәк. Бер мәсьәләне чишү юлы буенча уртак фикергә килә алмаганнар икән.

БДИда югары баллар җыю, олимпиадада катнашучылар әзерләү укучыларың Мәскәү дәүләт университеты каршындагы мондый читтән торып белем алу мәктәпләрендә укымаса, авыррак. Укытучыга да байтак тырышырга кирәк: башта син аларны тартасың, аннары – алар сине. Соңгы чыгарылышта гына да өч егет имтиханны 98 әр баллга тапшырды: өчесе дә олимпиадаларда катнашучылар иде. Интернетта барган олимпиадаларны үзләре эзләп табарга өйрәнделәр. Сүзләре булса, сизәм: янымда бал кортлары кебек әйләнергә керешәләр. Тагын берсе чираттагы олимпиаданы тартып чыгарган димәк... «Дәресләрдән соң безнең белән кала алмыйсызмы?» – диләр. Ризалыгымны алалар да, дәрестән, курслардан соң миңа йөгерәләр. Бер үк форматтагы мәсьәләләр бирелгән була: бөтенесе утыра, чишә. Аннан җавапларны чагыштырабыз... Соңгы чыгарылыш укучыларым турында сөйләвем. Инде лицейдан китәм дип хәл иткәч, үгетләп диярлек калдырдылар. Үзенчәлекле класс иде, гаделлек өчен көрәшергә яраттылар. Туры сүзлеләр. (Сүз уңаеннан, укучылар мине һәрвакыт тәнкыйтьли дә алды. Андый хәлләр дә булды. Олы улымның классташлары: «Нигә сез һаман Ринатны ачуланасыз?» – диделәр берсендә. «Ул минем белән бер фатирда яши, аңламаган очракта сорау мөмкинлеге бар, ә ул аннан файдаланмый», – дип җавап бирдем.)

Күчерү турында башта ук әйттем инде... Әйе, бүгенге мәктәптә хәлләр бөтенләй башкача: контроль эш әле башланмаган, ә укучы анда инде нинди мәсьәләләр буласын, аларның җавабын белә. Табарга өлгермәгән икән, кемгәдер шалтырата – җибәрәләр. Бу инде 7 нче класста ук шулай. Димәк, алар уку процессын яратмыйлар. Укытучы мондый теләкне, мәхәббәтне уята алмаган. Ата-аналарда да гаеп бар: балаларын теләсә нинди юл белән математика классына бирергә тырышалар. Бала кызганыч: башында бушлык, ә аңардан гел нәрсәдер таләп итәләр.
Бу тестны яздыралар, тегесен... Тест дигәннән, башлангыч сыйныфларда тест уздыруга мин үзем каршы. Әле укый, өйрәнә башламаган, тест белән җәфалау нигә кирәк?! Алар бит мәктәпне күралмаска мөмкин. Минекеләр якшәмбе көнне дә, 31 декабрьдә дә шөгыльләнергә әзер иделәр...

...Бүген укытучының уңышын класста БДИны иң югары балл җыйган ничә укучысы булуы белән билгеләү гадәте бар. Асия Фәритовна өчен сыйфат дәрәҗәсе исә башкача билгеләнә. (Дөрес, мондый йөзәр балл җыючылар аңарда да бар: бер елны бер класста берьюлы 4 (!) укучысы математикадан имтиханны 100 баллга тапшыра.) Ул укыткан, сыйныф җитәкчесе булган классларда укучыларның барысы да (!) дәүләт имтиханын 80–90 һәм аннан да югарырак баллга тапшыру – гадәти күренеш саналган. Укытучы шуңа омтылган! Бер генә мисал: 2004 елда аның классын 28 укучы тәмамлый. Шуларның унбише – медалист! Ун – алтын, биш көмеш медаль! Аларның барысы да югары уку йортларына керүләре турында әйтмәсәм дә аңлашыладыр. Бюджет урыннарына!

– Бөтен бала да математик була аламы, дисез... Бу сорауны миңа гел бирделәр. Фән юлына ук кереп китә алмыйдыр, билгеле... Ә менә укучыдан яхшы медалист әзерләргә тотынганчы, башта аның нәселен белергә кирәк. Улыңны өйләндергәнче, кызыңны кияүгә биргәнче каршы якның бөтен нәселен өйрәнәсең бит – монда да шулай. Әти-әнисе, әби-бабасы кемнәр, укуга мөнәсәбәтләре нинди булган? Ни дисәк тә, геннар зур роль уйный.

Математиканы тирәнтен өйрәнү классында укучыларның барысы да математик булып китми, әлбәттә. Әмма бу сыйныфларда белем алган укучылар, киләчәктә кайда гына эшләсә дә, башкалардан аерылып тора. Аларда белемне эзләп алу ихтыяҗы бар. Безнекеләр – һәр өлкәдә чын белгеч!

БЕЛЕШМӘ

1994 елда Америка миллиардеры Джордж Сорос мәгариф өлкәсендә Халыкара премия булдыру турында игълан итә. Ул премия физика, математика, биология, һәм химия юнәлешендә эшләүче галимнәргә, укытучылар, студентлар һәм укучыларга ярдәм итү максатыннан оештырыла. Сорос премиясенә ия булу бүген дә укытучылар арасында иң зур дәрәҗә дип санала, чөнки бу – аларга укучылары биргән бәя. Премия тапшыруның тәртибе болай. Россиянең йөзгә якын югары уку йортларында белем алучы I–III курс студентлары арасында сораштыру үткәрелә: «Мәктәптә үзегезнең иң яхшы укытучыгыз дип кемне саныйсыз?» 1996 елда, мәсәлән, бу сораштыруда 80 мең студент катнаша. Җаваплар аноним рәвештә бирелә, шунда ук компьютерга кертелә, аның нәтиҗәсенә беркем тәэсир итә алмый: җитәкчелек бу эштә катнашмый. Икенче этапта анкетада исемнәре берничә тапкыр кабатланган укытучылар сайлап алына. Өченче этапта бу укытучылар махсус анкета тутыра: аларның уңышлары рәсми документлар белән раслана. Туксанынчы елларда Сорос фонды премиясе күләме укытучының берничә еллык хезмәт хакы кадәр булган.

«Ризасызлыгымны иҗатым аша җиткерәм»

Яшь язучы, драматург Сөмбел ГАФФАРОВАның тормыш кагыйдәләре



ӘТИ-ӘНИЕҢ ТАНЫЛГАН КЕШЕЛӘР БУЛУ БАРЫБЕР НИНДИДЕР ИШЕКЛӘРНЕ АЧА УЛ. Син үзгә бер мохиттә, исемнәре билгеле кешеләр даирәсендә яшисең. Әнием тарихчы-галимә Фәридә Гаффарова мине журналистлар, галимнәр дөньясына кертеп җибәрде. Әти иҗатка якынайтты, әтигә карап яза башладым. Заманында, ышанмыйча: «Әтисе язып биргәндер», – дигәннәрен ишеткән бар иде. Кайчандыр миңа «Әхәт Гаффар кызы» дип караган булсалар, хәзер әтигә «Сөмбел Гаффарова әтисе», диләр икән.

12 яшьләремдә әти миңа язучы Гариф Ахуновлардан ак песи алып кайтты. Танылган язучы белән шулай «туганлаштык». Шигырь бәйрәменең берсендә язучы-шагыйрьләр имзалары куелган зур агач каләм бүләк иттеләр. Автографлы китаплар... Танылган шәхесләр белән бергә төшкән фотолар... Миңа 7-8 яшьләрдә гаиләбез белән Латвиядә, язучыларның Дубулты иҗат йортында ял иткән идек. Бөтен Советлар Союзыннан ялга килгән язучылар, аларның балалары белән аралашып йөрүләр... Соңыннан Якутск, Ташкент, Мәскәү кызлары белән хатлар алыштык. **АРАЛАШУЛАР ОФЫКЛАРЫМНЫ КИҢӘЙТТЕ.** Атаклы татар гимназиясе, «Сәләт» оешмасы, мәктәптә укыганда ук «Ялкын» журналында эшләвем, университетта укыган еллар, Төркиядә белем эстәүләр, шушы «багаж» белән «Сөембикә» редакциясенә килүем... Болар язмышыма зур йогынты ясады.

Янгын сүндерүче, детектив, тележурналист, җырчы, тагын әллә кемнәр булырга хыялландым. Актриса булырга хыялланмаган кыз юктыр да ул!.. Драматургиягә кереп китүем боларның барысына да якынайтты – **ПЕРСОНАЖЛАРЫҢ АША ТЕЛӘСӘ КЕМ БУЛА АЛАСЫҢ.**

Әнинең «тәрбияви күз карашын» онытырлык кынамы соң?! Кылган гамәлемнән риза булмаганда, кашын җиңелчә җыерып бер генә карый – барган җиремнән туктап калам, басып торган җиремнән йөгереп китәм. Безне тәрбияләгән вакытта психологлар да, махсус телевизион тапшырулар да булмады бит. Әмма начар булып үсмәдек. Сере, мөгаен, чиксез яратудадыр. «Үз балаларың булгач, аңларсың мине. Син әйләнеп кайтканчы ут йотам!» – дип әйтүләрен хәзер генә аңлый башладым. **ӘНИ ЙӨРӘГЕ ГЕЛ СЫЗЛЫЙ ИКӘН УЛ: АВЫР ЧАКТА ДА, ТЫНЫЧ ЧАКТА ДА.**

Әниемне бик юксынам. «Кызым, мин сине шулкадәр яратам! Әйдә, кочаклашып утырыйк әле», – дигәннәре әле дә колагымда... Шул сүзләре искә төшкән саен күземә яшьләр килә. Әниемне белмәгән-күрмәгән кызым Суфия көн саен диярлек: «Әнием, кочаклашып утырыйк әле», – ди. Каян сизә диген! **КЫЗЛАРЫМА ӘНИЕМ СЫМАН ӘНИ БУЛА АЛСАМ ИДЕ!**

ӘТИ МИНЕ ӘКИЯТ ДӨНЬЯСЫНА АЛЫП КЕРГӘН КЕШЕ. Фантазия, үзгә фикер йөртү – барысы да аңардан килә. Өч куллы пәлтә, шалкан койрыгы дип белеп, үз койрыгын кимергән күсе, юынмый торган балык... Бу әкиятләре башкача уйларга өйрәтте. Әти Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегендә эшләгәндә без Әлмәттә яшәдек. Ишегалдыбызда зур бер агач үсә иде. Мин әле бәләкәй чак. Әти бер кичне: «Мин шушы агачта үстем бит», – дип сөйләп китте. Ул әйтте дә онытты, ә ул картина әле дә күз алдымда. Балалар өчен язган «Чынга ашачак хыял» повестемда өе агачта булган бер йомран бар. Әти менә шул геройның прототибы!

ЛӘЙЛӘ АПАМ МИНЕМ ӨЧЕН ИҢ ЗУР АВТОРИТЕТ. Балачакта әни миңа шаярып кына үпкәләп тә куя иде хәтта – берәр эшкә тотыныр өчен әнинең рөхсәте генә җитми, апамның «ярый» дип хуплавы да кирәк була иде бит. Ул – тәрҗемәче. Күп нәрсәне белә, аңлый, анализлый. Мин аңа сокланам. Үз эшенең чын остасы ул!

Күз алдына китерегез: Казанның Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясендә матур бәйрәм бара. Бер кыз бала үзенең «Безнең-сезнең заманда» дигән әкиятләр китабын чыгарган – шуның презентациясе! Һәм ул мәҗлескә аксакал язучы Әмирхан ага Еники үзе килгән! Кыз бала – 10 нчы сыйныф укучысы Сөмбел Гаффарова! Яраткан язучым Әмирхан Еникиның китабым презентациясенә килүе минем өчен һаман төш сыман. Миңа ихтирам күрсәтеп, Сөмбел туташ дип дәшүләре, сәхнәгә менеп кулымны үбүе, аерым бер нәзакәт белән чәчәкләр тапшыруы – беркайчан онытылмас! **«ЯЗАРГА ӨЙРӘНЕП БУЛМЫЙ, АНЫҢ МӘКТӘБЕ ЮК. УЛ ХОДАЙ ТӘГАЛӘДӘН БИРЕЛӘ ТОРГАН СӘЛӘТ»**, – дигән сүзләре күңелгә уелып калган.

Татар әдәбияты укытучыбыз Флера Рәис кызы: «Миңа сезнең китап сүзләре белән җавап бирүегез кирәкми. Иң мөһиме – фикер йөртү! Шәхес булу!» – дигән иде. **БЕЗ – ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ӨМЕТЛЕ КИЛӘЧӘГЕ ДИГӘННЕ СЕҢДЕРДЕ ГИМНАЗИЯБЕЗ.**

Иң зур әдәби тетрәнүне мин мәктәп елларында Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ын укыганда алдым. Шунда әсәрнең баш героеның нинди булырга тиешлеген аңлап, персонажларның эчке дөньяларын, каршылыкларын күреп таң калган идем. Бу минем өчен зур һәм әһәмиятле ачыш булды. **КЕШЕЛӘРНЕ ЯХШЫ ҺӘМ НАЧАРЛАРГА АЕРУ МӨМКИН ТҮГЕЛ ИКӘН.**

«КИЛМЕШӘК» – ТОРМЫШЫМДАГЫ ИҢ ЗУР УҢЫШЛАРЫМНЫҢ БЕРСЕ. Балачактан ук мин яраткан Люция апа Хәмитова уйнасын әле! Режиссерым Фәрит абый Бикчәнтәев үзе булсын әле! Яңа ел теләкләре чынга аша икән – нәкъ шушы ике кешегә якынаюымны үземнең теләгем итеп пышылдаган идем бит. Пьесадагы төп героем Нәкыйпкә – дәү әниемнең сугышта хәбәрсез югалган абыйсына үзенә күрә бер һәйкәл дип уйлыйм «Килмешәк»не. Дәү әнием спектакльне күрергә өлгерсә, ни дияр иде икән дип хәзер дә уйланам.

ҮЗЕМ ӨЧЕН ШУНЫ АЧТЫМ: ЯНӘШӘҢДӘ ШӘХЕС АТЛЫЙ ИКӘН, АЛГА ТАБА АДЫМЫҢНЫ ВАКЛАМАСКА – КИҢ АТЛАРГА ТИЕШ СИН. Г. Камал театрында Равил Шәрәфинең үз юбилеенда «Килмешәк» спектакленә карата сүз әйтүе мине җирдән аерып күккә менгерде.

Фото: Анна Арахамия

Драматургия – ул тормыш. Бүгенге тормышыбызны, ул тормышта мин риза булмаган нәрсәләрне сурәтләү... Абсурдист Самуэль Беккет, Эжен Ионеску әсәрләрен укып, үзем өчен драматургиядә юл сайладым. Хәзер һәр әсәремдә абсурдизм, символизм урын ала. Геройларым – үземнең замандашларым. Үземне борчыган темаларны күтәрәм. «Мин дөньяны үзгәртәм!» дип яши башлыйсың, ә адым саен синең идеалларыңа каршы кешеләрнең күбрәк булуы ачыклана. Үзгәртеп булмаса да, нидер эшләми кала алмыйм – **РИЗАСЫЗЛЫГЫМНЫ ИҖАТЫМ АША ҖИТКЕРӘМ.**

Кечкенә чакта әни белән концертка барган идек. Шунда салма-а-ак, озы-ын җыр яңгырады. Ак шәл ябынган бер әби, онытылып, җыр тыңлый, күзләреннән яшьләре ага... «Аба-ау! Җыр тыңлап ела инде!» – дип бик гаҗәпләнгәнием истә. Ә хәзер беренче карашка бик гади текстлы халык җырлары да җанымны актарып, астын өскә китерә. **ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНДАГЫ ЭНЕРГЕТИКА, АКЫЛ, МОҢ КАТАРСИС КИЧЕРТТЕРӘ, КҮҢЕЛЛӘРНЕ ЧИСТАРТА, ИҖАТ ИТӘРГӘ ЭТӘРӘ.**

ИЛҺАМ ЯЗГАН ВАКЫТТА ГЫНА КИЛӘ. Язганда кәефем яхшыра, күңелем күтәрелә. Язсам, өйдәгеләргә дә яхшырак. Минем өчен иң мөһим фактор – өй җыештырылган булу. Бүлмәдәге тәртипсезлек ачуымны чыгара. Компьютер артына утырып, шундук гениаль юллар сиптерә башлыйсың дигән сүз түгел бит әле. Фикер тупларга, күзне йомып башка халәткә күчәргә, геройларың янына күченергә кирәк.

ХАТЫН-КЫЗНЫҢ БӘХЕТЕ ГАИЛӘДӘ ИКӘНЕН АҢЛАДЫМ. Иҗат, эш – болар барысы да яхшы, алар сине алга этәрә, кызыклы шәхес итә. Әмма балаңны кочып утыру мөмкинлегенә ия булган хатын-кызлар никадәр бәхетле!

Ирем Дмитрий минем ялгыш һәм ялгыш булмаган татарча әйтеп куюларымны күп очракта аңлый. Аңламаса, тәрҗемә итеп сеңдереп куям. Ачуым чыкканда татарча әрләп, дулап, тузып алам. Икебезгә дә рәхәт: мин дә шартламый калам, ул да аңламый, елмая. **БӘХЕТЛЕ, ТЫНЫЧ ГАИЛӘ СЕРЕ – ВАКЫТЫНДА ТЕЛНЕ ТЕШЛӘП, ДӘШМИ КАЛА БЕЛҮДӘДЕР.** Икең бергә дуласа, талашып, кирәкмәгән ялгыш сүзләр ычкындыру куркынычы бар.

Үпкәләшкән, ачуланышкан чаклар сирәк булса да булгалый, әлбәттә. Кайчакларда мин аңа эчемнән генә дулап йөрим, инде уемда без аерылышып, балаларны бүлешәбез. Мәңгегә ташлашабыз. Аннары ул уем томан кебек эреп юкка чыга. Ситуациядә казынып алам да, ирем өйгә кайтканда яки күрше бүлмәдән чыкканда инде без «туй уздырып» бәйрәм иткән булабыз... Хәзер гаилә иминлеген сакларга өйрәтүче төрле тренинглар, коучлар бар. **МИҢА КАЛСА, ИҢ ДӨРЕС КОУЧ – АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ УЛ.** Аның сүзеннән чыкмасаң, бәхетле булырсың.

КЫЗЛАРЫБЫЗГА МӘГЪНӘЛЕ, ИКЕ ТЕЛДӘ ДӘ МАТУР ЯҢГЫРАШЛЫ ИСЕМ ЭЗЛӘП КУЙДЫК. Суфия һәм Гайшә (документта Аишә). «Сәләт»тә әйдаман булганда анда бер кызның Суфия исемле икәнен белдем. Уф, балага шушындый исем бирәләрме инде дип уйлап куйганым истә. Аишәләр исә Төркия тулы иде, сирәгрәк исем табалмыйлар микәнни дип аптырадым... Ә үзебезгә менә нәкъ шушы фундаменталь, кешелек тамырында урнашкан исемнәргә тукталырга туры килде.

МИН – ТАГАН ШИКЕЛЛЕ ӘНИ. Бер мизгелдә шаян һәм киң күңелле була алам, аннан сабырлыгым чиләктән түгелеп, шундук кызып та китәм.

КАЙНАНАМ АЛТЫН МИНЕМ. Тормышы гөрләп тора аның – эше, гаиләсе, бакчасы, хоббилары дисеңме... Без аларга кунакка кайткач, чып-чын бәйрәм ясый: Суфияне командасына алып, конкурс-бәйгеләр оештыра. Безне йөгертәләр, төрле биремле уеннар уйнаталар! Бабай да сикерә, бабайның апасы да сикерә, ирем дә сикерә... Суфия шушындый тату, күңелле мохиттә үсә.

БАШКАЛАРНЫҢ СҮЗЕНДӘ ТОРА БЕЛМӘВЕ ЧЫГЫРДАН ЧЫГАРА МИНЕ. Башта аптырап калам, аннан дулый башлыйм. Апам тәрбиясе инде, ул мине шулай үстерде – берәр нәрсә вәгъдә иткән булса, һичшиксез сүзендә тора! Һәм мин гомер буе башкалардан да шуны көтәм, үзем дә ялганчы булып калмаска тырышам.

Бәйләргә, энҗе-мәрҗәннәрдән муенса, беләзек, алкалар ясарга яратам. Минем өчен иң яхшы ял ул. **СӘЙЛӘННӘР САЙЛАП, НИДЕР ЯСАГАНДА ҮЗЕНӘ КҮРӘ НИНДИДЕР ӘКИЯТ, КАРТИНА УЙЛАП ЧЫГАРАМ.**

МИН КӨЛДЕРЕРГӘ ЯРАТАМ. Көлү, юмор хисе кешене коткара: куркуларыннан арындыра, авыруларын дәвалый, кәефен күтәрә... Әгәр театрда роль уйнау мөмкинлеге булса, ике дә уйлап тормыйча Мюнхгаузенны сайлар идем.

Ялганлый белмим. Дөресен әйтеп, үземә начар буласын белсәм дә, ялганламыйм. **КЕШЕГӘ АВЫР СҮЗ ӘЙТМИМ. БЕРКАЙЧАН ДА.** Үземә начар мөгамәләдә булсалар да, аларга шулай ук итеп җавап бирә алмыйм. Бәлки, кайгысы бардыр, берәр күңелсезлек килеп чыккандыр дип, аны аклый башлыйм, гафу итәргә тырышам.

ҮЗЕМНЕ ҺАМАН 20 ЯШЬЛЕК КЫЗ КЕБЕК ХИС ИТӘМ. Фәкать тормыш шартларым, ролем генә башка. Әни, ир хатыны ролендә җаваплылык өстәлде, күпмедер дәрәҗәдә акыл, тормыш тәҗрибәсе тупланды... Кайчак үземне балалар бакчасы мәйданчыгында уйнап йөргән, гимназия коридорларыннан йөгереп узган, университет фестивальләрендә кайнаган кыз итеп күз алдыма китерәм. Әйлән дә кайт икән шул ваемсыз чакларга!.. Юк, булмый шул. Шуңа төшенгәч, бермәл үземне алданган сыман хис итеп куям. Ләкин моңсуланып торыр чакмы?! Суфиябез балачак белән тоташтырып тора.

Эльмира ЗАКИРОВА әзерләде.



« Тулысынча сайтыбызда: www.syuyumbike.ru

ФОТОПРОЕКТ: «ОБЪЕКТИВТА – ӘНИ»



Фото: Лилия НАСРЕТДИНОВА. Оренбург.

Бер мизгел.
Фоторәсемгә әйләнгән бер мизгел.
Ана белән Баланы кабат-кабат үткәнгә: шушы көнне, шушы сәгатьтә кичергән Бәхеткә, ул чактагы хис-тойгыларга алып кайтачак әле ул. Әни – җир йөзендәге иң кадерле кеше дип искәртеп торачак. Шатлыкларыңа аның кебек сөенүче башка берәү дә булмаячак, борчу-хәсрәтеңне ул гына үзенекеннән зуррак итеп кабул итәчәк. Аңлаячак, кичерәчәк, канат куячак... Яратачак! Бернигә карамый! Гомер буе...
«Объективта – әни» конкурсы тәмамланды, әмма проектыбыз дәвам итә.
Фотосурәтләрегезне көтәбез: гомер альбомындагы ул мизгелне безнең белән дә бүлешегез!
Иң уңышлы эшләр журнал битләрендә дөнья күрәчәк.


Фото: Анна Арахамия

«Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас», – дип яза Ризаэтдин Фәхретдин. Ә менә балаң кечкенәдән халыкара, республика конкурсларыннан кайтып кермәгәндә тәрбия дилбегәсен ничек дөрес итеп тотарга соң?! Җиңү һәм җиңелүләрне зирәк итеп ничек уза белергә?

Раилә ХӘЯЛИЕВА

«ҮЗ КӨЧЕҢӘ ЫШАНЫРГА КИРӘК!»

– Балаларга төрле ярышларда, конкурсларда катнашу күп кыенлыклар тудырса да, киләчәк үсешләре өчен шактый файдалы дип уйлыйм, – дип сүзен башлады Азалиянең әнисе. – Балада үз-үзенә ышаныч хисе арта, яңа төрле стимуллары барлыкка килә, дөньяның киңрәк, иркенрәк икәнлеген күрергә өйрәнә, үз өстендә эшли башлый. Күбрәк белүнең, камилләшүнең файдалы икәнлеген аңлый ул. Һәм, әлбәттә, әни кешедән дә күп нәрсә тора: баланы конкурсларга ахыры нәтиҗәле булырлык итеп әзерлисең, җиңүне дә, җиңелүне дә дөрес итеп кичерергә өйрәтәсең... Иң авыры – күп көч куеп әзерләнгәннән соң да җиңелеп өйгә кайткач, баланы киләсе бәйгеләргә янәдән илһамландырып җибәрү. Шулай да мин кызыма һәрвакыт: «Тырышкан табар – ташка кадак кагар», – дип кабатларга яратам. Теләге булган һәркем алга барырга тиеш, ләкин мондый конкурсларга күңеле ятмый торган балаларга зур үрләр яулатам, дип психологик травма ясаудан да сакланырга кирәк. Безнең җиңүләребез дә, җиңелүләребез дә күп булды бит. Бала ярыш-бәйгеләрдә уңышсыз чыгыш ясаганда аны да, жюрида утыручыларны яки башка катнашучыларны да гаепләп калдырырга ярамый. Җиңелүне кабул итә белү дә бер тәҗрибә бит! Бала белән бергәләп уңай якларны, өстенлекләрне барларга, чыгышының төрле урыннарын утырып анализларга кирәк. Җиңелгәндә дә баланың үз-үзенә бәясе төшәрлек булмасын. Аның бит әле алга таба барасы,

тагын да яңа үрләр яулыйсы бар. Нишләп алай килеп чыккан – төп проблемаларны билгеләргә кирәк, балага үз хисләрен тәртипкә китерергә вакыт бирергә, анализларга... Җиңелүдән курыкмауны, алга баруны максат итеп куярга тырышабыз без. Бала өчен иң мөһиме – үзен ничек бар, шулай итеп яратуларын белеп торудыр. Кызыбызның уңышларына да бергәләп шатланабыз, киләчәккә яңа баскыч дип кабул итәбез аны. Җиңүнең нигезенә берничә еллык тырышлык, ихтыяр көче салынган була. Мин һәрвакыт менә шул процессны билгеләп узарга тырышам. Азалия ниндидер эшкә алынса, ул аны 150% үтәп чыгарга тырыша. Шунысы да бар: һәртөрле бәйгеләрдә катнашканда уйламаганда-көтмәгәндә әллә нинди каршылыклар килеп чыга безнең. Йә тамак шешә, йә температура күтәрелә, йә көтелмәгән проблемалар килеп туа. Бу сынауга да ияләштек бугай инде.

Гөлназ Хисамиева белән сөйләшүебезне балалар өчен оештырыла торган конкурслардан башлап җибәрүебез юкка түгел. Аларның өлкән кызлары Азалиянең катнашмаган конкурс-ярышы калдымы икән әле?! Кече яшьтән үк башланган җыр-бию, матурлык конкурслары, фәнни конференцияләр... Азалия – Казандагы 180 нче гимназиянең 10 нчы сыйныф укучысы. Узган ел ул Казанда узган «Татар кызы» конкурсының җиңүчесе булып та танылды. Әтисе Рөстәм белән әнисе Гөлназ аның турында сүзне: «Ул безнең студент баласы булды», – дип сөйләүдән башладылар. Медицина университетында укучы әтисе белән әнисенең мәхәббәт сынаулары узганын көтеп торган да, туйлар узып, нәкъ бер ел үтүгә, алтынчы курста дөньяга килгән. Яшь әнинең зачет-имтиханнары елак төннәр аша бирелгән, лекцияләрне утырып түгел, басып кына тыңлаган вакытлар да булган. Әтнәдән килгән дәү әнинең дә, Әлмәт дәү әнинең дә назы тигән кызчыкка, туган апалар, хәтта күрше апасының да өлеше кергән! «Шуңадырмы, кечкенәдән бик җаваплы, җитди булып үсте ул безнең», – ди әти-әнисе.

Әниләрнең амбицияләре беренче урында булырга тиеш түгел, иң мөһиме – бала.

Гөлназ белән сөйләшүне дәвам итеп, балаларның актив тормышы, түгәрәкләр темасына күчәбез.

– Вакыты бушка узмасын дип кенә баланың көннәрен төрле түгәрәкләр белән тутыруны хупламыйм. Баланың кай якка үсәсе килә, нинди мавыгулары бар, менә шуны аңларга тырышырга кирәк. Безнең икенче кызыбыз Айзания менә хайваннар ярата, бик матур итеп рәсемнәр ясый. Атлар янына алып барыгыз, дип тә күптән сорап йөри иде инде. Башта курыктым, аннан килештем. Ипподромда әле берничә генә ай шөгыльләнсә дә, тәҗрибәле җайдаклар белән бергәләп чыгыш ясый ул хәзер. Атларны яратып карый, юа, чистарта, алар белән үзе генә белгәнчә җайлап аралаша. Ә менә кечкенә улыбыз Рамазан бик хәрәкәтчән, туганда ук тимер кебек нык булып туды. Бокс белән кызыксына. Анда йөрергә әлегә иртәрәктер, дидек тә, әтисе белән килешеп, әлегә футболга бирдек. Өч бала – өчесе дә төрле табигатьле. Без аларның һәрберсен ничек бар, шулай кабул итеп яратабыз. Ни генә булмасын, балага төп тәрбия гаиләдә салынырга тиеш дип уйлыйм. Тормыш өлгесе – әти белән әнинең бер-берсен яратуы, хөрмәте булганда, киләчәктә бала үзен бәхетсез хис итмәс. Без кечкенә чакта әни безгә ни булса да «әтиегез!» дия торган иде. Кирәк сүзне аңларга әтинең бер карашы җитте. Мин дә балаларны шул үрнәктә тәрбияләргә тырышам. Гаиләдә әти кешенең дәрәҗәсе зур булырга тиеш! Балаларның әти-әни нигезенә кайтып, дәү әти, дәү әни кочагында мәйханә килеп үсүләре дә бик мөһим. Үзем дә балачакта, «кубанка» бүреген киеп, радиодан Илһам Шакировны тыңларга яраткан Гыйлемхан бабам янында еш булырга тырыша идем. Минем озын толымнарыма карап, ул һәрвакыт: «Кызлар күрке – озын толым, чәчләреңне кисмә», – дия торган иде. Бабай сүзе бер дә истән чыкмады, чәчләремне кистермәдем. Кызларым да озын толымлы. Әниемә охшаганбыз. Әле безнең туй вакытында кыз алырга килгәч, Рөстәмгә «110 – нәрсә ул?» дип бер табышмак биргәннәр иде. Бик озак уйлагач, Рөстәм дөрес җавапны әйтте. Минем әнинең чәч толымы озынлыгы иде ул. Әйе, без – озын толымлы кызлар нәселеннән, анысы да бит татар кызлары өчен бер горурлык. Хәзер шәһәрдә чит телләрне кушып сөйләшәбез бит инде. Ул проблема белән күпләр очрашадыр. Беркөнне шундый нәрсә укыдым: үз туган телеңә чит тел сүзләрен кушып сөйләү – хәләл ризыкка хәрамне кушып ашаган кебек, диелгән иде. Бу сүзләр миңа бик нык тәэсир итте. Азалияне дә, Айзанияне дә көчле татар төркеменә күчердем. Татар теле укытучыларына бик рәхмәтлебез. Гимназияләрендә чып-чын татар мохите.

Сүзгә Азалия кушыла:

– Беләсезме, татулык яшәгән гаиләдә үсү зур бәхеттер ул! Әти безнең өчен гел тырыша, ә әни – минем тормышымдагы иң ышанычлы кешем. «Татар кызы» конкурсына да бергәләп әзерләндек. Нәкый Исәнбәтнең без сәхнәләштерергә тиешле «Миркәй белән Айсылу» әсәрен дә елый-елый бергәләп укып чыктык. Әни – бик максатчан минем, бер эшне дә ярты юлда калдырмас. Ул безне бернигә дә өмет итмичә, максатка үз көчебез белән ирешергә өйрәтә.

«Татар кызы» конкурсында катнашу миңа нәрсәләр бирдеме? Халкыбызның бик матур йолалары, гадәтләре барлыгын белдем, милли ризыклар тарихы белән таныштым. Милләтем турында тагын да күбрәк мәгълүмат җыя алуыма, яңа тарих битләре ачуыма мин бик шатмын!

ЭХ, ПОШАЛЫМ ЧАНАСЫ!



Лилия ГӘРӘЕВА

Заманында бу авылда кулына балта-пычкы тотмаган кеше булды микән?! Гомер-гомергә атаклы балта осталары төбәге бу. Кукмара ягы иң элек – җылы киез итекләре, Балык Бистәсе – күпереп торган мамык шәлләре, Саба – көмешчеләре, Буа кишер үстерүчеләре белән данлыклы. Ә Тукайлы, Мәрҗаниле, Мәһдиевле Арча ягы исә элек-электән чана-арба ясаучылары белән дан тоткан. Пошалым чаналары – Казан артының бер бренды инде ул. «Шакы-шокы Пошалым» дип, халык кушкан атамасы да юкка түгел Югары Пошалымның. «Бу авылның ир балалары кулына кашык тотканчы, башта чүкеч тотарга өйрәнә», – дип тә шаяртталар.





Әгәр дә ниндидер эшне эшләргә язган икән, белмәсәң дә өйрәнәсең. Үзеннән-үзе күңелгә килә ул.

Безнең героебыз да беренче тапкыр кулына кадакчүкечне алтынчы сыйныфта укыганда ук ала. Ниндидер уенчык-мазар ясар өчен түгел, ә чын ирләрчә, арт бакчага янкойма тотарга дип алына. «Берүзем эшләп чыктым шуны. Каен аратага кадак кага алмыйча бармакларымны канатып бетергән идем. Кипкән каен тактага кадак кагуның ни икәнен эшләп караган кеше белә инде», – дип искә ала ул.

Ике табан, өч карама

Моңарчы өстәл-урындыклар, тәрәзә йөзлекләре ясаса да, чанага ук тотынып караганы булмаган Рәдиф Нигъмәтуллинның. Дөресен генә әйткәндә, инде ул чаналарга ихтыяҗ да, чаначылар-арбачылар авылы дип дан казанган Югары Пошалымда аны җиренә җиткереп ясый белүчесе дә калмаган булган. Булганнары бармак белән генә санарлык – Равил абый Галәветдинов та Фаил Шәрәфиев...

2004 елда Татарстанның халык җырчысы Рөстәм Закиров «Пошалым чаналары» конкурсын уйлап чыгармаса, әлеге һөнәр шулай кирәксез булып калыр, онытылыр иде, мөгаен. Рәдифнең чана ясау остасы булып китүенә дә шушы конкурс «гаепле» дисәк тә, останың үзе әйтүенчә, әлеге нияте күңелендә күптән йөргән инде аның.

Балта эшенә беркем өйрәтмәсә дә, бу һөнәр канында Рәдиф Нигъмәтуллинның. Хәким бабасы да тарантаслар, бәби бишекләре ясаган аның, Шәйхетдин бабасы да чана табаннары бөккән.

Әлеге эштә иң четереклесе дә шушы – чана табаны бөгү икән инде.

– Чана табанына имән кирәк, ул иң нык агачларның берсе, – дип аңлата оста. – Табан бөгәргә имәннең дөрес итеп пешүе мөһим.

Безнең гаҗәпләнгәнне күреп, көлемсери үзе.

– Элек аның сыйфатын белү өчен бабайлар чәйнәп тә караганнар әле. Пешүе җиткән имән җиңел бөгелә. Ә менә пешүе җитмәсәме?! Инде булды, бөгелде генә дисең, дугаланып килгән урыннан «шарт» итә дә сынып китә. Шуңа да бу эш чана ясауның иң җаваплы, иң теңкәне корыта торган өлеше.

Чана ясау элек кулланышта булып, хәзер онытыла барган сүзләрне дә искә төшертә. Әйтик: үрәчә. Бу сүзне өлкәннәр белсә дә, яшьләр ни икәнен дә аңламый. Үрәчә – арба яки чананың як-ягында буйга сузылган агач ул. Анысын юкәдән ясыйлар. Үрәчә белән табанны үзара беркетер өчен имән кигиләр дә кирәк әле. Алары – алтау. Ике үрәчәне карама тоташтыра. Анысы, исеме үк әйтеп тора, карама агачыннан ясала.

– Менә бу карамаларны ноябрь аенда урманга менеп үзем әзерләдем, – дип, остаханәсендәге әзер материаллар белән таныштыра оста. – Теләсә кайсы агачны кисәргә ярамый, рөхсәт булганнарын гына кисеп алып төшәбез. Карама булмаса, шомырт та ярый, алар икесе дә җиңел бөгелә. Балалар чанасы өчен карама өчәү кирәк.

Боларга өстәп алгы һәм арткы терәкләр, арка терәгеч, канатлар, араталар һәм чананың төбе әзерләнә. Бизәкле канатларга, терәкләргә сокланып: «Кем ясый бу рәсемнәрне?» – дип сорау биргәнебезне тоймый да калабыз.

Әкияттән кебек

Нәзирә белән Рәдиф Нигъмәтуллиннар – авылда үрнәк гаиләләрнең берсе. Өч бала үстерәләр. 5 яшьлек Даниярның әле кул арасына керә генә башлаган мәле, ә Рамилә белән Дәниф инде әти-әнисенең уң кулы. Үзләре белән танышканчы ук: «Чаналарны бөтен гаиләләре белән ясыйлар: хатыны да ясый, кызы да...» – дигәннәр иде алар турында. Дөрес әйткәннәр!

Бавыннан тартып, әкиятнең үзеннән алып чыккандай тоела миңа Рәдифнең чаналары. Берсеннән шат куян баласы карап тора, икенчесенә мут төлке кызы елышкан, аю малае да бар монда, бүре малае да... Терәкләрендәге рәсемнәрен генә карагыз! Боларны күргәч, балаларның күзе кызадыр инде! Бая биргән соравыбызга җавап та табылды: уллары Дәниф рәсемен ясый, әниләре Нәзирә белән Рамилә буйый икән.

– Рәсем төшерү, аны буяу – табан бөгү кебек четерекле эш ул, – ди оста үзе дә. – Тиз кибә торган нитробуяулар кулланабыз. Өйдә аның белән эшли торган түгел, шуңа да эш «кабинет»лары мунчада. Белмим, үзләре ничек чыдыйдыр, яннарында бераз утырсаң, хәзер башка каба.

Бизәкләр турында сүз чыккач, укытучыларының Дәниф турында «рәссам егетебез, рәсемне коеп кына куя», дигән сүзләре искә төшә. Узган ел Казанда узган «Динас-

Фото: Анна Арахамия

Көнкүрешебезгә пластик ныграк үтеп кергән саен, табигыйлекнең кадере арта гына бара кебек.



■ «Бизәк төшерергә утырсам, үзем дә балачагага әверелә. Чаналарны иң якты, иң матур төсләргә генә буйыйсым килә: күрүгә, балаларның күзләре янарлык булсын», – ди Нәзирә ханым.

тия мастеров» конкурсында беренче урынны алып кайткан алар. Җиңүгә ирешүдә Дәнифнең таланты да роль уйнамый калмаган.

Булганнан бар да була

Остаханәне калдырып, мәчеткә юнәлəбез. Өйлә намазы якынлаша. Чана ясау – Рәдифнең бер хоббие генә. Төп эше – газ оешмасында. Болардан тыш, авыл халкы тагын бер зур вазыйфа йөкләгән аңа: Рәдиф – Югары Пошалымның имам-хатыйбы. Дин белән әле армиядә вакытта ук кызыксына башлаган.

– Үрнәк бистәсендә пекарняда эшләгәндә, күршедә генә Сәүбән исемле абзый яшәде. Бик дини кеше иде, ислам диненә тартылуымда аның да йогынтысы бар, – ди Рәдиф хәзрәт үзе.

Авыл картлары имамлыкны аңа 2014 елда ук тәкъдим итсәләр дә, үзе ике елдан соң гына ризалаша. «Мәчетебезнең бөтен документациясен тәртипкә китерде, кулы эш белгәч, кагасын – кагып, төзәтеп кенә тора. Чишмәләребезне карап торучы да ул», – ди авылдашлары. «Киңәшкә дә ярый, сүзе дә үтә Рәдифнең», – дип тә өстиләр.

Авыл халкы мәчет сукмагына кар төшерми: дин дәресләре үзләштерә, Коръән укырга өйрәнә. Наилә абыстай Арчадан ук килеп, гарәп теленә өйрәтә икән. Моның өчен дә Рәдиф хәзрәткә булган рәхмәтләрен яшермиләр.

Һәр авылның үз бизәге

– Бу авылда халык беркайчан да ярлы яшәмәгән, – дип сөйли Югары Пошалым башлангыч мәктәбе укытучылары Гөлфинә Шәйдуллина белән Гөлсинә Шәкүрова.

– Мин үзем дә шушы авыл кызы. Бездә чана гына түгел, орчыклар, көянтәләр, ат арбалары, бала бишекләре, йорт җиһазлары да ясыйлар иде. Бизәкләп, сырлап-сырлап эшләнгән ул матур орчыклар кемдә дә булса сакланды микән хәзер? Безнең авыл осталарының үзләренә генә хас бизәкләре бар иде. Таң беленгәнче үк чаналарын тартып, Апаз базарына тезелешеп китүләре әле дә күз алдымда, – дип сөйли Гөлфинә ханым. – Өй саен ясыйлар иде бит. Безнең авыл осталарының даны еракларга таралган иде. Авылга килеп, чанасылар монда яшиме, дип сорап йөргәннәрен хәтерлим.

Гөлсинә Шәкүрова да борынгы һөнәрнең кабат җанлануына куана.

– Әлегә чана ясаучы осталар өчәү генә. Өйрәнәсебез килә диючеләр бар. Минем улымның да тотынып карыйсы килә. Рәдиф абыйлары шундый берәр түгәрәк ачып җибәрсә, бу һөнәр әле яшәр иде. Аның үзенең дә бу теләге бар, вакыты гына җитми тора. Хәзер бит борынгы үрнәктә ясалган әйберләрнең кыйммәтен аңлыйбыз.

Безгә кар түгел, җыр кирәк

«Пошалым чаналары» дигәч тә, иң элек Татарстанның халык артисты Рөстәм Закиров үткәргән конкурс искә төшә. Ә бит барысы да җырдан башлана! Сания Әхмәтҗанова сүзләренә Илфат Дәүләтшин язган ул җыр өч Пошалым турында. Аны матур итеп халыкка тәкъдим итү идеясе әнә шулай конкурска әверелә. Беренче елларны Югары, Урта, Түбән Пошалым авыллары арасында уздырыла, аннары инде чикләре киңәя. Җырның чаналарга ни катнашы бар, диярсез. Җыр – Пошалым турында, конкурс үзе дә шушында уза, ничек инде чаналарсыз булсын?! Бизәлгән атлар, чаналар белән, авыл урамнарын гармун-җырга күмеп уза ул. Җиңүчеләргә дә бүләкнең иң кәттәсе – Югары Пошалым брендына әверелгән җиңел агач чаналар бүләк ителә. Баштагы елны конкурска дигән чаналарны Равил абый ясаса, аннары ул Рәдиф Нигъмәтуллинга йөкләнә. Быел «Пошалым чаналары» конкурсының 16 еллыгы Казанда фестиваль рәвешендә уздырылып, тамашачы арасында 16 чана уйнатылды. Элеккечә атлар, чаналар белән, конкурс итеп уздырылмавына вакытында кар яумавы гына сәбәпче түгел, билгеле. «Безгә кар түгел, җыр кирәк», – диләр пошалымныкылар.

– Арба-чана ясау кәсебе онытылган иде, – ди Рөстәм Закиров. – Пошалымда бит чаналар гына түгел, бала арбалары да ясаганнар. Юкә кабыгыннан матур итеп ясалган шундый бер арба бездә дә бар иде. Бакча башыннан люцерна ташый идек аның белән. Кыш көне исә арбаны йөк чанасы алыштыра. Шуның белән шуабыз да, салам да ташыйбыз... Ат чаналары, кошевкалар, арба көпчәкләре – кайчандыр иң кирәкле булган әйберләргә бүген ихтыяҗ юк. Ихтыяҗ булмагач, эш ысуллары да онытыла. «Пошалым чаналары» конкурсы бу һөнәрне кабат тергезеп җибәрде дип саныйм.

Лаклаганнан соң, гәрәбә төсенә кереп, үзендә кояш нурын чагылдырган бизәкле чаналарның даны инде күптән Татарстан чикләрен үткән. Оренбург, Архангельск, хәтта Франциягә үк соратып алганнар аларны.

Чана шуу яшеннән күптән чыккан булсам да, кызыктым бу чаналарга. Их, шушы чаналарның берсенә утырып, таудан выжылдатып кына бер шуарга!



НИКАХЛАР НИГӘ КЫСКА ГОМЕРЛЕ?

Бер генә кеше дә гаилә корганда, аерылышырбыз, балабыз ятим үсәр, дип уйламый. Барыбызның да бәхетле гомер итәсе, балалар үстерәсе килә. Ләкин тормышта кайчак бөтенләй башкача килеп чыга... Никахны ничек озын гомерле итәргә, дигән соравызга **Сәйдә абыстай АППАКОВА** җавап бирә.

? Ни өчен яшьләр килешеп яши алмый, никахлар нигә таркала?

– Бисмилләһир, рахмәәнир-рахиим! Бу сорауга бер генә җөмлә белән җавап биреп булмый... Шулай да элеккеге һәм хәзерге тормышыбызны чагыштырып карасак, азмы-күпме нәтиҗә ясарга булыр иде.

Әти-әнием колхозның умарталыгында эшләде. Әни мине дә үзе белән эшкә ияртеп алып бара иде. Эш башланганчы аның белән икәү аз гына уйнап алабыз. «Әйдә, йорт салабыз, – ди әни. – Син гел кечкенә тормассың, үсәрсең, кайнанаң белән кайнатаң булыр. Без дә кунакка килербез». 8-9 сантиметрлы чыбыклар алып, берничәсен җиргә кадый да, «йорт» урынын сызып, «вәгазен» дәвам итә: «Түр башында – кайнанаң белән кайнатаң, бер ягында – без. Тегендәрәк – балалар, бу җирдә – үзегез».

Кыз баланы ана, хатын булырга, өйрәтеп үстергәннәр. Ә ир балага кечкенәдән син гаилә башлыгы буласың, гаиләңне матди яктан тәэмин итәргә, тынычлыкны саклый белергә, хатының, балаларыңның сәламәтлеген кайгыртырга тиеш буласың, дигән фикерне сеңдергәннәр.

? Хәзер балаларны тәрбияләүдә нинди ялгышлыклар җибәрәбез?

– Мин күп җирләрдә булам. Кайда булсам да, бер сорауны бирми калганым юк: «Ир балагызны – ир кеше, әти кеше, кыз балагызны әни, хатын булырга өйрәтәсезме?» – дип сорыйм. «Әллә тагын? Кирәк булганда өйрәнерләр әле, без өйрәндек», – диләр. Әйе, без өйрәндек. Безнең чорда әле борынгы тәрбия әзме-күпме эләкте.

Хәзерге заманда гаиләдә бер яки ике баланы йокысы туйганчы йоклатабыз, пәрәмәч, өчпочмаклар ашатып, нәрсә сораса, шуны алып биреп сөендерәбез. Укымаса, акча түли-түли белемен күтәрәбез. Аннары түли-түли институтларда укытабыз. «Әти-әни» дип әйтә белмәсә дә, никах укытып, туй ясыйбыз. Хәлдән килсә, кулларына фатир ачкычын да тоттырабыз. Никах алдынан үгет-нәсыйхәтләребез белән «коендырабыз»: «кайнана-кайната белән яшәмәгез, ялгыз яшәүне карагыз. Иреңне яисә хатыныңны беренче көннән үк кулга алырга тырыш! Изелеп яшәмә, юл куйма, үзеңне сакла». Менә болар барысы да – хәзерге заман тәрбиясе.

Нәтиҗәне карыйк. Бер капчык уенчыгы белән дә уйный белмәгән, эшкә өйрәтелмәгән бала үз фикере дә булмаган кеше булып үсеп җитә. Туйдан соң беренче конфликтта ук югалып кала, күз алдына да китермәгән тормыш кагыйдәләре белән очраша. Юл кую, сабыр итү, бер-береңә хөрмәт күрсәтү кебек тормыш күнекмәләре алмаган бу кеше мондый вакытта күп уйланып тормый, яңадан әти-әни өенә юнәлә. Аннары барыбыз да гаҗәпләнәбез: ничек инде, әле генә никахлашканнар иде, хәзер аерылабыз, диләр?!

? Катнаш никахлар да бар бит әле...

– Монысы инде тагын да авыррак. Гасырлар буена сакланып килгән ике капма-каршы гореф-гадәтләр, ике дин. Христианнарда туйдан соң яшьләрне эшләтмиләр, олылар эшли. Ә бездә киресенчә – күбрәк яшьләр эшләргә тиеш. Менә башлана ризасызлык... Бала тугач, эш тагын да катлаулана. Балага исем кушу, исем кушуны кайсы дин кушканча башкару, уртак мәҗлесләрдә кайсы телдә сөйләшү – болар да зур проблемага әверелергә мөмкин. Һәр ике якның да үзенчә итәсе килә. Әкренләп гаиләдә тынычлык югала, хөрмәт бетә.

? Ир кеше ялкау булса, гаиләсен кайгыртмаса, нишләргә?

– Бу бик мөһим мәсьәлә. Мондый очракта аның хатыны бар авырлыкны үз өстенә алырга мәҗбүр була. Бу гаиләне дә бәхетле гаилә дип әйтеп булмый. Әкренләп никах гомере кыскара бара, чөнки бер-береңә булган хөрмәт сүнә. Хатын-кыз лидерга әйләнеп, үзен гаилә башлыгы итеп тота, ә ирнең абруе түбән тәгәри. Кайнана-кайната да хәрәкәткә килә башлый, янәсе аларның баласын санга сукмыйлар, ир итмиләр. Югыйсә бу хәлдә киленгә рәхмәт кенә әйтәсе: «И кызым, барлык мәшәкать синдә төшә инде. Кода-кодагыйлар сине бигрәк эш сөючән итеп үстергән. Рәхмәт аларга. Без үз балабызны үстерә белмәгәнбез икән. Җай белән генә үзең эшкә куш инде», – диясе. Үз ялгышыңны тану да ярап куя тормышта. Ялкауны кем ярата? Беребез дә яратмый.

Тагын үткәннәргә кайтыйк әле. Әти-әниләр безне нык ихтыярлы итеп үстерергә тырышты. Аерылып кайтулар бик оят булып тоела иде. Ә хәзер ничек? «Әйдә, кайт! Бер баланы ничек тә үстерербез әле!» – диләр. Менә бу – гафу ителмәслек ялгышыбыз.

Иргә дә, хатынга да җылы сүз кирәк. Янында терәк булмаса, ай-һай, авыр. Тормыш тәҗрибәсе шуны күрсәтә: ир кеше әз булса да тырыша икән, хатын-кыз аерылып китәргә ашыкмый.

Без үзебез турында гына түгел, илебез турында да кайгыртырга тиеш. Аерылышулар илнең нигезен какшата. «Ир дәрәҗәсе – ил дәрәҗәсе», – дигән бит халык та.











МИНЗӘЛӘ САНДУГАЧЫ

Әхтәм ЗАРИПОВ

Татарстанның атказанган артисткасы Мәбрүрә Рәхмәтуллинаның тууына – 100 ел! Театр сәнгатенә, җырга гашыйклар, Минзәлә театрының тугры тамашачылары, бу үзенчәлекле талант иясен сагынулы хөрмәт белән искә ала.

Алты дистәдән артык спектакльдә катнашып, Мәбрүрә Рәхмәтуллина Минзәлә театры тарихында җуелмас тирән эз калдыра.

Мәбрүрә апаның җырлаганын бер ишеткән кеше, аның тавышына соклануын: «Минзәлә сандугачын тыңладым», – дип башлап, ишеткән җырын кабатларга тырышу белән сүзен тәмамлавы без, авыл яшьләре арасында узган гасырның илленче елларында бик тә мәртәбәле күренеш иде. Башкортстанның татарлар күпләп яшәгән Илеш, Дүртөйле, Бакалы, Чакмагыш, Бүздәк, Шаран районы кешеләре өчен Минзәлә – сәнгатьнең генә түгел, гомумән, мәдәниятнең, мәгърифәтнең бер үзәге, кыйбласы булып саналды.

Безнең Тәҗәй авылында башлангыч мәктәп кенә иде. Бишенче сыйныфтан күрше Куҗбахты мәктәбенә йөреп укырга тиеш була идек. 1–4 нче сыйныфлардагы укытучыбыз Шура апа Куҗбахты мәктәбен мактаганда: «Укытучыларның күбесе анда Минзәләдә укып кайткан чын педагоглар», – дип кызыктыра иде. «Педагог» сүзенең мәгънәсен аңламасак та, «чын» дигәне күңелгә кереп калган.

Шура апа үзе, безнең авылга югары белемле агроном Әсраровның хатыны буларак килеп, ипилек-тозлык татарча өйрәнгән марҗа иде. Шул марҗа, күрше авылларга Минзәлә театры килгәнне ишетеп, безне спектакльләр карарга алып баргалый иде.

Ничәнче ел икәнен хәтерләмим, әмма «Акчарлаклар» дигән спектакльне карарга күрше авылга барганны хәтерлим. Мәбрүрә апаның җырлавын әүвәл шул спектакльдә ишетмәдемме икән?! Без – авыл малайлары өчен артистканың ничек җырлавы түгел, спектакльне күрү үзе үк мактаныр сәбәп, ә менә Шура апа без күрмәгәнне дә күрә, без ишетмәгәнне дә ишетә икән: «Бүген өегезгә кайткач, көндәлек дәфтәрегезгә беренче мәртәбә колоратурное сопрано тавышлы җырчыны тыңладык, дип язып куя аласыз», – диде ул миңа карап. Мине якын иткәннән түгел, ә шулай тиеш санагандыр, чөнки мәктәптә исемем чыккан гармунчы идем. Шунда «ярый» диясе урында: «Ә минем бит көндәлек дәфтәрем юк», – дидем. «Булмаса – булдыр, мондый җырчыларны сез тагын кайчан тыңлый алырсыз әле. «Ла Скала» театрына барып кына тыңламасагыз...» – ди бит Шура апа. «Ла Скала»... Мин шунда: «Анысы да Минзәләдәме?» – дип сораганымны, Шура апаның көлгәнен генә хәтерлим. Әмма ләкин ул матур тавышлы җырчының җырлавын мин тагын бер ишеттем.

Безнең авыл клубы ишегенә «Базытамак клубында Минзәлә театры «Идел буенда» дигән спектакль күрсәтә» дигән игълан беркетелгән иде.

Безнең инде яшереп кенә тәмәке тарта башлаган егет чак, игъланны укыгач, бәхәсләшү дәрәҗәсенә җитеп кызыксындык. «Идел буенда» дигән бит!.. Безгә Агыйдел алты-җиде чакрым ераклыкта. Анда һәр елны булып узган кызыклы хәлләрдән без яхшы хәбәрдар. Болыныбыз шунда, печән әзерләгәндә куышлар салып, колхозның өч бригадасы да шунда кунып ята. Печән чоры! Бу чорда ел саен нindidер бер вакыйга була, озак вакытлар сөйләргә сүз калдыра... Безнең Агыйдел буендагы авыллар «Ак» сүзен әйтмичә, «Идел» дип кенә йөртә. Минзәлә театры күрсәтәчәк спектакльне дә безнең Идел буендагы берәр хәл турындадыр дип ышанып, Базытамак клубына юл тоттык. Спектакль безнең Иделебез турында булмаса да, баруыбызга үкенерлек түгел иде – без анда тагын теге «сандугач» җырчыны тыңладык. Аның егете Салих белән парлап җырлаганы әле дә колагымда: «Ай ли, Салихым, ай ли, Фирүзәм!..» Кызганыч, җырчыларның исемнәрен мин еллар узгач кына белдем: Җиһангир Җиһаншин белән Мәбрүрә Рәхмәтуллина, ягъни «Минзәлә сандугачы» булган икән.

Хәзер аңлавымча, Мәбрүрә апа Минзәлә сандугачы гына булмаган. Ул чакта Минзәлә өяз шәһәре генә түгел, татар мәдәниятенең кәгъбәсенә тиң бер шәһәр иде. Ә Минзәлә театрының даны хәзерге академия театрыданыннан да югарырак булгандыр, чөнки ул милләткә үзе килеп сәнгать әсәрләре бүләк итүче чын театр иде. Радио һәм телевидение юк чакта авылга театр килү олы бәйрәмгә тиң вакыйга иде.

85 еллык иҗади гомерендә бу театр Островский, Гоголь, Горький, Мольер, СССРда яшәгән тугандаш халыкларның классик әсәрләрен татар телендә уйнады. Милләтебезнең рухи-мәдәни үсешенә тиңсез өлеш керткән үзенчәлекле иҗат коллективы булуы бәхәссез аның! Шул өлеш кертүчеләрнең берсе, әлбәттә, Мәбрүрә апа Рәхмәтуллина! 1949 елда Мамадыш театры ябылгач, ул ире Шамил Сабиров белән Минзәлә театрына килеп урнаша.

Театр тарихында үз эзенңе калдыру һәр артист өлешенә тәтемәүгә игътибар итсәк, Мәбрүрә апа икеләтә мактауга лаек: аның җырлавын бер ишеткән кеше ул җырны гомере буе күңелендә саклый. Бигрәк тә Җәүдәт Фәйзи, Заһит Хәбибуллин, Шакир Мәҗитов, Александр Ключаревларның бу уникаль тавышлы җырчыга атап язылган җырларын. Алар Мәбрүрә апабыз башкаруында төрле бизәкле өстәмә-үзгәрешләре белән бүгенге җырчылар тарафыннан да башкарылып, сокландырулары дәвам итәләр. Аерма шунда: Мәбрүрә апа җырлаганда һәр көй, «тумыштан шундый тавыш» дигән бәһа белән тыңланылып, ничек бар – шулай кабул ителсә, хәзерге профессиональ җырчыларны тыңлаганда, «бигрәкләр дә оста җырлыйлар» дип, аларның башкару осталыгына гына сокланасың. Моңның күңелдән саркылып чыкмавы үзен сиздерә шул. Шул ук көй, әмма тәэсирләре җир белән күк аермасы. Мәбрүрә апада табигыйлек өстенлек итсә, замандаш җырчыларда осталык-һөнәрманлык төп компонент икәне сер түгел.

Бүген ике кешенең берсе үзен җырчы дип санап, җырны кәсепкә әверелдерү гамәле белән шөгыльлән-

Фотолар: автор архивыннан

Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ендә Салих Сәйдәшев җырларын башкарып, талантлы актриса моң диңгезендә йөздерде.

гән заманда, ни өчен профессиональ театр үзенең «штатный сандугачын» бар тавышына сайратыр өчен «куаклар» утыртмады икән дигән сорау туа. Минзәлә театрының Мәбрүрә апа эшләгән чор репертуарында музыкаль спектакльләрнең булмавы гаҗәпләндерә. Җырчы артистлар бер Мәбрүрә апа гына түгел бит юкса. Милләтнең күңеленә күңел күзе белән карау җитмәгәнме? Әллә инде идеологиягә бәйле сәбәпләр артистны табигатенә ят рольләр башкарырга мәҗбүр иткәнме? Алай дисәң, Островскийның «Бирнәсез кыз»ындагы трактир хезмәтчесе Иванның идеологиягә ни катнашы бар? Мәбрүрә Рәхмәтуллина дигән колоратуралы сопрано тавышлы талантлы җырчыга, мыек беркетеп, аннан Иван ясау кемгә ни бирде икән? Шул инде – булганны сакламыйбыз, югалткач, елыйбыз.

Ничәнче сыйныфта укыган чагым булгандыр – авылга Минзәлә театры украин язучысы Вадим Собко әсәре буенча куелган «Балан куаклыгы» дигән спектакль алып килде. Кыш иде. Керосин мичкәсеннән әмәлләгән мичнең төтен торбасын тәрәзәдән чыгарып, клубны җылыткан хәтердә. Әйе, клуб җылынган шикелле булды, әмма халык җылынмый. Чөнки спектакль ышандырмый. Тәнәфестән соң халыкның яртысы спектакльне ташлап китүе дә хәтердә калган. Артистлар начар уйнаганнан түгел, төп сәбәп – спектакльдәге вакыйгаларның татар тамашачысы өчен гыйбрәтле булмавында. Гыйбрәтле спектакльләр булмау – лаеклы әсәрләр булмаудан. Ә инде әсәрләр булмау – театрларның драма язучылар дип йөрүчеләргә йөкләмә-бурыч куя алмауларында. Аларның күпчелеге сәбәпне шунда күрә. Сәбәп, әйтеп узганымча, халык күңеленә битарафлыкта. Шул битарафлык аркасында сәхнәгә түбән зәвыклы, сай эчтәлекле, «бер каптырмалы» пьесалар мөнә, залдагы тамашачының яртысы көлә икән, театр үз максатына ирешә дигән нәтиҗә чыгарыла.

...Мәбрүрә апа белән булган бер вакыйганы сөйлим әле. Чөнки шул бер эпизодта да ул үзенең кемлеген һәм театр өчен бик тә кирәкле булуын күрсәтте.

...Минзәлә театрына мин үзем 1955 елның декабрь ахырларында кушылып киттем. Авыллардан авылларга тракторларда яки атларда күчәнәбез. Актаныш ягындагы Пучыдан Аю авылына күченгәндә көчле буранга эләгеп, Ык буендагы Матвеевка дигән урыс авылында тукталырга – гастрольләребезне өзәргә мәҗбүр булдык. Төн. Буран. Фатирларга урнашу ихтималы юк. Салкын клубта урнашып, буран тукталганны көтәргә булдык. Һәркем булдыра алганча селкенеп, кыймылдап, үзәкләргә үткән салкыннан сакланмак була. Дәрт-дәрман өстәү өчен анекдот-мәзәк сөйләүчеләр дә тынды. Әнә шул тынлыкта толыпка төренеп яткан Мәбрүрә апаның сандугачтай сайрап җыр башлавы караңгы клуб эчен яктыртып җибәрде. Термослары булганнар чәй калдыкларын эчтеләр, кемнәрдер Мәбрүрә апага кушылып җырларга маташты, Әнвәр ага Фәсхетдинов гитарасын чыгарды. Иң гаҗәбе – котырган буран булуга карамастан, клубка халык җыйнала башлады. Кемдер фонарь тотып килгән иде – яктылык пәйда булды. Иң кирәкле яктылык күңелләребездә балкыды. Мәбрүрә ападан соң Әнвәр абый русча берничә җыр җырлады. Чын концерт иде бу. Матвеевка авылының бер кешесе, кыюлыгы җитеп, Мәбрүрә апага: «Спойте «Соловушку» Алябьева», – диде. Без, яшьләр, бу сорауны аңламадык, әлбәттә, үртәлдек. Мәбрүрә апа исә: «К сожалению, не знаю слов этой песни, но импровизирую мелодию», – дип, сүзсез генә «җырлап» күрсәтте.

Ниһаять, 31 декабрьдә Минзәләгә кайтып егылдык. Җыр кайгылары калмады, миңа фатир табып урнашырга кирәк иде. Ә башка артистларны гаиләләре, балалары көтә. Мәбрүрә апаларның да өчәү алар.

Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ен куя башлагач кына кабат «сандугач» тавышын ишеттек. Спектакль сәхнәдә куелуда Мәбрүрә апаның ире Шамил абый Сабировның да өлеше зур булды. Чөнки күптән куелмаган, тыелган әсәрнең Салих Сәйдәшев язган көйләрен хәтерләп, нотасын язып, артистларга өйрәтү театрның баянчысы Шамил абыйга йөкләнде. Моңарчы тыелган «Зәңгәр шәл»не Минзәлә театры 1955 елның язында республикада беренче булып тамашачыларга кайтарды.

...Мәбрүрә апаның кызы Венера да гомере буе җыр сәнгатенә хезмәт итте. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә хормейстер булып эшләгәндә иҗат итеп калдырган үлемсез җырларыннан «Зөбәрҗәт», «Сорнай моңы», «Кәккүк»ләрне кызының анасы Мәбрүрә апага һәйкәле дип кабул итәргә була. «Аулак өй», «Сабантуй» дигән күләмле хор әсәрләре – барысы да Татарстанның халык артисты Венера Гәрәеваның иҗат җимешләре.

Кызганыч, Мәбрүрә апа вафатына бер ел кала гына Татарстанның атказанган артисты исемен алуга ирешә. Әмма ул халык күңелендә күптәннән халык артисткасы булып танылган иде инде. Һәм йөз яшен билгеләп үткәндә дә шул дәрәҗәсе белән хәтерләрдә яңара. Әйе, ул Сандугач иде. Сандугачның сайравын хәтерләгәндә, яше бөтенләй кызыксындырмый. Сайрасын гына сандугач, куркытмасыннар гына. Ни кызганыч – бүген ул сандугачның оясы да, кунып сайраган куаклыгы да юк. Куакларда башка оялар, ояларда сайрамас кошлар («чыпчыклар» диясе килми). Ярый әле ул катнашкан спектакльләрдәге рольләрдә төшерелгән кайбер фоторәсемнәре сакланган. Алар өчен без артистканың балаларына һәм аның уенына, җырларына гашыйк тамашачыларга рәхмәтлебез. Минем бу язмам Мәбрүрә Рәхмәтуллинага рәхмәтем һәм догам булып ирешсә иде.

Илгә ябырылган олы кайгы – миллионнарча корбаннар биргән сугыш афәте без – балалар өчен дә зур сынау, балачагыбызны урлаган, бик күпләребезне ятим иткән кара көннәр булып йөрәккә уелып калган. Безнең чор баласы авыр физик хезмәт белән иза чигүләрдән тыш, сәяси яктан кыерсытылу газапларын да башыннан уздырды шул. Искә төшереп, күз алдына китерсәң, җаннар телгәләнә. Ләкин без барысына түздек...

ҖИҢҮ ТӘМЕ БАЛЛЫ ИДЕ



Әлфия апа альбомында 1941 елның җәендә төшкән бер фото саклана. Казанның Киров урамындагы фотосалонга барып төшкән бу көнне ап-ачык хәтерли ул. «Өстемдәге күлмәкне әни тегеп биргән иде. Аягымдагы туфлиләрне исә дустым Суфиядән алып тордым. 12 яшь иде миңа». Сугыш чорының бар авырлыгын күреп үскән Әлфия Ибраһим кызы Әхмәдуллина ул көннәрнең берсен дә онытмый. 1418 көннең һәрберсе истә...

– Без әнигә өч бала идек, – дип, хәтер битләрен ача Әлфия апа. – Равил абый армиядә, Фәрит абыем алтынчы классны тәмамлап, һөнәр училищесына укырга кергән иде. Әтиебез миңа 5 яшь тулганда ук вафат булды. 1940 елның 6 ноябре иде. Әти Иваново энергетика институтын тәмамлап кайтты. Иртән мине күтәреп бәйрәмгә алып барды, ә кичен... без аны мәңгегә югалттык.

Ә 1941 елның 22 июне дә кичә генә булган кебек.

– Тукай урамында яши идек. Үкереп елап, ишегалдына күрше кызы Роза Денисова йөгереп чыкты: «Война началась!» Ә якын дустым Ләлә пионер лагеренда! «Сугыш башланган, Ләләне алып кайтыгыз!» – дип, аның әти-әнисе янына чаптым.

Иртән безнең тормыш танымаслык булып үзгәрде. Күршеләрне фронтка озаттык, укытучыларны, дусларымның әтиләрен, абыйларын... Равил абыемны 1940 елда армиягә алганнар иде. Ул сугышка шуннан гына керде. Соңгы хаты 1941 елны Мариуполь шәһәреннән килде.

Без укыган 80 нче мәктәпне госпиталь иттеләр. Җәй буе госпитальдә эшләдек: яралыларның якыннарына хатлар яздык, бинтларын юдык, утын кистек, концертлар куйдык... Укулар декабрьдә генә башланды шикелле. Муса Җәлилнең кызы Чулпан бездән ике класс югары укый иде. Әле дә күз алдымда: шинель кигән шагыйрь мәктәпкә кызы белән хушлашырга керде.

Ачлык, ялангачлык, зәмһәрир салкыннары белән кыш керде. Иртән укырга барганчы вокзалга төшәм. Өстемдә – абыйга училищедан бирелгән зур бишмәт, кесәмдә – бау, чүкеч, кадак. Утын төялгән йөк күрсәм, каршысына йөгерәм: «Дяденька, продай!» Сатса, бозлы бүрәнәгә кадак кагып, бау бәйлим дә, өйгә сөйрим. Әни эштән кайтканчы балта белән чапкалап, самавырга шакмак булса да әзерләп куям. Әти вафат булгач, әни пекарняга эшкә урнашкан иде. Эш бик авыр, барысы да кул көче белән эшләнә. Сугыш башланган елны 1 нче тегү фабрикасына урнашты. Пекарняда эшләгәндә аз булса да ипи ашый идек әле, фабрикага күчкәч, ипи карточкага гына калды. Әнигә көненә – 600 г, миңа 400 г ипи тия. Абый үз өлешен училищедан ала. Сугыш башлангач, Казанга эвакуацияләнүчеләр күп иде. Безгә дә ике украин егетен керттеләр. Аларның һәркайсына ипине көненә 800 грамм итеп бирәләр. Карточка булу бер хәл, ул ипине әле чират торып алырга да кирәк. Берсендә барыбызның да карточкаларын урлаттым. Ун көнлек ипи карточкасын бергә ябыштырып алып чыккан идем. Сыгыла-сыгыла елаганымны күреп кибетчеләр җәлләде: бер кирпеч ипи бәрабәренә картбюрога тапшыру өчен кибеттә ипи карточкаларын ябыштырырга чакырдылар. Иптәшкә дустым Ләләне дә ияρттем. Төнгә кибетчеләр өстебездән бикләп китә. Клейстер ясар өчен ипи валчыклары биреп калдыралар. Ул валчыкны аның өчен тотмыйбыз инде – үзебез ашыйбыз, ә клейстерны горчицадан ясый идем. Эшләгәнем өчен алган бер кирпеч ипине өйгә алып кайтып, тиз генә кисәкләргә бүлеп куям: әнигә, фатирдагы егетләргә... үземә бүләрлек калмый. Чын ачлыкның нәрсә икәнен менә шунда белдем. Ләкин ничек итсәм дә иттем, карточкаларны урлатканны әнигә әйтмәдем. Ун көннән соң үз өлешемне кулыма алгач, шатлыгымнан ипине битемә терәп еладым. Урамнан ипи ашап кайтканымны күрше Сәгыйть абый күргән икән. Ачулана: «Җиткән кыз булып киләсең, ник урамда валчык коеп йөрисең?» – ди. «Бер кирпеч ипи ашап бетерер идем әле, карточкаларымны урлаттым, ун көн ашаганым булмады», – дигәч, өенә чакырып кертте дә каяндыр бер кирпеч ипи алып кайтып бирде.

1945 елның 9 мае бик җылы, кояшлы килде. Иртәнге алтылар иде микән, радиодан дүрт ел буе тилмереп көткән хәбәрне әйттеләр: «Сугыш беткән!» Мин, шатлыгымнан кая басканымны да белмичә, дус кызларыма чыгып чаптым. Бергә җыелышып, класс җитәкчебез Хәят апага – Лобачевский урамына киттек. Ул әле йокыдан да тормаган иде. Безне өенә чакырып, провансаль кәбестәгә шикәр сибеп ашатты. Ул баллы тәм безнең өчен Җиңү тәме иде.

Әлфия апа ӘХМӘДУЛЛИНА сөйләгәннәрне Лилия ГӘРӘЕВА язып алды.




Рашат НИЗАМИ

Рашат Низамиев иҗатын балалар да, яшьләр дә, өлкәннәр дә бердәй ярата. Мәктәптә балалар укытып, «Ялкын», «Татарстан яшьләре» кебек яшьләр басмаларында – җаваплы секретарь, «Казан утлары» журналында – баш мөхәррир урынбасары, яшьләр журналы «Идел»нең баш мөхәррире булып эшләгән каләмдәшебез үз әсәрләрендә җәмгыятьне, милләтне, яшьләрне борчыган күптөрле мәсьәләләрне кузгата. «Йолдыз яңгыры», «Кызыл җәй», «Шәһәр өстендә акчарлак», «Тормыш трамвае», «Урман эчләрендә урман», «Яшьлеккә хат», «Кызыл кар яугач»... Китапларының исемнәрен искә төшерү дә җитә – геройлары, халыкчан образлары, тормышчан детальләре белән сизгер күңелле каләм иясенең укучыларына никадәр якын булуын аңлыйсың. Композитор Фәрит Яруллин турындагы романы исә язучыны иҗатта яңа баскычларга күтәрә. «Дөньяга рәссам булып туган кешеләр була. Алар безгә караганда күбрәк сиземлиләр, тирәнрәк хисләнәләр, дөнья гамьнәрен үз йөрәкләре аша үткәрәләр. Рашат – әнә шундый борчулы җаннарның берсе», – дип яза Фоат Галимуллин аның турында. Талантлы язучыны, ихлас күңелле, олы йөрәкле кешене гомер бәйрәме белән котлыйбыз!

КАЙСЫ ЙОЛДЫЗЛЫКТАН ТӨШТЕҢ ҖИРГӘ

Минем җырым
(триптих)

«Как гений чистой красоты».
А. С. Пушкин

I

Мин яшенгә гашыйк идем элек,
Коеп-коеп яңгыр яуганда.
Ничәмә кат, сөю ташын эзләп,
Сәфәр чыктым алсу таңнарда.

Күңел тырышлыгын багышладым
Гел кояшлы көннәр ягына.
Хыялларым, янар учак булып,
Җирдә-күктә канат кагына!

Яшьлегемнең ап-ак битләренә
Язмыш-каләм ниләр язачак?
Айның аргы якларыннан хәтта
Күңелем сине эзләп табачак.

Ләйлә белән Мәҗнүн мәхәббәтен
Кабатларга телим мин, имеш...
Күрәсеңме, әйтер сүзем булып,
Калтырана кызыл гөлҗимеш.

II

Эчем-тышым яна... Барган шәпкә
Сикерәмен гүя ут аша.
Синең сурәт, синең нурың белән
Мәңгелеккә килеп тоташам.

Җиләк сыман посып тора әнә
Әйтеләсе сүзләр – ир(е)немдә.
Дәрман җитә: күкнең катламнарын
Мин күтәреп торам иңемдә.

Бәхетемне килми куркытасым,
Син – язмышым минем, син – ярам.
Зинһар, тәкъдир! Биргән бәхетеңнән
Мәхрүм итә күрмә – ялварам...

Хыялымда сиңа, толым итеп,
Йолдызлардан гөлләр үрәмен.
Вулканнарга кереп баттым бугай, –
Мин терелеп, мең кат үләмен.

III

Ярый әле син янәшәмдә,
Безнең уйлар, күңел – янәшә.
«Яшәү – бәхет,
тәмен белегез», – дип,
Күкләр безгә хәтта эндәшә.

Мәхәббәтне танып-белер өчен
Янып яшәү кирәк иң элек.
Таулар тикле таулар җимерелә,
Сөю генә җирдә – мәңгелек.

Күзләреңнән, керфек очларыңнан
Түгелә сыман гөлләр яңгыры...
Безне зурлап, зәңгәр офыкларда
Яшәү музыкасы яңгырый!

Кайсы йолдызлыктан
төштең Җиргә,
Шуның серен миңа әйт әле.
Сихерләнеп багам: син бит, сеңел, –
Матурлыкның тере һәйкәле...

Серләр эзлим

Бер үк кояш яктыртса да
шушы җирне –
Үләннәрнең яфраклары
төрле-төрле...
Кара туфрак имеп үскән
алмагачның
Алмалары нидән кызыл –
шунсы серле.

Тузан баскан каберташлар
күтәп тора
Яфракларның сыйпап-сыйпап
киткән чагын.
Кая гына бакма – хикмәт белән,
Серләр белән тулып ята тирә-ягым!

Кешеләрнең йөзләреннән
серләр укыйм:
Берәү моңсу,
ә берәү шат атлый юлдан.
Агач битле,
таш бәгырьле җаннар гына
Мәхрүм була сагышлардан,
елмаюдан.

Киң күкрәкле ир-егеткә караганда
Ун мәртәбә катлаулырак
хатын-кызлар.
Серләрнең дә иң серлесе,
иң нечкәсе –
Күз нурыңны сындырырлык
матур кызлар!

Серләр эзлим, серләр ачам –
вакыт җиткәч
Сөйләр өчен оныкларга
чын дөресен.
...Күзләремнән якты йолдыз
яуган чакта
Мин үзем дә сердер әле
кемдер өчен...

Кояш турында җыр

Син миңа әнидер, әнидер...
Күңелең еш кына әрнидер.
Булды бит хәсрәтле чакларым –
Син мине давылдан сакладың.

Син миңа ападыр, ападыр...
Уйларың үткәнгә кайтадыр.
Кул селтим дөньяның малына,
Чын бәхет китердең җаныма.

Син миңа сеңелдер, сеңелдер...
Гомерләр мәңгелек түгелдер.
Алдыңа моң булып түгеләм:
Син – кояш! Мин – тамчы,
мин – үлән.

Син миңа кыз бала, кыз бала...
Мең төрле гамьнәрем кузгала.
Сөюнең мәгънәсен бел икән –
Яшәүләр, уйласаң, гөл икән.

Янартау йокламый, йокламый,
Кирәксә, йөз елдан уяна.
«Белегез, мәхәббәт бар ул!» – дип,
Чаң сукты йөрәгем дөньяга...

Ялгышу

Синең хакта уйланудан
туктамакчы булдым.
Салкын мендәремне тешләп
йокламакчы булдым.

Туктап калды Ай һәм Кояш
йолдыз чатларында.
Чәчәкләр дә сулды кинәт
сөю бакчасында.
Ерып чыгалмастай куе
карурманга кердем.

Күзем йомык. Йөрәк тынган –
бер минутка үлдем.

Хыялымда үз-үземнән
качып барган чакта, –
Тойдым: хакыйкатьнең күзе
тора икән сакта!

Сөю һаман бәргәләнде
күкрәк читлегендә.
Ярты җаным, кубарылып,
калган икән синдә...

Күперләр

Җитәкләшеп уздык күпердән.
Сулар ага... Үлән күпергән.

Тирә-юньдә көмеш яктылык!
Болыт тора күктә – тап булып.

Каеннардан аклык түгелгән.
Уздык сөю дигән күпердән.

Мәхәббәттән Ай да исерде –
Ялгызлыгын искә төшерде.

Еллар ага... Вакыт картая.
Без барабыз икән кай таба?

Каләмемнең кипмәс карасы, –
Сүзләр сүзгә тора карашып.

Насыйп булсын гарше кичләрдә
Сират юлын бергә кичәргә...

Тузганак

Мин болынга диеп килгән идем
Күрер өчен якын кешемне.
Тузганаклар, йомры тузганаклар
Балачакны искә төшерде.

Кушымта:
Әй тузганак, синең дә бит бардыр
Үзең генә белгән моңнарың.
Мине исә шунсы моңландыра –
Тузганактай тузгый елларым.

Еракларга очып китсен диеп,
Өрә идек сиңа тын белән.
Вакытның һәм алтын балачакның
Кире кайтмаслыгын мин беләм.

Кушымта.
Тузганаклар шары каршылады
Болындагы яшел үзәндә.
Сөю безне эзләп тапкан икән,
Сагынуларга кирәк түзәргә.

Елап торган кызны юату

Ник тетрәде әле керфекләрең,
Нинди җилләр узды кагылып?
Күк йөзедәй төпсез күзләреңдә
Яшен эзе тора чагылып.

Син елыйсың...
Күктә кояш көлә,
Бал кортлары кайта басудан.
Карурманның яшел капкалары
Әкиятләргә табан ачылган.

Елмаясың...
Күлдә аккош елый,
Күкләр елый аңа кушылып.
Зонтикларга, агач башларына
Яңгыр булып ява шушы моң.

Белми калсын, күрми калсын Сөю,
Чәчәк сабын җилләр кискәнне...
Ник тетрәде әле керфекләрең, –
Әйтерсең лә дөнья сискәнде!

Теләк

Дәрвиш сыман әй кичәсе килә
Урман белән урман арасын, –
Күрәсе һәм иркәлисе килә
Яңа туган поши баласын!

Хәтерләү

Басуларга тагын чыгып китәм,
Табанымда – камыл эзләре.
Юл читендә күзен кысып кала
Күкчәчәкнең зәңгәр күзләре.

Кыйтга

Ак болытлар – гүя ат көтүе,
Яугир җиңеп кайта пар атта.
Скиф токымыдай тезелешеп
Чал йолдызлар чыккан парадка...

Әнкәй


Күзәнәкне күзәнәккә ялгап,
Оекбашлар бәйли әнкәем.
Тукта, мизгел! Мин әнкәйдән күрәм
Матурлыкның тере һәйкәлен...

Яхшылык

Картаймый – таң саен һаман да
Яшәргә ашкына бу күңел.
Гомернең өч көне калса да,
Яхшылык эшләргә соң түгел!



Мөхәммәт Мәһдиев... Аның исемен әйтүгә үк мәһабәт буйсынлы, җор телле, затлы-зыялы язучыбыз күз алдына килеп баса. Йөрәкләрне актарып ташлый торган берсеннән-берсе матур әсәрләрен сагынып искә төшерәбез. Стиле, гаҗәеп матур теле, җиңелчә юморы, йомры сүзләре тәмам әсир итә. «Фронтовиклар», «Без – кырык беренче ел балалары», «Ут чәчәге», «Каз канатлары», «Кеше китә – җыры кала», «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү», «Мәңгелек яз»лар... Исемнәре үк җырлап тора! Кайсы битен ачып укый башласаң да, бөтереп алып кереп китә! Аларның һәркайсы өстәл китабы булырлык. Кабат-кабат әйләнеп кайтасың шул әсәрләргә. Язучының үзен, геройларын өр-яңадан ачасың. Мәһдиев дөньясы дигән үзгә бер дөньяда рәхәт бер моңга, бәхеткә төренеп, әле елмаеп, әле самими бер халәткә күчеп, җанга якын әсәрләрне тансыклап укый башлыйсың...



Мөхәммәт МӘҺДИЕВ

ТЕЛ БЕЛМӘГӘЧ

(«Каз канатлары» романыннан өзек)

Май башы иде, Гаҗилә җиңгине идарәгә чакыртып, кулына путёвка тоттырдылар. Путёвка бушлай, Кара диңгезгә, санаторийга иде. Баштарак Гаҗилә җиңги тартышып маташты:

– Сыерымны кем саусын? Казым утырган вакыт! Юл өстендә юкәлек дигәндәй, тапкансыз бер юаш кеше... Кешеле кешеләр беткәнмени?

Ленар сабыр гына аңлатты. Елмаеп сөйләде.

– Менә, – диде, – без сиңа билет алып бирәбез, путёвканы идарә карары белән бушлай бирәбез. Аның тулы бәясе йөз дә егерме сум. Син анда барып ял ит. Сыерыңны да, казыңны да күршеләрең карап торсын. Бәрәңге утыртырга кайтып җитәсең. Синең эш – ял гына итү.

Гаҗилә җиңги күнде. Эшкә күндәмлеге ярдәм итте. Чөнки еракка ял итәргә баруны ул эш дәрәҗәсендә күрде. Ул болай уйлады: колхоз идарәсенә, Кара диңгезгә бер кеше җибәрегез дип, задание килгән. Сугыш вакытында шулай була иде бит: Пермьгә фәлән кеше, Илләт урманына фәлән кеше дип. Колхозга задание килгән – аны үтәргә кирәк. Председатель кыен хәлдә. Ә Гаҗилә җиңгинең үз гомерендә колхозны, аның җитәкчелеген кыен хәлдә калдырганы юк. Һәм булмас та...

Шулай, күндәмлеге аркасында гына Гаҗилә җиңги, йорт-җирен Зәмзәмбикәгә калдырып, диңгез буена килеп төште. Урнашкан җире аэропорттан ерак түгел иде, шунысын уйлап бераз тынычланды. Ошамаса, күз күрер әле дип үзен юатты. Шулай, үз гомерендә беренче тапкыр Гаҗилә җиңги эшсез калды. Бу вакытны эшсез ничек үткәрергә?

...Иртән ашханәнең складына дәү-дәү машиналардан сыер, сарык түшкәләре, сөтләр бушаталар. Гаҗилә җиңги шуларны карап тора. Бәлки, алар колхозының сыерлары да шушында килеп керәдер? Бәлки, алар колхозының сыерларыннан сауган сөтләр дә менә шу-



Рәсем: Наталья Васильева

лай шешәләр белән монда киләдер дә, аның кем кулыннан чыкканын уйлап тормастан, тиздән югары кыска чалбар кигән, кара күзлекле, йонлы балтырлы шушы адәмнәр эчеп куялардыр...

Ул һәр көн шулай итә, сөт бушатканны карап тора. Аннан диңгез буена төшеп күләгәдә калгып утыра. Аның бик нык үзе теләгәнчә ашыйсы килә. Алдагы көнгә заказ биргәндә акыллырак булырга кирәк дип уйлый. Менә ничә көн инде аның тәлинкә тутырып токмачлы аш, савыт тутырып бәрәңге, ботка ашыйсы килә. Кисәге белән күтәреп ит ашыйсы килә. Әнә бит складта нинди һәйбәт түшкәләр бушаттылар...

Ләкин өстәлгә бер дә андый ризык килми. Бер кабарлык уган кишер... Пычагымамы ул? Ике телем суган. Акыллы кеше тик торганда суган ашыймы? Аек кеше? Аннан кызыл кәбестә. Бер кашык. Җүнле булса, ак булыр иде ул. Аннан, ак тимер савытта сыек кына, аз гына аш сыман нәрсә. Песи савыты. Ашый башлауга бетеп куя.

Гаҗилә җиңги заказлар кәгазен кулына ала. Юк, болай булмый. Заказ бирә белмәүдән бу. Ул көн саен исемлектән «мясо», «гуляш», «каша», «лапша» дигән сүзләр эзли. Юк. Юк...

Рагу. Азу. Бифштекс. Ромштекс. Бефстроганов... Бар икән күрәселәр...

Тефтели. Лангет. Солянка. Пудинг. Зразы... Бусы инде бигрәк иләмсез сүз. Ферма мөдире Гыйльмуш абзар ишеген ватып чыгып качкан үгезне бервакыт шулай дип сүккән иде.

– Ярабби, складка сыер түшкәсе килеп керә бит соң! Нишләп монда чыкканда әллә нинди әкәмәткә әйләнә бу? – дип, ул карандаш белән кайсы туры килсә, шунысына төртеп чыга. Чит тел белмәгәч, ни хәл итмәк кирәк? Гаҗилә җиңги белән палатада бер татар хатыны яши иде. Яшь, сылу. Акчасы күп, көн саен йөзекләр, мәрҗәннәр сатып ала, төсле ташлар сатучы малайлар белән мәш килә. Ниндидер институтта укытам, диде, Хәбибрахманны белми икән. Бакча яшендәге ике малаен иренә тапшырып ял итәргә килгән. Үзе теләп. Әмма чибәр хатынга ял бик аз эләгә. Кич булдымы – таза гына бер егет белән култыклаша да киногамы, каядыр китеп бара. Таң атканда гына кайта. Гаҗилә җиңги йоклаган турыдагы тәрәзәне чиртә. Гаҗилә җиңги шыпырт кына барып эчтән бикле ишекне ача. Аннан ачык йөзле чибәр хатын барысын сөйли. Кая-кая барган-



нар, теге нәрсә дигән, бу нәрсә дигән... Гаҗилә җиңги аны тыңлап ята – үзенең йөрәге жу итеп китә. Аның килене дә шулай ара-тирә санаторийга баргалый бит. Хәбибрахманнан башка. Ул да шулай йөрсә? Аның Хәбибрахманы бик юаш, бик ышанучан бит. Гел уҗым бозавы инде. Аны да шулай алдамыймы килен? Әллә бу гаеп эш түгелме? Әллә моны Гаҗилә җиңги аңламый гынамы? Әллә ул тормыштан артта калганмы?

– Ике балаң, ирең була торып ничек шулай йөрисең? – диде аңа бер таңда Гаҗилә җиңги.

Сылу хатын кояшта янган матур тәнен ефәкләрдән, затлы тасмалардан азат итеп простыня астына кереп чумарга җыена иде, йөрәк тавышы белән әйтте:

– И апа җаным, елына бер генә килә бит бу рәхәтлек, – диде. – Нибары егерме дүрт көн бит ул...

Гаҗилә җиңги телсез калды. Хәер, ир янында нибары ярты ел торып калган башы белән ир хатынының вазыйфаларын каян белеп бетерсен соң ул?

Аның күңеле инде мондагы тәртипләргә күнә бара. Шулай, шулай... Монда бөтен нәрсәнең исеме башкача икән. Диңгез ярында тик утыру – һава ваннасы. Сукмактан барсаң – туризм. Тегесе дә, бусы да дәва икән. Ә Гаҗилә җиңги болын буендагы фермага көненә ике тапкыр бара. Болын сукмагыннан гына йөри. Көненә сигез чакрым.

Иртәгесен ул тагын теге түшкәләрне карап бушаттыра, тагын дулкыннар янына төшеп, мөлаем гына елмаеп күләгәдә утыра. Үзе күңеленнән кайтырга ничә көн калганын саный.

Дулкыннар көлә-көлә уйнаклашалар...

Алар Гаҗилә җиңгинең мондагы бик күп нәрсәне аңламавыннан көләләр бугай. Явыз көлү белән түгел, ә яратып, якын итеп... Гаҗилә җиңгинең күлмәгеннән дә көләләрдер. Нибары ике күлмәк белән килде бит ул. Күлмәкләре дүрт, биш иде югыйсә. Ә монда! Күлмәк бизгәге. Гаҗилә җиңги моның хикмәтен, фәлсәфәсен каян белсен? Аның бит дөньяга беренче чыгуы.

Булган яшь чаклар... Пляждагы кырык яшьлек, илле яшьлек хатыннарның да яшь чаклары булган. Ләкин ул вакытта Кара диңгез кайгысы ике кереп бер дә чыкмаган! Сугыш вакытының бөтен кайгыхәсрәте, ачлыгы меңләгән хатын-кызның яшь вакытын рәхимсез йоткан. Ситсы да булмаган, хәзерге кебек кыю фасоннар да булмаган.

Ә менә бүген барысы да бар...

Утыз яшьлек хатыннар һәр көнне күлмәк алыштыралар. Кырык яшьлекләр кичке ашка бөтенләй үзгәрешеп киләләр. Аларның көндез кияр өчен һәр көнгә – бер, кич кияр өчен тагын бер күлмәкләре бар. Әмма илледәгеләр барысыннан да уздыралар. Алары иртәнге ашка – берне, пляжга – икенчене, кичкә өченчене кияләр. Күлмәк алыштырып ашханәгә барганда кисәк кенә борылып кире кайтып киткәннәре дә бар. Чөнки аллея буйлап нәкъ шундый күлмәк кигән икенче берәү килә икән. Хатыннар үзләренеке төсле күлмәк кигән икенче бер хатынны бер дә яратмыйлар. Андыйлар кара-каршы очрашканда, берберсенә үтергеч салкын караш ташлап узалар, һәм шул көннән соң бер-берсе белән исәнләшми башлыйлар. Остарак ирләр күлмәк сылтавы белән аларга матур сүзләр әйтеп калалар.

– Сезнең күлмәгегез гаҗәп матур!

– Ә мин үзем матур түгелме?

– Юк, мин әйтеп бетермәдем. Сезнең күлмәгегез сезнең өстегездә булганлыктан икеләтә матур.

– Рәхмәт.

Мактау сүзен тары боткасы май сеңдергәндәй йоткан хатын, җиңелчә генә кызарып, дулкынланудан аякларын саташтырып китеп бара. Бакчада тын буылырлык кершән исе аңкып кала...

Диңгез буенда бар бер сылу кыз. Унсигез-унтугыз яшьләрендә. Институтта укыйм, ди. Ял итүчеләр арасында иң яше. Кызның нибары ике-өч күлмәге күзгә күренә. Берсен һәр көнне кич кия. Бер-икесе гап-гади ситсы күлмәкләр. Хатыннар белән карта уйнап яткан ирләр, пляжга ул төшеп басуга, сылтаухәйлә табып, аның янына акрын-акрын җыелалар.

– Ничек йокладың?

– Өең сагындырмыймы?

– Бүген кич кая барасың? – дип, сораулар белән аны күмәләр.

Кызый, саран гына елмаеп, резин башлыгын кия дә диңгезгә кереп китә. Аның арзанлы күлмәге, туза башлаган туфлиләре янында таза, юан абзыйлар басып калалар.

«Ах, шул кызыйга иң кыйммәтле туфли бүләк итәргә иде! Ләкин ничек? Кабул итмәс бит ул почык борын. Стипендиягә генә ничек яшәмәк кирәк?»

Аена дүрт йөз сум ала торган зур трест җитәкчесе диңгезгә карап, ахрысы, әнә шуларны уйлый.

«Их, шушы кыз белән бер генә кич бакчада сөйләшеп утырырга иде! Шушында, ял иткән җирдә үк, мәхәббәт, яшьлек турында бер шигырь язар идем!»

Чал чәчле шагыйрь, ахрысы, шулай уйлый.

Әмма Гаҗилә җиңги алай уйламый. «Савыгып, исән-имин генә кайтып китә алса ярар иде бу бала. Ялгышып китмәсә ярар иде, ирләр бик күп», – дип, Гаҗилә җиңги аның өчен борчылып утыра.

Юан-юан хатыннар яр буенда дулкын эчендә тәгәриләр.

Студент кыз ерак-еракка кереп китә. Ул йөзгән җирдә акчарлаклар уйный. Акчарлаклар атылып-атылып аның турысына төшәләр дә дулкынга борыннарын төртеп һавага күтәреләләр. Кыз йөзә дә йөзә...

...Кич җитә. Студент кыз, үзенең ябык якалы кара йон күлмәген киеп, ашханәгә таба бара. Бакча юлында исә күлмәкләр күргәзмәсе: вак чәчәкле, эре чәчәкле, йон, кримплен, нейлон, лавсан, зәңгәр, соры, ак, диңгез дулкыны төсендә, саз төсендә... Бакча юлында куе ислемай исе, кершән исе. Студент кыз

инде ашханәгә кереп китте, ә күлмәкләр дулкыны әле һаман чайкала. Ашыгырга ярамый. Күлмәкнең бөтен матурлыгы бакча эченнән барганда күренә.

Күлмәкләр дулкынына оста телле ирләр тарафыннан мактау сүзләре ява:

– Сезнең күлмәгегез...

– Сезнең загарыгыз...

– Сезнең чәчегез... Фәлән-төгән, – диләр.

Бакча гөрли...

Әмма кайтырга нәкъ бер атна калганда гына, Гаҗилә җиңгинең кинәттән күңеле сынды: ул төш күрде. Сыерын күрде.

Хәбибрахман бер сөйләп утырган булган иде: имеш, адәм баласына төсле төш керми, андый төш керсә, ул бик гайре табигый хәл була, андый кеше белән врачлар кызыксыналар... Менә, кызыксынсалар, Гаҗилә җиңгәне тикшерсеннәр: төшендә ул сыерын нәкъ үз төсендә күрде. Кара елтыр тиреле. Маңгаенда ак кашкасы, бер аягының тояк өстендә ак урыны бар. Сыер ишегалдындагы яшел чирәмдә басып тора. Болар төс түгелмени? Сыерның кара күн елтыр иреннәннән селәгәй ага. Үзе мөгри. Йа Алла! Савылмый калган ул! Зәмзәмбикә оныткан... Йә семьяларында тавыш чыккандыр. Алай дисәң, Миңнулла эчүен ташлаган иде. Ничек кенә булмасын – сыер савылмаган, ул үпкәләгән караш белән башын түбән игән, әкрен генә мөгри, Гаҗилә җиңгинең бәгырен телгәли. Кара танавыннан үләнгә селәгәе сузылган...

Гаҗилә җиңги йөрәк ачысы белән ыңгырашып уянып китте. Палатадагы чибәр хатын әле йоклый иде. Торды, киенде, ишегалдына чыкты. Чинар, платан агачларыннан, куаклардан иртәнге салкынча һавага искиткеч затлы куе ис — туя куаклары исе таралган, түбәндә, ак кояш астында, зәңгәр-карачкыл сихри көзге булып диңгез ялтырый, кичәге гайрәтле дулкыннар күренми. Кырым көне ял итүче, дәваланучы халыкка матур сәгатьләр вәгъдә итеп уянып килә иде. Эвакуатор башта Гаҗилә җиңги белән бәхәскә керде. Билетка заказ бирелгән, срогын үзгәртеп булмый, диде. Әмма Гаҗилә җиңги бирешмәде: чалбар кигән, озын кызыл тырнаклы, яшел керфекле бу кызны рәхәтләнеп сүкте – теге кыз бер авыз сүз татарча белми иде, елмаеп тыңлады. Ярдәмгә әлеге сылу хатын Гаҗилә җиңгинең бүлмәдәше килгәч кенә эш җиңеләйде.

– Җәяү чыктым киттем булыр, аягым ат, кулым канат, – диде Гаҗилә җиңги. – Бу бака күзгә юньләп аңлат әле, әч-чәч, әч-чәч, кыяфәте норсызның!..

Эвакуатор кызый чибәр иде, Гаҗилә җиңги аны юри сүкте, билет алып бирсен дә аэропортка озаттырсын дип сүкте. Тегесе гел елмайды. Чибәр кызга хет яшел, хет шәмәхә булсын, керфекнең ниндие дә килешә...

Институт хатыны да Гаҗилә җиңгинең алдан китүенә әйбер әйтмәде: сагынгач – нишлисең? Аннан, ике кешелек бу палатага, Гаҗилә җиңгинең путёвка көне тулмыйча, икенче кеше кертмәячәкләр иде. Анысы да уен-муен түгел. Диңгездә коенып кайткан яшь, сылу хатынның көзге каршында үз матурлыгына үзе соклана-соклана бер чишенеп киенәсе килмимени? Бәхет, зур бәхет бит ул – матурлыкка карау... Ялгыз бүлмә, гомумән, әйбәт инде ул.

Шулай Гаҗилә җиңгигә ул билет алышты.

Чибәр хатын белән аерылышыр алдыннан, Гаҗилә җиңги, өлкән кеше буларак, аңа үзенең киңәшләрен биреп маташты.

– Көне буе кояш астында ятма, эссе кагар, харап булырсың, – диде. – Тәнең кубалакланып чыкса, нишләрсең? Каның сыекланып калса, нишләрсең?

Чибәр хатын дөньяларны яктыртып матур итеп елмайды.

– И апа җаным! – диде ул чын күңелдән. – Кояшта янган яшь хатын-кыз тәненнән дә матур бу дөньяда тагын нәрсә бар? Кайвакытта, яшькелт-зәңгәр суда йөзеп барганда, үземнең җилкәләремә, беләкләремә күз салам да: «И Ходаем, минме икән бу?» – дип уйлап куям. «И Ходаем, бу матурлыгымны миннән күпсенмә», – дип теләкләр телим...

Гаҗилә җиңги аптырабрак калды. Ахрысы, болар икесе ике телдә сөйләшәләр иде. Ул үзенең йончыган, бушаган тәнен, аксыл-арык җилкәләрен күз алдына китерде. Аның беркайчан да тән турында уйлаганы юк иде. Шуңа күрә сүзне аңлаешлырак мәсьәләгә борды.

– Теге әзмәвереңне дә ташла инде, ирең ишетелсә нишләрсең? – диде ул, борчылып.

Дөньялар тагын яктырып китте – әлеге сылу хатын тагын елмайган икән.

– Ишетелми, ишетелми, апа җаным, – диде ул, көләч елмаеп. – Ишетелсә дә берни булмый. Мине сагынып тора ул. Менә мин аңа бүләк итеп бер шешә бик яхшы вино алып кайтам. Мин кайткач эри дә китә ул. Ул инде болай да бик бәхетле. Миндәй хатын бөтен кешегә дә эләкми ул, апа җаным. Мин бит турылыклы хатын. Минем матурлык икенче бер юньсезгә эләксә, ул хатын почмак саен интервью биреп йөрер иде. Мин андый түгел. Егерме дүрт кенә көн бит ул, апа җаным...

Гаҗилә җиңги моңарчы да бу хатынның телен аңламаган иде, «интервью бирү» дигәнне ишеткәч, ул бөтенләй өмет өзде: күпме тырышса да, бу хатынның сүзләрен ул аңлый алмаячак иде.

Алар кочаклашып аерылыштылар. Чибәр хатын машина кузгалганда кул болгап калды.

Көн уртасында Гаҗилә җиңги инде Симферополь аэропортында динамиктан «Казан» сүзе ишетелгәнне көтеп утыра иде. Еракта, аэродром түрендәге мәйданда туктап калган ике канатлы кечкенә самолётлар аңа сыер көтүе булып, ә горизонттагы радиолокатор үзенең ак кашкалы кара елтыр сыеры булып күренә иде. Локаторның канаты-антеннасы әйләнепәйләнеп ала, әйтерсең лә Гаҗилә җиңгинең әле дә савылмаган сыерына чебен-кигәвен килеп бәйләнә, сыер, шуларны куып, башын, койрыгын селки иде...



Айгөл Хөснуллина – яңа авторыбыз. «Сөембикә» журналында бүген аның дебюты. «Казан утлары», «Идел» журналларында повесть-хикәяләре, «Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре» кебек газеталарда язмалары чыккан кызның инде хатын-кыз холкын, кичерешләрен оста тасвирларлык каләме дә бар, тормыш тәҗрибәсе дә җитәрлек. Гаилә, мәхәббәт, ачы язмышлар, кызыклы хәлләр турында язарга ярата ул. Айгөл – Туфан Миңнуллин әсәрләрендә мактап язылган Тау ягыннан, Кама Тамагы районы Кыртапа авылы кызы. Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм көнчыгыш телләре бүлеген тәмамлаган. Бүгенге көндә Татарстан Язучылар берлегендә эшли.



Айгөл ХӨСНУЛЛИНА

ТУҢ ЙӨРӘК

(хикәя)

Күңелләр җилкенгән чак! Яз белән ниндидер илаһи хисләр яңара, яратасы, яратыласы килә. Җылы кояш нурларында коенып, бәхеттә йөзгән парлар урамда ешрак очрый. Әнә бит каеннар да талгын гына җилдә бер-берсенә сарылып тирбәлә! Бар җиһан мәхәббәт диңгезендә йөзә сыман.

Яраткан кешең булу, аны көн саен янында күрү – зур бәхет. Тик адәм баласына үзен дә кемнеңдер кадерлесе итеп тою кирәк. Гүзәл гомер буе назга, кадер-хөрмәткә нәүмиз булып яшәде. Ире Илнур өйләнешкәнче дә «яратам» дигән сүзне еш кабатларга яратмады, бергә тора башлагач, бөтенләй әйтмәс булды. Беренче елларда Гүзәл ире турында, артык горур, тәкәббер, үз хисләрен чәчәсе килми дип уйлады. Тора-бара матур сүзләрне ишетмәскәияләнде, күнде. Дус хатыннары бәйрәм саен ирләре биргән бүләкләрне күрсәтеп мактанганда, Гүзәл мөһим эш белән шөгыльләнгән кыяфәт чыгарып, сүзгә кушылмый гына утыра бирде, ахырда ул 8 Мартны да, туган көннәрне дә күрә алмас дәрәҗәгә җитте. Иренең сүзе бер булды:

– Акча синдә, тиененә кадәр алып кайтып бирәм, үзеңә кирәген сатып ал!

Гүзәл үзе дә акчаны яхшы эшли лә ул, шуңа да зәвыклы киенә, үзен гел карап йөри. Теләгәнен сатып алу аның өчен берни дә тормый.

Барысы да бар, җитәрлек, дип әйтергә ияләнсә дә, бәйрәм саен иренең бер кечкенә чәчәк бәйләме булса да күтәреп кайтуына өметләнә. Тик ул өметләр, һәрвакыттагыча, бәллүр пыяла савыт сыман чәлпәрәмә килә дә куя...

Кайбер көннәрдә Гүзәл үзен беркемгә кирәксез кеше итеп тоя башлый. Эштә дә аңа артык игътибар юк сыман тоела, ире кайта да, ашап алгач йә телевизор карый, йә сәгатьләр буе кесә телефонына текәлеп утыра. Шул чакларда Гүзәл нидер сөйли башласа, ул аның тиз генә авызын ябарга ашыга: комачаулама, янәсе. Хатын ачудан телефонын алып идәнгә бәрүдән, телевизор пультын чүплеккә салудан көчкә тыелып кала. Малае да үсеп буйга җитте, күбрәк үз дөньясында кайный, инде Миләүшә исемле кыз белән очрашып йөри. Иртән чыгып китә, төнлә кайта. «Әнием» дип, элеккеге кебек муенына сарылып иркәләнеп алулар сирәк күренешкә әйләнеп бара. Ярый әле Ходай аңа ахирәте Гөлнараны бүләк иткән. Аптыраган чакларында аңа шалтыратса, дусты начар кәефен шундук юкка чыгара, юата, тынычландыра.

– Сулга йөрми, акча эшли, бар җирегез килгән, тагын ни кирәк? Ходайдан курык, шөкер ит. Күпләр синең тормышны кинода гына күрә. Балаң сау-сәламәт, үзең чибәр, яраткан эшең бар. Әнә, күршең Санияне генә кара син. Гомер буе икешәр эштә эшли, акчасы бернигә җитми, шуның өстенә ире көн саен диярлек эчеп кайтып кыйный. Наз, ярату тоеп яшәү кирәк инде, билгеле, тик нишлисең, шундый туң йөрәкле булгач. Ул үзе сине беркайчан



Рәсем: Наталья Васильева

яманлап сөйләми бит, – дип сүгеп тә ташлый.

Бу сүзләр белән килешә Гүзәл. Дөресе дә шул лабаса! Күршесе Саниянең михнәтле тормышы көн саен күз алдыннан үтә. Кибеттә соңгы тиеннәрен санап ипи алып торуларын, ике көннең берендә күзендәге зәңгәр күгәрекне кара күзлек астына яшереп йөрүен дә күрә. Еш кына бурычка сорап кергәндә акча да биргәли. Тик... бәйрәм җитте исә... шул Саниядән дә көнләшә Гүзәл. Аның ире бит иң арзан чәчәк бәйләме булса да алып кайта, алдына тезләнеп гафу үтенә. Туң йөрәк, туң йөрәк.... бер җылы сүз әйтеп, кочаклап алса ни була бу Илнурга. Тик туң йөрәк шундый булып кала бирә.

Ире белән үзе арасындагы салкынлыкны Гүзәл бары кайнанасыннан гына күрә. Киленен беренче көннән үк сөймәде ул. Шуңа да озакка сузмыйча башка чыгарга туры килде. Тик ана кеше тынычланырга уйламады да, киресенчә, килгән саен улына хатынының начар якларын күрсәтеп, тормышларын агулап торды. Башта «Балагыз юк, кысыр», – дип теңкәсенә тиде. Уллары тугач: «Синекеме икән, бер дә безнең якка охшамаган?» – дип шик тудырырга тырышты. Әнисе яныннан кайткан саен ир гел канәгатьсезлек белдерде, хатыныннан гаеп эзләде, еш кына тавыш чыгарды. Аның, гомумән, үз фикере, тормышка карашы юк сыман иде.

Гүзәл сабыр булды, тешен кысып түзде. Бәлки, вакытында «буран» очырып, кайнанасын урынына куйган булса, мондый хәл килеп тә чыкмаган булыр иде. Яраткан кешесен югалтудан, баласын ятим итүдән куркып чыдады, язмышына буйсынып яши бирде хатын. Гомер азагында кайнанасы урын өстендә калып, аның тәрбиясендә өч ел яшәгәннән соң гүр иясе булды.

* * *

Көн дә эштән соң өенә ашкынган Гүзәлнең бүген нигәдер кайтасы килмәде. Улы дуслары белән табигать кочагына китте. Фатирда кабер тынлыгы, ире кайтып, гадәтенчә телевизор каршында урын алгандыр.

Иртәгә шимбә... эшкә барасы юк... ашарга әзерләнгән... Берни, беркем көтми әле анда Гүзәлне. Шуңа да хатын эшеннән чыгуга ашыкмыйча гына җәяүләп кайтырга булды. Уйларына бирелеп, биш тукталышны үтүен сизми дә калды. Йортларын үтеп китеп паркка килеп кергәч кенә айнып киткәндәй булды. Бермәлгә туктап як-ягына каранып алды да паркның икенче башындагы күл янына юл тотты. Язның талгын җиле битләреннән, чәчләреннән сыйпады. Артык чибәр булмаса да, ир-атлар аңа һәрвакыт игътибар итәләр иде. Бу юлы да зифа буйлы, сөрмә күзле, кызыл күлмәк өстеннән ак плащ кигән сылу ханымны күпләр күз карашы белән озатып калды. «Кешеләрне үзенә тартып тора торган сөйкемле сөягең бар синең», – дия аңа туганнан туган апасы. Бәлки, шуңадыр да, башкалар белән җиңел аралаша, уртак телне тиз таба ул. Гомере буе кешенең авыр хәлдә калуын күреп, җылы сүзен әйтергә, кирәксә, җилкәсен куеп таяныч булырга әзер булды Гүзәл. Аның кебекләргә, соңгы чалбарын салып бирүче, диләр.

Бүген ул, соңарып кайтып, ирен борчуга салырга булды. Шул уйларга бирелеп, күл буендагы яшел эскәмиягә барып утырды. Рәхәт. Күл өстендә бәбкәләрен ияртkән пар үрдәкләр йөзә. Аларга карап тору үзе бер юаныч. Бәбкәләр, аерылып китеп, кешеләр ташлаган ипи кисәкләрен эзләптер, күрәсең, яр буена якынаялар, ә ана үрдәк аларны күл уртасына әйди. Горур муенын текә тотып, анда ата үрдәк йөзә. Ана үрдәк урап килеп каршыларына төшкәч, бәбкәләрнең



берничәсе теләми генә артыннан иярә. Тик берсе һаман үзенекен итәргә тели генә бит, туганнарыннан аерылып, гел ярга якынлаша. Шулчак ата үрдәк дәшеп куйгандай итә. Инде бар да, хәтта иң шук бәбкә дә, гаилә башлыгына ияреп, күл уртасына йөзә башлый. Үрдәкләр артыннан калган дулкын алкалары акрын гына күл өстенә җәелә. Башта кечкенә генә түгәрәк хасил итеп, аннан тәмам җәелеп китеп, алар яр буенда башларын түбән игән камышлар арасына кереп югала.

Сукмактан акрын гына култыклашып килүче шактый олы яшьтәге бер пар Гүзәлнең игътибарын җәлеп итте. «Тигез картайганнар... Шулай гомер буе бер-берләрен кадерләп, авыр сүз дә әйтмичә яшәүчеләр дә бар бит ул. Шундый тигез картлыкка, бер-береңә олы хөрмәткә ни җитә! Илнур белән без алар яшенә җиткәндә нинди булырбыз икән?» – дип уйланып утырды хатын.

Көн бетүен сиздереп, кояш офыктан аска тәгәрәде. Һава суларга чыккан бала-чагалы әти-әниләр дә, этләрен ияртеп йөрүчеләр дә әкренләп бер-бер артлы күздән югалды. Күл буендагы аргы эскәмиядә бер яшь пар һәм үз уйларына чумып утырган Гүзәл генә калды. Хатынның тәненә ниндидер салкынлык иңде. Өенә кайтырга кирәклеген чамалап, ул эскәмиядән күтәрелде, тик аякларында ниндидер авырлык иде, бер мәлгә атлап китә алмыйча торды. Ире югалтырга өлгерде микән соң әле? Нигәдер шалтыратып та эзләми. Ни дисәң дә – туң йөрәк.

Теләр-теләмәс кенә хатын кайтыр сукмакка таба борылды. Киң сукмак, бара торгач тараеп, өсләре кырылган куаклык арасына сузылып китә иде. Гүзәл әллә нигә шомланып калды. Караңгы төшә... Әңгер-меңгердә күзе дә начаррак күрә, җитмәсә. Тавык күзе диләрме әле?! А витаминнары җитмәгәннән шулай була дип укыганы бар. Адымнарын тизләтте. Шулчак капылт кына каршында бер ир заты пәйда булды:

– Чибәркәй, кая ашыгасың, әйдә, бераз аралашыйк?!

Гүзәл ни дияргә дә белми өнсез калды. Кая чабарга, нинди юнәлештә? Кычкырса да беркем ишетмәс... «Беттем», дип уйлап куйды хатын. Гүзәлнең куркып калуын сизеп, ир йомшаграк тавыш белән сөйләшергә кереште:

– Курыкмагыз, мин сезгә тимим... Ялгызыгыз гына бу вакытта йөргәч, минем кебек җан җылысы эзлисезме әллә дип кенә туктаттым.

– Юк, берни дә эзләмим, эштән кайтып барышым, – диде Гүзәл, ялганлый белми торган күзләрен яшереп.

– Бәлки, сезне озатып куяргадыр? – дип серле елмайды ир-ат.

– Юк, кирәкмәс, хәзер каршыма ирем килә, – дигән булып, Гүзәл адымнарын тизләтте. Башында бер генә уй: «И-и Ходаем, ярдәм ит, артымнан гына башыма сукмасын». Борылып карарга кыймыйча бераз баргач, хатын бар көченә йөгерергә кереште. Тар сукмактан олы машиналар йөри торган юлга чыккач кына борылып карарга җөрьәт итте ул. Беркем дә юк иде. «Уф!.. Йөриләр шунда кеше котын алып... Җан җылысы кирәк, имеш!» Үзенең бу фикереннән үзе имәнеп китте Гүзәл. Үзе дә шул җан җылысын эзләп йөри түгелме соң ул? Үз башыңа ашкыну шушы, күрәсең. Бу фикере аны тәмам айнытып җибәргәндәй итте. «Ярый ла берәр төрле маньяк булмады, ятар идең хәзер берәр чокырда», – дип үзен-үзе битәрләп, йортына якынлашты. Подъезд ишеген ачарга гына үрелгән иде, атылып Илнур килеп чыкты:

– Кайда йөрисең син, әллә ниләр уйлап бетердем!.. Бөтен кешене аякка бастырдым!.. Телефоның эшләмиме әллә? – дип тезеп китте ул ашыгып.

Гүзәл, ни дияргә дә белмичә, сумкасындагы телефоннын барлый башлады.

– Зарядкасы беткән бугай, сүнгән...

– Мине борчылып тора дип уйламыйсың да син, Гүзәл, – дип үпкәсен белдерергә ашыкты Илнур.

– Кибеткә кергән идем, вакыт үтүен сизми дә калганмын, гафу ит инде, син мине югалтырсың дип уйламадым да, – диде хатын иренә сөрмәле күзләрен текәп. Икәүләп ишектән эчкә узып, берни сөйләшми генә баскычтан менә башладылар. Өченче катка җитәрәк, Санияләр ишек төбендә бераз туктап калдылар. Фатир ишегенең икенче ягында гөрселдәп нидер ауды, ир-атның сүгенеп кычкыруы, балалар елавы, Саниянең «җитәр инде сиңа!» дигән тавышы ишетелде.

– Тагын исерек, бәдбәхет, – диде Гүзәл ачуын тыя алмыйча. – Балалар, Сания кызганыч...

Илнур, килешкәндәй, башын чайкады да хатынының иңбашыннан йомшак кына кочып, баскычтан алып менеп китте. Ишектән кергәч, Илнур гадәттәгечә утны яндырырга ашыкмады. Алар ярым караңгылыкта аяк киемнәрен салдылар. Гүзәл ут кабызырга дип үрелгән иде, ире аның кулыннан тотты.

– Гүзәл, бүген бит бездә аулак, син шуны беләсеңме? – диде.

– Нинди аулак, ни сөйлисең син?

Ире аның плащын салдырып элеп куйды, Гүзәлне җитәкләп түргә – йокы бүлмәсенә алып кереп китте. Анда идәнгә шәмнәр тезелгән, ятакта чәчәк таҗлары сибелгән. Кечкенә генә өстәлдә кичке аш әзерләнгән иде.

Гүзәл тәмам сәерсенеп иренә төбәлде:

– Синме соң бу, Илнур?

– Малай белән булачак килен булышты!

– Нинди килен?!

– Малай Миләүшә белән кайткан иде, тиздән өйләнәм ди, сине озак көттек, мин аларга бүген безнең никахлашканга егерме биш ел дип сөйләгән идем, сюрприз ясарга булдылар, – дип елмайды Илнур.

– Ә минем башымнан да чыккан... Әйе, бүген егерме бере бит әле...

– Шул-шул менә.. Тиздән бик күңелле булачак бездә, Гүзәл. Әби белән бабай да булып куярбыз, Алла теләсә. Ә бүген бездә аулак, безгә егерме биш ел. Мин сине бик яратам, Гүзәлем, син минем иң кадерле кешем, – дип хатынын кочып алды Илнур.

– Туң йөрәк, туң йөрәк... Менә сиңа туң йөрәк, – дип пышылдады Гүзәл...

НИЧЕК ДУСЛАШТЫРЫЙМ?

Гаиләбездә ике малай үсә. Олысына 14 яшь, ул минем беренче никахтан туган улым. Кечесе – 5 яшьлек, хәзерге ирем белән уртак балабыз. Ирем олы улымны какмый-сукмый, якын итә. Безнең проблема бөтенләй башка: олы улым энесен берничек тә кабул итә алмый. Югыйсә аңларлык яшьтә бит инде. Азмы-күпме энесен караша да ала. Әмма ярдәм сорасаң, минем балам түгел, үзегез карагыз, ди. Кечкенәсе абыйсына тартыла, аның белән уйныйсы, аның янында буласы килә. Ләкин улым аны этеп тә җибәрергә мөмкин, энесенә тупас итеп эндәшү, җикерену дә – аның өчен гадәти хәл. Ничек дуслаштырырга ул балаларны? Олы улымның энесенә булган мөнәсәбәтен ничек үзгәртергә?

Нурзилә М.
Казан.

Зәмирә РӘҖӘПОВА-КУПРИЯНОВА, телевидениедә алып баручы.

Безнең гаиләдә мондый проблема юк. Бездә, киресенчә, Аяз энесе Данилны бик ярата. Хәтта мин ачулансам да: «Ул бит әле кечкенә, аңламый», – дип, энесен гел яклап чыга. Үз улымнан күреп әйтәм, 14 яшь – ул инде барысын да аңларлык яшь. Авторның гаиләсендә мондый күңелсезлек бар икән, димәк, сәбәбе бар. Бәлки, көнчелектер ул. «Улым, мин икегезне дә бертигез яратам. Икегез дә бик кадерле миңа», – дисә әнисе, абый кешенең энесенә һәрчак терәк булырга тиешлеген аңлатса, олы улының да карашы үзгәрер иде, бәлки. «Сез үсәрсез. Энең дә гел кечкенә малай гына булып тормас. Бу рәвешле син аны үзеңә дошман итеп үстерәсең бит», – дисен. Ләкин ничек кенә булмасын, әлеге проблеманың сәбәбен ачыклау кирәк. Юкса бу дошманлык гомер буена барачак. Бәлки, әни кешенең үзенә сорашып карарга кирәктер, бәлки, психолог ярдәм итә алыр.

Тагын бер мөһим әйбер: «Син зур инде, юл куй», – дип, гел олысын гына тыеп тору да дөрес булмас. Мин кайчак кечкенәсенә: «Абыең синнән олырак, син аны тыңларга тиеш», – дим. И-и Аязның күңеле үсеп китә инде шул сүзләрдән соң. Балаларны үстергәндә тигезлек балансын саклау әһәмиятле.

Максим КУПРИЯНОВ, музыкант.

Дәүләттә ниндидер проблемалар туса, аны хәл итәр өчен Президент бар. Тышкы проблемаларны да, эчкесен дә ул хәл итә. Ә гаиләнең президенты – әти кеше. Гаиләдәге проблемаларны да ул чишәргә тиеш. Бу очракта мин әни кешегә ире белән сөйләшергә киңәш итәр идем. Олы уллары белән әтиләре сөйләшсен. Ир-егетләргә үзара килешү, проблеманы ачыктан-ачык сөйләшеп хәл итү уңайлырак. Яшүсмер егетнең үзен болай тупас тоту сәбәбен ачыклау мөһим. Минемчә, бу – көнләшүдер. Әниләре бар игътибарын энекәшенә бирә кебек тоеладыр. Бәлки, чынлап та аңа игътибар җитмидер. Проблемаларны әйтеп сөйләшүдән курыкмаска кирәк. Гаиләдә бары тик ышанычлы мөнәсәбәтләр генә ыбулсын.

Белгеч фикере



Ләлә БӘҺРАМШИНА, психолог

Яшүсмерләр белән эшләү кайчак чынлап та җиңел түгел. Сәбәбе күп инде. Холкындагы кытыршылыклар организмдагы җитди үзгәрешләр белән дә аңлатыла. Баланың нерв системасы әлегә озакка бара торган көчәнешләрне чыдата алмый. Әти-әниләргә аны ничек тыңлатырга соң?

Кушканыбызны үтәми. Бу, мөгаен, әти-әниләрнең иң еш әйтә торган зарыдыр. Моның сәбәбе йә ялкаулык, йә курку гына була ала. Бу очракта улыгызга энесе белән ни өчен үзен туганнарча тотарга кирәклеген аңлатырга кирәк. Энесе бит тиздән үсеп җитәчәк. Алар ике бертуган, берберсенә бик кирәк булачаклар.

Бу яшьтә балалар үзләрен башкалардан үзгә, үзенчәлекле итеп күрсәтергә тырыша. Моны да әти-әни дөрес юнәлештә куллана ала: «Улым, энең синнән үрнәк ала, ул сиңа охшарга тырыша».

«Бар әле, энеңне уйнат!» – дисәң, яшүсмернең кирелеге уяна. Шуңа да яшерен инструкцияләрне кулланыгыз. «Хәтерлисеңме, теге юлы әкиятләр укып, син аңа күпме яңа әйбер өйрәттең. Син булышкач, миңа да бик уңайлы». Һәм, әлбәттә, улыгызның аз гына тырышлыгын да игътибарсыз калдырмагыз. Гамәлләренә детализация ясагыз: нәрсәсе яхшырак килеп чыга. Баланың бигүк уңай булмаган гамәлләрен аның шәхесе белән бәйләүдән сакланыгыз. «Син – тупас», диясе урынга, «Без сине бик яратабыз, әмма энеңә карата тупас булма», – дип әйтү баланы уйландырыр.

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Сугыш еллары берәүне дә читләтеп үтмәгән. Бу елларның барлык авырлыгын – ачлыгын, ялангачлыгын, михнәт-газапларын да кичереп, бүгенге көндә дә тормышны, кешеләрне яратучы авылдашыбыз Фәрхисорур апаның хәлен белергә барган идек. Сугыш чоры ачыларын күргән ветеран белән сөйләшеп, аның истәлекләрен озак тыңлап утырдык без ул көнне...

Шәрипова Фәрхисорур Кәраметдин кызы Мөслим районы Салауз-Мухан авылында 1933 елда туган. Бөек Ватан сугышы башлангач, 8 яшендә беренче класска укырга керә. «Язарга кара булмады. Мичнең корымын кырып, аны суда җебетеп, язу карасы ясый идек. Каз каурыен очлап ясаган каләмне шул карага манчып, язу яздык. Кияргә кием булмады. Әмма җаен таба идек. Киндерне йолкып, җиргә салып таптыйсың, сүсен чыгарасың, һәм шуны әнкәй җегерләтә иде. Махсус станнарда сугып, шулардан әнкәй күлмәкыштан текте. Юкә мунчаласыннан чабата үрдек. Сугыш булса да, уку тукталмады, безне дә илне сакларга өйрәттеләр. Әзһәр абый Апукаев – военрук иде. Ул безне йөгертте, окоплар казытты. «Ложись!» – дип кычкырып җибәрүе була, без кыш көне кар өстенә барыбыз дәррәү егылабыз. Бик авыр булды ул еллар, әмма сынмадык, сыгылмадык. Ашарга юк. Унике чакрым юл узып, Үрнәк авылы аша Урыс авылына кәлҗемәгә йөрдек. Басу, бакча казып, кәлҗемә җыясың, аннан кире җәяү кайтасың. Әнкәй шул кәлҗемәне чыжлап янган чи тал белән җылытылган мич төбенә куеп пешерә иде. Җиңү көнен бөтен халык түземсезлек белән көтте. Бу изге яңалыкны безгә мәктәптә барыбызны бергә җыеп аңлаттылар. Ул вакытта балалар күп иде, барыбыз да шатлыктан елый-елый бик озак «Ур-ра» кычкырып йөрдек. Шул елны җиденче классны тәмамладым. Алга таба да укыйсым килде. Әмма Мөслимдә уку түләүле иде. Китап-дәфтәрләр өчен акчаны кара бөрлегән сатып җыйдым. Көн саен әрәмәгә барып чиләгеңне тутырып җыясың да шул ук көнне, биш чакрымдагы Мөслимгә барып, стаканлап сатып та кайтасың. Әмма ярты ел гына укырга насыйп булды. Әткәй чирле иде, акча булмагач, укуны ташлап, эшкә кердем. Чанага ат җигеп, көн саен Мөслимнән почта алып кайттым һәм аны кешеләргә таратып чыга идем. Бәләкәй Чакмак авылы почтальонына да мин почта алып кайта идем. Эшләгән акча бик аз булгач, Лаеш урманына агач кисәргә бардым. Кама елгасы буйлап Әстерханга кадәр сал агызуда катнаштым. Үзебез дә сал белән агып бардык. Менә шунда инде, алты ай эшләгәч, баеп кайттым дисәң дә була. Әткәйгә, абыйга костюм, әнкәйгә матур яулык, үземә костюмлы күлмәк сатып алдым, таслар, чиләкләргә дә җитте ул эшләгән акчам. Кайткач, колхозда эшли башладым. Авылыбыздагы мәктәпкә Әмирҗан Шәрипов исемле укытучы килде. Гармунда уйный, математик, үзе чибәр, бик ачык кеше. Мин дә бик кыю идем. Вечерларда биедек, спектакльләрдә бергә уйнап йөри торгач, Әмирҗан белән дуслаштык. Озакка сузмый өйләнештек тә. Мин һәрвакыт тырыш булдым, бер эштән дә курыкмадым. Бианай белән биатайны тәрбияләдем. Әмирҗаным белән өч бала үстердек. Балаларым да, киявем белән киленем дә бик тәүфыйклы, тырышлар. Кызым Фәйрүзә үзенең гаиләсе белән Чаллыда яши. Дамирым – Казанда. Рәсим улым тумыштан инвалид булды. Ходай шулай кушкандыр, шул балам белән бергәләп тормыш итәбез. Балаларым һәрвакыт булышып тора. Аллага шөкер, 87 нче яшем белән барсам да, сарыклар да асрыйм, тавыкларым да бар. Эшсез тора алмыйм мин. Тормышым бик җитеш. Без күргән сугыш афәтләрен балаларыбыз, оныкларыбыз күрмәсен иде. Күгебез аяз, илебез тыныч булуын телим мин. Ил җи-

Фото: Анна Арахамия

тәкчеләребезгә ныклык, түземлек, көч бирсен иде, Ходай!» – дип сөйләде дә, сөйләде Фәрхисорур апа.

Һәрвакыт киң күңелле, җор телле, ачык йөзле һәм ярдәмчел Фәрхисорур апабызга инде күзләр генә тимәсен. Алардан кеше өзелеп тормый, хәлен беләләр, дуслары да күп аның. Тугаштан, Табыннан да, киңәш сорап та, ярдәм итәргә дә гел килеп торалар.

Рафаэль ЗАРИПОВ.
Мөслим районы,
Тегерманлек авылы.

Ноябрь башында Адлерга Кара диңгез ярында ял итәргә барган идем.

Аның матурлыгы әле дә күз алларыннан китми: зәңгәрсу төстәге су, биек-биек дулкыннар күбекләнеп ярларга килеп бәрелә. Көз ахыры булса да, су коену бәхете дә елмайды.

Көннәр җылы, ә төннәр җиләс, салкынчарак була торган иде. Кара диңгезнең теге ярында – Төркия. Анда ул чорда 30–35 градус эссе, шул яктан җылы диңгез агымы килде. Минем өчен иң гаҗәбе – мондагы яңа танышларымның күбесе татар милләтеннән булуы. Алар белән рәхәтләнеп үз телебездә аралаштык, сөйләштек. Пансионатта сак хезмәтендә эшләгән Мирсаль исемле кеше Ставрополь өлкәсенең бер татар авылыннан булып чыкты. Ул безгә авылларында сакланып калган татар-башкорт йолалары турында сөйләде. Алар авылындагы егетләр кайсы милләт кызына өйләнсә дә, хатыннары ислам диненә күчә, балаларын татарчага өйрәтәләр икән.

Милләтем өчен сөенеп кайттым бу ялдан. Бердәмлектә – байлык һәм көч, ә төрле якка таркалып яшәү бары тик хәлсезләнүгә һәм көчсезлеккә генә китерә.

Барыгызга да исәнлек-саулык, озын гомерләр телим, милләттәшләр!

Лилия ФАЗЛЫЕВА.
Свердлау өлкәсе,
Югары Пышма авылы.

Әле күптән түгел генә «Комсомольская правда» газетасы ТАССРның 100 еллыгына багышлап, «Татарстанның 100 легендар бренды» дигән тавыш бирү игълан иткән иде.

Күзем исемлектәге «Сөембикә» журналына төште дә, игътибарым бер мизгелгә туктап калды. Бу бит безнең әбиләр, әнкәйләр һәм үзебез укып үскән «Азат хатын»ның дәвамчысы «Сөембикә» журналы дип уйлап куйдым.

Аңа да тавыш бирүчеләр шактый. Димәк, халык ярата, аңа битараф түгел дип канәгатьләнү хисе кичереп утырганда, «кылт» итеп моннан 42 ел элек булган бер вакыйга искә төште. Без Казан дәүләт университетының 5 нче курсында укыганда Балтыйк буе республикаларына музей практикасы экспедициясенә барган идек. Ул чакта безнең илебез күпмилләтле СССР иде әле. Ригадагы бер музейга кергәч, экскурсовод үзләренең милли матбугаты белән таныштырды. Иң истә калганы шул булды: ул безгә латышларның зур тираж белән чыга торган хатын-кызлар журналын күрсәтте. Тиражы ничек шулкадәр зур дип сорагач, без аны саклап калу өчен, гаиләдә ничә хатын-кыз бар, шулкадәр алабыз дигән иде. «Сөембикә» безнең республикада да хатын-кызларга адресланган бердәнбер журнал. Татар халкы Россиядә икенче урында дибез. Димәк, аны татарлар яшәгән төбәкләрдә дә алалар дигән сүз. Шулай булганда, ул бит алдынгы рәтләрнең берсендә булырга тиеш. Үзебезнең милли хисебез уянмаса, татарлар бетәбез, дип чаң сугуның кирәге булыр микән?! Аның үткәнендә безнең әниләребез, бүгенендә без үзебез, киләчәгендә безнең киләчәк буын булса гына милләтебез һәм телебез яшәр!

Фирдәүсә КӘРИМОВА.
Казан шәһәре.

Замана алга бара, яңа законнар чыга тора.

Көтелмәгән яңалык: хөкүмәт беренче баласын алып кайтучы әниләргә дә ана капиталы бирелү турында хәбәр итте. Бу – күпләр өчен зур шатлык.

Акчалата ярдәм кемгә комачауласын бу заманда?! Тормыш алып бару бик җиңел түгел бит. Бигрәк тә яшь гаиләләргә. Шулай да, акчалата ярдәм бирү төрле бәхәсләр дә тудырды. Акча белән генә илнең демографик хәлен җайга салып булырмы икән?! Акчага гына кызыгып бала табу киләчәктә төрле күңелсезлекләргә китермәсме?! Бездә бала пособиесе яңа закон буенча 7 яшькә кадәр бирелә бит. Аннан баланың бәхетле киләчәген кайгырту барыбер әти-әни җилкәсенә кала. Германиядә бала пособиесе түләү – 18 яшькәчә, Бөекбританиядә 16 яшькә чаклы икән... Балаларны балигъ булганчы кайгырту безнең илдә дә комачауламас иде!

Узган ел безнең гаиләгә икенче бала өчен ана капиталы алу бәхете тиде. Әмма аны алганчы никадәр урау юллар узарга, документлар җыярга, кәгазь эше аша узарга туры килгәнне үзебез генә беләбез. Тиешле акчаны кулга төшергәнче шактый катлаулы процесс узарга кирәк. Хәер, балаларымны өстәмә акча бирмәсәләр дә, барыбер табар идем. Бала назын, әни булу бәхетен тагын ни белән чагыштырып була икән соң?!

Шулай да, минем башта бер сорау әйләнә соңгы вакытта: беренче, икенче балага ана капиталы түләүләр, өченче балага җир бирүләр... Бала элеккечә мәхәббәт җимешеме соң ул хәзер, әллә акча җимешеме?!.

Альбина ГАЛЛӘМОВА.
Чаллы шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA

«ТАБАМ, КОЧАМ, ҖИБӘРМИМ!»


Фото: Анна Арахамия

Интернеттагы танышу сайтына теркәлгән бер егет менә шулай язып куйган. Игътибарны җәлеп итәр өчен генәме икән, әллә... Танышу сайтларына теркәлү, бәлки, чыннан да, күңел белән ымсынып, нәни могҗиза көтүдән башланадыр. Чыннан да, кем өчендер бер табыласы иде ул! Бер сыенасы иде ул кочакка!..
Танышу сайтларында кемнәр «утыра» соң, кемнәр кемне эзли анда? Мин дә интернет аша танышып карарга булдым әле. Алдан ук кисәтеп куям, экспериментым – журналга язма әзерләү максатыннан гына!

Раилә ХӘЯЛИЕВА

Әйдәгез, танышабыз!

Әле кайчан гына «без интернетта танышып гаилә кордык», диючеләр шундый сирәк, һәм алар үзенә күрә бер замана герое кебек иде. Ә хәзер күп кенә яшьләр үзләренең танышу тарихы турында сөйләгәндә: «Ул мине интернеттан күргән, шуннан язды...» – дип, берәр популяр соцаль челтәрне атый.

Кемдер социаль челтәрләрдә таныша, ә кемнәрдер танышу сайтларының ишекләрен шакый. Ә алар бик күп икән хәзер. Түләүлесе бар, түләүсезе. Иң мөһиме – туган телдә аралашып була торганнары да күп булып чыкты. Нәкъ менә төрле җирләрдә яшәүче татарларны кавыштыруны максат итеп куйганнары да очрады. Интернетта табышу-кавышу темасы белән күптәннән кызыксынам. Барлаган язмышларым, кызыклы (ә кайвакыт шактый күңелсез!) тарихларым да бар. «Интернетта яхшы кеше утырмас!» – ди күпләр. Ә нигә, үзебез дә якыннарыбыз белән күбрәк мессенджерлар аша аралашабыз бит инде. «Онлайн» яшибез, бөтен хәбәрне шуннан алабыз. Интернетта мәхәббәтеңне табу гаҗәп хәлмени бүгенге заман өчен?!

Йәле, кемнәр бар икән «анда», үзем күреп, танышып чыгыйм булмаса.

Инде дистә елдан артык эшләп килүче иң популяр татар танышу сайтына теркәлдем. Катнашучылар саны – 38 538 448 диелгән. Шанслар җитәрлек, димәк! Яшьлек – җилкенчәк, чая вакыт ул. Ә олыгайган саен, күңелдәге киртәләр, уңайсызланулар арта бара. Һәркемнең парлы буласы килә, анысы да гаеп эш

түгел. Ялгызлыктан интегеп, күңел читендә «Их, иңне-иңгә куеп яшәргә яр булса», дигән яшерен теләк белән ялгыз картайганчы, күңел киртәләреннән арынып, бәлки, чыннан да, үз ярыңны табарга талпынып караргадыр?!

Исемем – Мөнирә, 53 яшь, дип күрсәттем. Монда барысы да язып куелган: үз йортың белән торасыңмы, балалар янында яшиме, аерыммы, хезмәт хакың уртачадан зурракмы, кимрәкме, буең, чәч-күз төсең, кызыксынуларың... Сиңа туры килгәннәрен билгеләп кенә чыгасы. Фото куймадым. Бер айга фотосыз да ярап торыр... Алай да беренче көнне минем анкета «популярлар» арасында иде. Кичкә уннан артык хат алдым! Кемдер елмаюлы смайлик җибәргән, кемдер хәл белешеп язган. «Үзем тирә» ир-егетләр дә бар, яшьрәкләр дә сәлам җибәргән. Әйе, яшьләр дә җитәрлек монда. Иркутск, Мәскәү, Саратов... Чит илләрдә яшәүчеләрнең дә анкеталары бар. Гаилә корыр өчен үз милләтеннән кәләш эзлиләр! Дин бер булгангамы икән, төрек ир-атлары да күп «утыра» булып чыкты бу сайтта. Әле беренче көнне үк 55 яшьлек төрек ире язган иде. Танышырга телим, үзең турында сөйлә, дигән. «Миңа кияүгә чыккан хатын-кыз Истанбулга күченеп, әнием һәм минем белән яшәргә тиеш була. Син ризамы?» – дип тә өстәгән.

Татарстанның Казаннан ерак түгел бер районында яшәүче, миннән (бу очракта Мөнирәдән дип укырга кирәк!) шактый яшь егет бик еш яза башлады. Үзе турында күп сөйләмәсә дә, берничә көннән бастырып телефон номеры сорый бу. Максаты ни булгандыр егетнең, әмма: «Үз тиңеңне эзлә, энем», – дип хушлаштым мин аның белән. Алдан язганнар белән дә элемтәдә торам, яңа язучыларга да хәбәр салам. Кайбер кешеләр шактый актив, кайберләре бер генә тапкыр «Сәлам!» дип яза да, туктый... Карале, минәйтәм, үзем язганнар белән генә язышып утырып булмас бит инде, үзем дә язып карыйм әле! «Үз тиңемдә» булганнарның анкеталарын ачып куйдым: Казан, Мәскәү кешесе, берсе – Германиядән... Башлап язарга кыюлык җитми генә бит! Ни дип сүз башларга?! Соңыннан, белгечләр белән аралашкач аңладым, танышу сайтларына кергән олы яшьтәге татар хатын-кызларының күбесенә хас күренеш икән ул. Ничек инде таныш түгел ир-ат янына барып сүз башлыйсың?! Безнең табигатькә хас гадәт түгел лә! Ләкин танышу сайты – тыйнаклык саклап тора торган җир түгел. Максат куйдыңмы – тәвәккәлләргә кирәк! «Исәнме, хәлләрең ничек?» Хатларның күбесе менә шулай гади генә языла. «Әйбәт! Үзең ничек?»тән сөйләшү башлана. Мин, хыялланып, беренче хатларымда: «Карсыз Казаннан кайнар сәлам!» дигән булган идем. Хмм... узган гасырда калганмын, ахры, хәзер алай аралашмыйлар икән... Андый хатларыма әллә ни җавап биреп торучылар табылмады. (Әллә карсызлык алҗытканмы?!) Шулай да 57 яшьлек бер абзый авызыннан зур итеп сагыз шары чыгарып шартлатучы смайлик куеп җибәргән иде. Рәхмәт инде, монда да шар кабартучылар бар икән...

Танышулар сайты күпләр өчен аралашу мәйданы гына бит ул.

Хатларга җитди итеп язучылар да булды. Ә берәү: «Сез җитди итеп аралашырга телисез бугай. Ә мин өйләнгән кеше. Минем монда танышып, сирәк кенә очрашып, яратышып кына йөрисем килә», – дип ачыктан-ачык язган иде. Вакытны әрәм итмик, безнең инде картлыкка таба, дип, төрле килешмәгән тәкъдимнәр белән язучылар да булды. Җитди итеп, бер-беребезне якыннан белешик, дигән ихлас тәкъдимнәр дә яңгырады.

Бу сайтта 26 яшьлек кызлар да, 63–65 яшьлек ханымнар да бар иде. Ир-атларның да яшьрәкләре бар, картраклары... Теләгән кеше белән языш!

Альфонслар, кредит түләтүчеләр...

Танышу сайтларында 50% ирләр һәм 50% хатын-кызлар утыра, ди белгечләр. Максат бер – танышу. Әмма ни өчен танышу?!

...Район үзәгендә гомер итүче Заһир абый классташы аша таныша ул хатын-кыз белән. Үзенең тормыш иптәше, авырып, инде күптән вафат булган. Заһир абый пенсиядә булса да, агач эше белән шөгыльләнә, егәре нык. «Эшләп кергән җиремә чәй куеп торырлык, өенең бизәге булырлык берәр хатын булмасмы икән», – дип шәһәрдә яшәүче классташына үзе мөрәҗәгать итә. Классташы танышулар сайтын ачып карый да, язганнары буенча Заһир абыйга туры килә торган хатын-кызны барлап, телефон номерларын бирә. Калганын үзләре килешә. Ике атна дигәндә, ул ханым Заһир абыйга күчеп яши дә башлый. Никах та укыталар. Уңган хуҗабикә йорт-җирне дә карый, хатын-кыз эшләрен яратып башкара, юмалап, өч атна дигәндә, берәм-берәм Заһир абыйга башта – үзенең, аннары улының кредитларын да түләтеп бетерә һәм... озакламый китеп тә бара... Өенең нуры барлыкка килде дип очынып йөргән Заһир абый эшнең нидә икәнен аңламый да кала... Аңлашырга дип шалтыраткач, «Ачуланма инде, минем дус хатыннар да шулай итә, яшәргә кирәк бит», – ди...

Сайтта утыручы альфонслар, ялганчылар турында да күп ишеттем. Ялгызлыктан өзгәләнгән хатын-кызга мул итеп матур сүзләр яудыралар, бәхетле киләчәк вәгъдә итәләр дә, бер тамчы җылыга нәүмиз җанны кармакка каптыргач, кинәт «авыр хәлдә» калалар икән – йә әниләре үлеп китә, йә үзләре авырый башлый, йә киләчәктә икәү яшисе йортка акчалары җитеп бетми...

«Күңелегезгә киртләп куегыз: мөнәсәбәтләрдә ихлас булган ир-ат хатын-кыздан беркайчан да акча сорамый. Ир кеше табигате белән – табучы ул. Авыр хәлдә калганда да ярдәм сорарга ир-ат дуслары, танышлары була аның, – ди психолог Галия Гыйма-

Бар ул бер-берсен танышу сайтларында очраткан бәхетле кешеләр.

диева. – Шулай ук танышу сайтларына керүчеләр көткән кешемне шиксез очратырмын, дип, артык өметләр багларга мөмкин, ләкин мондый күзаллаулар чынбарлыкка туры килми. Шуңа күрә күңел кайту очраклары да була кайчак. Экранның теге ягында кем утырганны беркайчан да йөз процент белеп бетерә алмыйбыз бит. Үзегезгә дә артык яхшы булып күренергә тырышмаска киңәш итәр идем. Ялган барыбер калкып чыгачак, соңыннан уңайсыз хәлдә калуыгыз бар. Бәягезне дә төшермәгез. Безнең хатын-кызлар бит еш кына үзләренең уңай ягын табып күрсәтә белми. Тагын шунысына да игътибар итегез, язышканда ук күңелегез тартмый, аралашуда үзегезне ничектер уңайсыз хис итәсез икән – киләчәктә бу кеше белән нидер килеп чыгасы икеле. Аралашкан кешегезгә яшәү рәвеше, элеккеге мөнәсәбәтләре турында да сораулар бирергә уңайсызланмагыз. Бәлки, нәкъ шул мәгълүмат киләчәктә сезгә дөрес нәтиҗә ясарга ярдәм итәр. Иң мөһиме – языша башлаганчы, үзегез нәрсәгә яраклаша алу-алмавыгызны барлап куегыз. Башка шәһәргә, илгә күчеп китәргә әзерме сез, ир кешенең әнисе белән бергә яши алачаксызмы...»

Тагын бер тарих. Әлфия апа аны миңа үзе сөйләде. Инде олы яшькә җиткән балалары белән яшәгәндә танышулар сайтына кереп языша башлый ул. Ире белән яшьли аерылышкан. Казандагы фатир шактый кысан булганга, күңелгә ятышлы ир-ат белән танышып, моннан күчеп китәсе килә аның. Авылда үзенең йорт-җире белән яшәүче берәү белән шактый озак язышып аралаша. Яңа танышы очрашырга дип берничә тапкыр Казанга да килә. Озакламый Әлфия апаны үзенә яшәргә алып кайтып китә. Күптән хатын-кыз кулы тимәгән өйне тәртипкә китерергә тырыша Әлфия апа: юа, җыя, ашарга пешерә. Башта хатын янында гына йөргән ир бераздан ялкаулана башлый, кулланучыга гына әйләнә. Берни эшлисе килми, уртак тормышка әллә ни исе китми башлый. Балалар алдында зурдан кубып чыгып киттем бит дип, ярты ел түзеп яши әле Әлфия апа. Беркөнне ирнең яңадан танышулар сайтында утырганын күреп ала да, китә ул анардан. Бик күңеле төшә. Шулай да, Казанга кайткач, танышулар сайтында аралашуны дәвам итә. Тагын бер ир-ат җитди итеп яза башлый аңа. Ышанырга да, ышанмаска да белмәгән Әлфия апа аның белән дә очрашып карарга була. Казанның Урицкий паркына лалә чәчәкләре күтәреп килгән ир... аның элеккеге аерылышкан ире булып чыга. Башка исем белән язышкан ир үзенең кем янына килгәнен белеп килә. «Яңадан килештек бугай без, менә җайлап кына аның дача йортында яшәп ятабыз әле», – ди Әлфия апа бәхетле елмаеп. Шундый хәлләр дә булгалый!

Әз үземнең тәҗрибәмә таянып менә шуларны әйтә алам: танышу сайтларында хатын-кыз белән очрашуларга йөрергә вакытлары булмаган эшлекле кешеләр, чит илләрдә, чит төбәкләрдә яшәп, татар хатын-кызын очратырга теләүчеләр, эшсезләр, бер төнлек (гафу итегез!) мәхәббәт һәм кызык эзләүчеләр, тормыш итәргә яр табарга өмет итүчеләрне очратырга була. Монда һәркем идеаль. Язганнарына гына карагыз: бөтен кеше буш вакытында паркка йөри, документаль фильм карый, музыка тыңлый, китап укый һәм кадерлесен табып, бәхетле булырга хыяллана. Барлык сүзләргә дә ышанып бетмәгез, сак була белү дә кирәк!

Шулай да! Өметне беркайчан да өзәргә ярамый. Чүп ташларга чыкканда да иреңне буяп чык, язмышыңны очратуың бар, диләр бит. Әлеге язмага алыныр алдыннан да, әнә, икесе дә бик авыр язмыш сынаулары узган ир белән хатынның, ялгыз калгач, танышу сайтларында язышып, табышып, бәхетле тормыш корып җибәрүләре турында сөйләгән иде. Бар ул бер-берсен танышу сайтларында очраткан бәхетле кешеләр. Мәхәббәт сәгатенең кайда сугасын кем белсен?! Ихлас теләк белән парын эзләп танышу сайтларына керүчеләрнең дә үзләрен табучысы һәм үзеннән җибәрмәүчесе табылсын иде ул!

...Танышу сайтларында утырып, җәй җиткәч, кышкы бүреген дә алып куярга онытккан бер абзый турында көлеп сөйләгәннәр иде бервакыт. Виртуаль дөнья үзенә бик тиз тартып кертә шул ул. Әмма мин бер айдан анкетамны алдым, һәркем белән матурлап саубуллаштым. Минем белән аралашканда танышу сайтындагы бер генә ир заты да зыян күрмәде дип ышанам.

P. S. Ау-у! Китапханәдә яки театрда танышучылар бармы ул хәзер?!

ФИКЕР

Илсөяр (интернет аша танышып, 12 еллык гаилә тәҗрибәсе бар): «Интернет аша танышу 15 еллап элек башланды. Ул вакытта бик күп иптәш кызларым шунда танышып, кияүгә чыктылар. Ул вакытта танышу сайтларына начар уйлар белән керүчеләр юк иде әле. Эшкә килгәч, шунда кереп кем беләндер танышып-сөйләшә идек тә, кичен инде ул кеше белән очрашуга да барып кайткан чаклар бар иде. Ә хәзер кем белән танышканыңны белеп аралашырга кирәк дип әйтәләр. Без үзебез дә ирем белән интернет аша таныштык. Бер ел буе интернет аша гына аралаштык, фотолар алыштык. Күрешкәндә инде бер-беребезне әйбәт белә идек, чөнки аралашуыбыз җитди булды. Бүгенге заманда интернет аша танышуларга уңай карыйм. Ыгы-зыгылы тормышта яшибез, йөгерәбез, чабабыз, байлык артыннан куабыз. Шәхси тормышка вакыт та калмый торгандыр ул. Ялгызлар өчен әйбәт аралашу мәйданы дип саныйм мин аны».

Ирләр күзлегеннән

ТАНЫШУЛАР ...ШАЯРУДАН БАШЛАНА



Алып баручы, «BEZ» телеканалының продюсеры Фәнил ВАККАЗОВ

Шактый еллардан бирле туйлар алып баручы буларак, бер нәрсәгә игътибар итәм: никахланышучыларның күбесе интернет аша табыша икән. «Ә сез ничек таныштыгыз?» – бу сорауны бер генә туйда да бирми калганым юк. «Интернет аша» дигән җавап елдан-ел ешрак яңгырый. Беләсезме нәрсәсе кызык: алар инде тормышта бер-берсен күргән, белгән дә булырга мөмкиннәр. Ләкин ул чакта ничектер бер-берләренә игътибар итмәгәннәр, күңелләрендә мәхәббәт уянмаган. Ә менә шул ук кешене интернет киңлекләрдән эзләп табып, «Сәлам!» дип бер сүз язып җибәрү учакны кабызырдай очкын була алган.

Интернет аша танышуларны мин икегә бүлеп карар идем.

Беренчесе, мөгаен, җитди булмаганрак танышудыр. Интернет челтәрләрне караштырып утырасың, «хоп!» бер кеше ошады, алдын-артын уйлап тормыйча, тоттың да яздың. Әлеге язуга җавап булырмы, танышу барып чыгармы, элемтә барлыкка килерме? Ул турыда син артык уйлап тормыйсың, булса – әйбәт, булмаса – алга таба эзләүне дәвам итәсең. Бу танышу сине бернәрсәгә дә мәҗбүр итми, аның алдында яхшырак, матуррак күренү ихтыяҗы да юк – ул бит сине әлеге мизгелдә күрми, язуыңны гына укый.

Икенче төрле танышу, минемчә, җитдирәк ният белән була һәм аларның күбесе туй белән тәгәлләнә. Белмим, бәлки, кайберләренең җитди танышуы җитди булмаганрактан да башланып китәдер. Күп очракта барыбер ниндидер уртак танышлар барлыгы ачыклана, ике як тарафыннан да күпмедер «заочный» материал тупланган була.

Үзем мин «тере» танышу яклы. Миңа кешене үз күзләрем белән каршымда күрергә кирәк, аның энергиясен тоярга, тавышын ишетергә, елмаюын, күзендә кабынган очкынны, карашының яктылыгын күрергә... Ә аннары инде якынрак танышу өчен интернетны да рәхәтләнеп кулланырга була. Челтәрләрдә берәр кеше бик ошаса да, аңа нәрсәдер язганчы, сәхифәсенә кереп, еш була торган урыннарын, кайда эшләвен, нинди спорт төре белән мавыгуын, кайсы залга йөрүен караштырып, аның белән очрашу эзләр идем. Челтәрләрдәге фотолар һәм тормыш рәвеше еш кына чынбарлыктан шактый аерыла. Күп тапкырлар моның шаһиты булганым бар. Кешегә үзен тормышындагыдан матуррак, уңышлырак, баерак, акыллырак итеп күрсәтү теләге хас. Бигрәк тә яшьләр мавыгучан моның белән. Шуңа да интернеттан елмаеп карап торган фотога гына ышану ярап та бетми.

Икенче яктан карасаң, интернет аша танышуның бөтенесе дә күрешеп танышуга алып барып җиткермәскә дә мөмкин. Ә кемгәдер, бәлки, ул кирәк тә түгелдер. Кайберәүләр бит интернетта виртуаль аралашу гына эзли, шуннан рәхәтлек, кәеф таба. Интернет аша башка ил кешеләре белән танышучы, аралашучылар барлыгын да беләм. Алар бит гомерләрендә бер тапкыр да күрешә алмаска мөмкин. Хәер... Бер туйны алып барырга чакырдылар. Кияү – Америкадан. Бәлки, арагызда аларны белүчеләр дә бардыр. Балтач егете Ленар җиде еллап Америкада яши. Һәм көннәрдән бер көнне ул интернеттан Айгөлне эзләп таба. Бәлки, моңарчы да күргәне, ишеткәне булгандыр, читтән торып кына булса да, аны белгәндер... Алар виртуаль аралашалар, дуслашалар. Ленар бер-ике тапкыр Америкадан үзе дә кайтып килә. Бу аралашу мәхәббәткә әверелеп, без гөрләтеп аларның туйларын уздырдык. Хәзер алар Америкада яши.

Беләсезме, иң мөһиме бит ничек танышу түгел. Иң мөһиме: миллионнар арасыннан үз тиңеңне табу. Тапкач, аны югалтмау. Әкиятләр генә туй белән тәгәлләнә, ә чын тормыш, киресенчә, туй белән башлана гына әле.


Фотолар: гаилә архивыннан



Раилә ХӘЯЛИЕВА

СИН ЯНЫМДА БУЛГАН ЧАКТА ГЫНА...

Чәчкәләрнең нигә кирәге бар,
Өзеп бирер кешең булмаса?!
Нәрсә соң ул күктә янган кояш,
Үз кояшың балкып тормаса...

...Нәсимә ханым өй каршысын тутырып үскән чәчкәләргә су сибеп йөри. Үзе ничектер моңсу, хәтта аз гына ямансу да булып күренә. Назлы таҗларга су тамчылары эленеп кала, ә күңелдәге олы мәхәббәт күршесенә әче бер сагыну хисе кереп оялаган. Күрше авылга йөреп балалар укыткан, төрле тормыш мәшәкатьләре белән елларда гына иркенләп күрешү насыйп булган ире Фәритен сагынуы ла ул! Чәчкәләр – сердәшләр, алар янында онытылып торырга да була. Халык теленнән төшми җырланган «Чәчкәләрнең нигә кирәге бар?» җырының тексты буласы ихлас шигырь юллары менә шулай 1961 елның матур бер җәендә гади авыл хатыны күңелендә өй каршындагы чәчәкләргә су сипкәндә бөреленә. Мәхәббәт тулы яшь йөрәк аша саркып чыга ул, сөйгән ярының кадере арткан мизгелдә туа. Киләчәктә, инде популяр җыр булып ирешкәч, Нәсимә апа үзе дә: «Иремне бик сагынган

Чәчкәләрнең нигә кирәге бар?

Чәчкәләрнең нигә кирәге бар,
Өзеп бирер кешең булмаса?!
Нәрсә соң ул күктә янган кояш,
Үз кояшың балкып тормаса.

Син янымда булган чакта гына
Матур җырлар туа күңелемдә.
Эчкерсез саф мәхәббәтем минем
Юлдаш булсаң иде гомергә.

Тормыш юлын бергә
башлаганбыз,
Ахыргача бергә булыйк без.
Авырлыклар килсә,
бергә уртаклашыйк,
Шатлыкларны бергә бүлик без.
Бик бәхетле, иркәм, булыйк без,
Тормыш юлын бергә үтик без.

булганмын, күрәсең. Ярату хисләре белән әйткән сүзләрем үзеннән-үзе шигырь булып чыкты», – дип искә алып сөйлиячәк әле.

Нәсимә апа үзе – Сарман кызы. КДУның татар филологиясе факультетын тәмамлап, КПССның Татарстан өлкә комитеты юлламасы белән Кайбыч районы редакциясенә эшкә җибәрелә. Тырыш кыз авылдан авылга йөреп хәбәр җыя, редакциянең җаваплы хезмәткәренә әйләнә. Монда булачак тормыш иптәше, гомерлек яры Фәрит абый Абзалов белән таныша. Сарман якларында туып-үскән кыз Кайбыч районы Кошман авылы килене булып куя. Соңрак Нәсимә апа да мәктәпкә эшкә күчә, татар теле һәм әдәбияты укыта башлый, иҗат итүдән дә туктамый.

«Чәчкәләрнең нигә кирәге бар?» җырына көй язган композитор Илһам абый Хисмәтуллин белән сөйләшәбез:

– Бу шигырь минем кулыма 1985 елда килеп керде. Кошман авылыннан Әкрам Борһанов исемле кеше минем яныма кереп, үзенең шигырьләрен күрсәтте. Алар арасында «Н. Абзалова. Кайбыч районы газетасында 1961 елда басылып чыккан шигырь» дип язылган кәгазь дә бар иде. Миңа ул шигырь бик ошады. Ул көнне минем ике җырым туды. Берсе – «Чәчкәләрнең нигә кирәге бар?» дигән җыр. Ул вакытта Түбән Кама шәһәрендә кичке уеннар гөрләп бара иде. Мин ул җырны беренче тапкыр кичке уенда җырладым. Шуннан соң бер атна эчендә бу җыр бөтен республикага һәм Башкортстанга таралды. Бәйрәмнәрдә, мәҗлесләрдә җырлана башлады. Җырның төпле фикере бар икән, аны халык яратып кабул итә. Ә бу җырда бербенсен яраткан кешеләрнең, табышып, бәхетле булуына гимн җырлана. Шуңа күрә бүген дә яратып җырлыйлар аны.

Язылу тарихы бик матур булса да, җырның язмышы шактый бормалы булып чыга. Газета битләрендә ят авторлар исеме белән басыла ул, җыр китапларында Нурия Измайлова сүзләре дип тә күрсәтелә. Күпмедер вакыттан соң, шагыйрә Нурия Измайлова әлеге шигырь хакында: «Минем каләмем түгел ул», – дип төзәтмә кертә. Әмма Нәсимә апаның мондый гаделсезлеккә шактый күңеле рәнҗегән, яраланган була инде. «Шигырьне генә түгел, йөрәк түреннән чыккан кадерле сүзләрне, хисләремне урлаганнар кебек хис иттем. Хәзер алай исем китми инде», – дип истәлекләр белән уртаклаша ул бер сөйләшүдә.

Гаделлек урнашу тарихы да кызыклы. Бу турыда безгә шагыйрә Шәмсия Җиһангирова сөйләде:

– Бер елны без, бер төркем язучылар, Кайбыч районы Кошман авылына язучы һәм публицист Зариф Бәширинең каберенә кайткан идек. Шунда мин Нәсимә һәм Фәрит Абзаловлар белән очраштым. Минем радиода эшләгәнемне белеп килгән булганнардыр инде. Фәрит абый, радиодан яңгырый торган «Чәчкәләрнең нигә кирәге бар?» җырының сүзләрен үзенең хатыны Нәсимә апа язганын аңлатты. Фәрит абый ул җырны гармунда уйнап күрсәтте, без кушылып җырладык. Башка кешене җыр текстының авторы дип йөртүләре бик борчыган иде аларны. Казанга кайткач, мин булдыра алганча бу ялгышны төзәтергә тырыштым. Нәсимә апа Абзалова исемен автор буларак җыр китапларына керттем, картотекаларда, протоколларда төзәттем, кайбер җырчыларга шалтыраттым, Язучылар берлегенең авторлар белән эшләүче бүлегенә хәбәр иттем. Шулай итеп, бу җыр яңадан үзенең авторлары исеме белән аталып йөртелә башлады. Җырларның авторларын бутау күренеше әле һаман да дәвам итә. Бик кызганыч күренеш бу. Башкаручыларның игътибарлырак булуы кирәк.

«Тормыш юлын
бергә башлаганбыз,
Ахыргача бергә булыйк без...»

Бу шигырь юллары гади генә текст түгел, аның белән Нәсимә апа киләчәк тормышын күзаллап куя сыман. Аллага шөкер, бар да җырдагыча килеп чыга аларның. Фәрит абый күп еллар мәктәптә математика укыта. Нәсимә апа гомер буе бакча тутырып хуш исле чәчәкләр үстерә, алар белән аралашудан ямь таба. Иҗат белән шөгыльләнә, шигырьләр яза. Бүгенге көндә дә бергәләп балалары тәрбиясендә яшиләр, оныклар үстерәләр. Әле күптән түгел генә балалары, аның барлык шигырьләрен җыеп, китап итеп бастырып чыгарган – әниләренә зур бүләк ясаган.

Нәсимә апага һәр бәйрәм саен оныклары, балалары чәчәкләр бүләк итәләр. Гомер буе чәчкәләргә гашыйк җан шул ул...

Фото: Фәрит абый белән Нәсимә апаның яшь вакыты. Сабантуйда.

PRESSA



ИСПАНИЯГӘ... ҖӘЯҮ



Полина
ТРОЯНОВСКАЯ

Португалиядән Испаниягә җәяүле сәяхәтем – тормышымдагы иң гаҗәеп һәм онытылмас вакыйгаларның берсе. Әлеге маршрутның тарихи ягы бар: ул католикларның хаҗ сәфәре. Юлны Европаның теләсе кайсы почмагыннан башларга була, ләкин ул Испаниянең Сантьяго-де-Компостела шәһәрендә тәмамланырга тиеш. Тик бүгенге көндә әлеге маршрут спорт сөючеләр һәм минем кебек гадәти булмаган сәяхәтләр яратучылар өчен дә бик кызыклы.

Юлда танышкан кайбер пилигримнар белән һаман да аралашам.

Сәяхәтче дусларым күп минем. Шуларның берсе: «Әйдә, киләсе язга бергә Изге Иаков юлын узабыз», – дип язды. Ул чакта әле Изге Иаков–Камино-де-Сантьяго юлы турында берни дә белми идем. Кызыксынып, төрле чыганаклардан аның турында мәгълүмат эзләргә керештем. Эмилио Эстевесның «Путь» фильмын карадым (андый исемле фильмнар күп булганга төгәллек кертәм – «The Way» дип атала ул), Пауло Коэльоның «Дневник мага» китабын укып чыктым. Сүз уңаеннан, Камино-де-Сантьяго юлы нәкъ менә Пауло Коэльоның китабыннан соң шулай популярлаша да.

Киләсе язны көтеп җиткерә алмадым: җәен үк юлга җыена башладым. Камино-де-Сантьяго – бик атаклы юл, аның маршрутлары да шактый. Шуларның берсе һәм иң билгелесе – 800 чакрымга сузылган Француз юлы. Ул Сен-Жан-Пье-де-Пор дигән француз шәһәрчегендә башлана. 1896 елда Пауло Коэльоның нәкъ шушы юлны узганы билгеле. Француз юлыннан кала Португал юлы, Инглиз юлы, Төньяк юлы, Көмеш юл һәм тагын бик күптөрле маршрутлар бар. Иң мөһиме, әйткәнемчә, барлык юллар да Испаниянең Сантьяго-де-Компостела шәһәренә илтә. Нәкъ бу шәһәрдә 12 апостолның берсе – Изге Иаковның көчләре сакланган дип сөйлиләр кайбер чыганаклар.

Дус кызым белән зур Француз маршрутын бергә үтәргә сөйләштек, ә аңа кадәр бигүк озын булмаган Португал маршрутын үзем генә үтеп карарга булдым. Беренчедән, бу маршрут үзенең матурлыгы белән аерылып тора. Икенчедән, ике илдә – Португалия һәм Испаниядә булачакмын, ике милләтнең көнкүреше белән якыннан танышачакмын. Өченчедән, ялда кеше болай да диңгезгә ашыга, ә монда тагын да әйбәтрәк – океанны күрәчәкмен!

Яшермим, маршрутны планлаштырганда курку хисе дә булмады түгел. Берүзем чыгып китәм бит! Әлеге юл хакында бик күп укыдым, аны узучыларның блогларын карадым, кайбер нәрсәләрне яза бардым: кайда кунып калырга, туктап ял итәргә, тамак ялгарга... Берәр португал урманында адашып калмаммы икән дигән уйлар да килде башка. Чынлыкта, әлеге юлда бик тырышсаң да адашып калмыйсың. Нәкъ «Волшебник Изумрудного города» әкиятендәге шикелле – бөтен юл ачык сары төстәге тамгалар белән билгеләнгән. Әкияттә бу сары кирпеч булса, монда сары уклар ярдәмгә килде. Аларны бөтен җирдә күрергә була: аяк астындагы асфальтта, баганаларда, коймаларда...

Әлеге юлны үтүчеләр хаҗилар булып санала һәм пилигримнар, ягъни илгизәр-юлчылар дип атала. Юлга чыкканчы, хаҗи паспортын булдырырга кирәк. Мин аны католиклар гыйбадәтханәсендә алдым. Кунарга яисә ял итәргә тукталган урыннарда паспортка махсус штамп бастырасың. Моннан тыш, пилигрим үзенең рюкзагына диңгез кабырчыгы элеп куя – анысы юл символы. Бу билге буенча синең хаҗи икәнеңне танып алалар һәм төрлечә ярдәм итәргә тырышалар.

Бөтен маршрут буенча альберге – махсус пилигрим кунакханәләре урнашкан. Алар кыйммәт түгел – 5–7 евро тирәсе, ә кайбер кунакханәләрдә исә, гомумән, түләү ирекле: мөмкинлегең булса, акча калдырасың, юк икән, рәхмәт әйтеп кенә чыгып китәсең. Әлбәттә, мондый кунакханәләрдә халык бик күп туктала. Бер бүлмәдә егермеләп кеше кунарга мөмкин. Караватларда урын кирәк-ярагы юк, үзеңнең йокы капчыгында гына йоклыйсың. Дөресен генә әйткәндә, тулай торакка охшаган бу кунакханәләрдә шулкадәр халык белән бер бүлмәдә ничек кунармын икән дип бик борчылган идем. Моңарчы андый җирдә түгел, хәтта хостелда да кунганым булмады. Әйе, шәхси альбергеларда да тукталырга мөмкин анысы – юл буенда андыйлар да очрый. Тик, беренчедән, алар шактый кыйммәт, икенчедән, зур альбергелар барыбер кызыграк – аларда үзенә бертөрле Камино-де-Сантьяго рухы. Юкка борчылганмын! Көненә 20–30 чакрым юл узгач, күп әйбергә игътибар да итми башлыйсың икән – тизрәк урынга авасы, ял итәсе генә килә.

Башта шактый тиз бардым: беренче көнне – 30, икенче көнне 25 чакрым тирәсе юл уздым. Тик юлда танышкан испаннар ашыкмаска, юлдан, сәяхәттән ләззәт алырга, ял итә-итә барырга киңәш иттеләр. Аннан соңгы көннәрне, дөрестән дә, әкренрәк барырга, табигатькә сокланырга, кешеләр белән аралашырга тырыштым. Көненә якынча 20–22 чакрым юл үтә идем.

Европада бу вакытта бик эссе булганлыктан, пилигримнар, гадәттә, юлга иртә таңнан кузгала. Альбергеда кунучылар таң белән уяналар һәм иртәнге бишләр тирәсендә инде чыгып та китәләр. Көндезге икеләр тирәсендә күршедәге берәр авыл яки шәһәргә барып җитеп, икенче көнгә кадәр шунда калабыз.

Альбергега урнашканчы ук, башка пилигримнар белән таныша башлыйсың: кем кайдан килгән, никадәр

■ Юлның иң кыйммәтле һәм иң мөһим өлеше – экипировка! Әгәр дә җәяүле туризм белән моңарчы мавыкмаган булсагыз, шактый күп кыйммәтле яңа әйберләр алырга туры киләчәк: йокы капчыгы, махсус треккинг өчен сандалилар, рюкзак.



Фото: www.pixabay.com

Юлда бернинди дә куркыныч янамый: хаҗиларны анда яраталар.





юл узган, нинди тәэсирләр алган... Кайбер альбергеларда теннис корты, хәтта бассейн да бар – бергәләп уйныйбыз, йөзәбез. Кич белән кайберәүләр ашарга пешерә, ризыгы күбрәк килеп чыкса, башка пилигримнарны да чакыра. Күңелле!

Бер вакыйганы искә төшереп үтәсем килә. Шулай беркөнне арыпталып альбергега килеп җиттек, ә анда урын юк! Бу көннәрдә әлеге кечкенә шәһәрчектә ниндидер музыкаль фестиваль уза икән. Без бу турыда, әлбәттә, алдан белмәдек. Альбергеда безгә башка отель эзләп карарга тәкъдим иттеләр. Тик бу кечкенә шәһәрдә отельләр бик аз, булганнары да шыгрым тулы булып чыкты. Аптырап, кире шул ук альбергега кайттык: «Урын юк, нишлик?» – дибез. Чиркәүгә яки... янгын сүндерүчеләргә мөрәҗәгать итеп карарга куштылар. Нишләптер, янгын сүндерүчеләр хаҗиларның дуслары булып санала икән. Алар да кире борды... Аптырагач, чиркәүгә киттем. Анда исә миңа кунарга башка шәһәргә барырга киңәш иттеләр. Юл өстендә калган шәһәргә! Ә аңа кадәр кире 7 чакрым тәпилисе... Авыр рюкзак күтәреп, көне буена инде 20 чакрымнан артык юл үткән кеше бит мин! Бөтен сәяхәтем буена: «Мин монда нишләп йөрим, нәрсәгә дип интегәм?!» – дип уйлаган бердәнбер мизгел шушы булгандыр, мөгаен. Тик нишлисең, урамда кунып булмый – кире киттем. Ни булса да, яхшыга юра, диләр бит әле. Беренче очраган отельдә туктадым. Өр-яңа отель булып чыкты ул. Пилигрим икәнемне күреп, бер үземне аерым бүлмәгә урнаштырдылар: рәхәтләнеп ял иттем. Иртән бушка иртәнге аш белән сыйлап озатып та калдылар әле.

Юлда хаҗилар бик күп. Берәмберәм генә баручылар да, парлап йөрүчеләр дә бар. Бер гаилә бу юлны, гомумән, кечкенә бала белән велосипедта узды! Юлга минем кебек берүзең чыксаң да, үзең генә калмыйсың. Кемдер сине куып тота, кемнедер син куып тотасың... Барысы да: «Buen Camino!» – дип уза. Бу исәнләшү һәм хәерле юл теләүне аңлата. Юлда очраган башка пилигримнар белән күпмедер вакыт бергә барасың, аралашасың, аннары һәркем юлын үз темпы белән дәвам итә. Ә кич кунарга туктаган урында алар белән яңадан очраклы рәвештә күрешергә мөмкинсең. Мин күбрәк европалыларны очраттым, чөнки алар җәяү йөрергә ярата, шуңа күрә еш кына үзләре өчен шул рәвешле ял итү мөмкинлеген сайлый. Озын Француз юлында исә америкалылар күбрәк очрый, диләр.

Күпләр бу юлга кабат-кабат әйләнеп кайта икән. Юл – үзеңнең тормышыңа анализ ясау, уйлану өчен менә дигән урын бит. Вакыт иркен, сез бары икәү: син һәм юл. Күп әйбердән яңа мәгънә таба башлыйсың, ниндидер проблемалар эреп юкка чыккандай була. Бу халәтемдә үземне шулкадәр бәхетле тойдым! Кешеләр шул халәтне эзләп бу юлга кире кайтадыр дип уйлыйм. Мин дә аны кабат узар идем...

Физик яктан күпләр юлны авыр кичерә. Кайберәүләрнең аркалары, аяклары авырта, сөялләр чыгып җәфалый. Аяклары канап беткән кешеләрне күп күрдем. Бу яктан үзем зарлана алмыйм: әллә моңарчы йөгерү белән шөгыльләнүем, әллә махсус йөгерү кроссовкалары киюем ярдәм итте – миндә андый хәлләр булмады, юлны сөялсез уздым.

Хаҗилар ни өчен бу юлны сайлый, аның нинди мәгънәсе бар? Элек бу юл, чыннан да, дин белән бәйле булган. Соңрак исә уйланыр, үз-үзләрен «тыңлар» өчен бу юлга чыгып киткәннәр. Әйтик, мин бер хаҗины очраттым. Аның гаилә тормышында шактый катлаулы чор икән: хатыны белән аерылышыр дәрәҗәгә җиткәннәр. Ул үз-үзен аңлар, ялгызы гына калып уйланыр өчен шушы юлга кузгалган... Бу юлда нинди генә милләт вәкилләрен, кайсы гына диндәге кешеләрне очратмыйсың?! Күпчелек пилигримнар өчен бу сәяхәт, әйткәнемчә, спорт, үз-үзеңне сынау, яңа җирләр күрү. Ул борынгы испан һәм португал шәһәр-авыллары аша уза. Испаниянең кайбер авылларында испан теленнән башка телне, гомумән, аңламыйлар. Менә кайда чын тормыш: ничек бар – шулай! Португалиядә, мәсәлән, бер күренешкә игътибар иттем: кайбер авылларда йорт ишекләрендә пакет белән ипи эленеп тора. Бу авылларда ипи сатучыга алдан ук акча түләп куялар да, ул үз чиратында ипине ишегеңә үк элеп китә икән. Бездә почтальон газета тараткан шикелле. Кызык!



Камино-де-Сантьягода төрле милләт вәкилләре күп булса да, россиялеләрне юлда бары тик ике генә тапкыр күрдем: беренчеләрен – юл башында, Порту шәһәрендә үк, икенчеләрен – юлда барганда. Алары Санкт-Петербург шәһәреннән килгән бер пар иде. Очраткач, ничек шатланганымны белсәгез! Ул көнне юлда бергә бардык, алар мине кичке ашка чакырдылар.

Юлда гомер кирәк булмаган әйберләр кирәк булуы да ихтимал. Әйтик, маңгай фонаре. Юлда ул бик әһәмиятле атрибут булып чыкты. Юлга җыена башлаганда махсус аяк киемем дә, йокы капчыгым да юк иде. Җәй икәнен исәпкә алып, йокы капчыгының бик җиңелен генә сайладым. Шулай ук бераз кием-салым, яңгырдан саклану киеме (дождевик), баш киеме, күзлек, лейкопластырь алдым. Иң кирәгенә генә тукталырга туры килә: һәммәсе бер рюкзакка сыярлык кына булсын.

Рюкзак – шулай ук юл символы. Аны монда тормыш белән чагыштыралар. Без бит еш кына тормышыбызны кирәкмәс нәрсәләр белән тутырабыз: артык кием-салым, вак-төяк, җанга рәхәт бирми торган мөнәсәбәтләр, кирәкмәс үпкәләр... Алар тормышны авырайта, алга атларга комачаулый. Монда исә – бер рюкзак. Иң мөһим әйберләр шунда сыеп бетәргә тиеш. Җәяүлегә янчык та авыр диләрме? Атлый торгач, йөгең җиңелрәк булсын дип, тагын кайбер кирәкмәс әйберләрне ташларга туры килә. Тормышта да шулай бит... Кирәкмәс нәрсәләрдән вакытында арына да белергә кирәк! Юл уңаенда кунакханәләрдә кешеләр рюкзакларын кабат барлап, кайбер киемнәрен, китапларын һәм башка вак-төякне калдырып китәләр. Галиҗәнап Юл, кирәкмәс әйберләрне рюкзактан алып аткан шикелле, аларны баштан да ташлый барырга өйрәтә сыман...

Әйткәнемчә, барлык маршрутлар да Испаниянең Сантьяго-де-Компостела шәһәрендә тәмамлана. Пилигримнар анда адым саен. Шундый күп! Махсус агентлыкта пилигрим сертификаты бирелә. Анда кем, кайда, нинди юл үткәне күрсәтелә. Әлеге сертификатны алу өчен зур чират җыела. Шул чиратта урын алу өчен соңгы көнне иртәнге өчтә үк юлга кузгалдык. Урамда әле караңгы иде. Маңгай фонарьларын киеп, урман аша бардык. Бу шәһәрдә бөтен җирдә татлы миндаль пирогы сатыла, ул Сантьяго пирогы дип атала. Пилигримнарның барысы да бу пирог белән сыйлана, шул рәвешле авыр һәм озын юлның ахырына җитүләрен билгеләп үтәләр.

Камино-де-Сантьяго юлының Португал маршруты – 270 чакрым, мин аны ун көндә уздым. Әлеге сәяхәт минем өчен гаҗәеп бер тормыш мәктәбе дә булды. Юлда синең кем булуың, кайда эшләвең, кесәңдә никадәр акчаң булуы мөһим түгел. Барлык пилигримнар да бертөрле диярлек киенгән, бертөрле ризык ашыйлар, 20 шәр кешелек бүлмәләрдә куналар. Юлда ничек җиңел танышсалар, шулай ук җиңел саубуллашалар да – берәү дә синең шәхси чикләреңә керергә җыенмый. Әмма шул ук вакытта һәркем сиңа булышырга, ярдәм итәргә әзер.

Бу юлда үземне яңа яктан ачтым, үземә ышанычым артты, булган мөмкинлекләремә башкача карый башладым.

Хәзер исә озын Француз юлын үтәргә хыялланам. Пауло Коэльо китабында язылганын! Ул Франция Пиренеиларыннан башланып, Испаниянең Наварра өлкәсендәге таулар һәм ярлар, йөзем бакчалары, матур авыллар аша уза. Моның өчен бер ай чамасы вакыт кирәк. Бу мине куркытмый, чөнки беләм: һәр юлның башы булган кебек, ахыры да бар.

Альбина ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА
әзерләде.



■ Кафеларда исә пилигримнар өчен махсус меню булдырылган – тамакны шунда ялгый идем. Гадәттә, пилигрим менюсы шактый туклыклы, чөнки хаҗига күп энергия кирәк. Мәсәлән, дөгеле яисә бәрәңгеле итле ризык. Әлеге менюда һәрвакыт шәраб булуына да игътибар иттем.

ХАТЫН-КЫЗНЫҢ КӨЧЕ – КҮЗ ЯШЕНДӘ



Фотолар: гаилә архивыннан

Хәлим ҖӘЛӘЛОВ,
Татарстанның халык артисты;
А. Алиш исемендәге премия лауреаты;
Гаилә стажы – 51 ел;
Кызлары: Дилбәр, Миләүшә.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Гади генә сорау, әйеме, ләкин бик четерекле. Иң элек тыйнаклыгына. Ну чибәрлегенә күз төшә инде. Флүрә апагыз яшь чагында бик чибәр иде. Бик! Әгәр җитди итеп әйтсәк, намуслы булсын. Хәйләне сизәм икән, ул кеше миңа якын килмәсен инде. Хатын-кыз, чәчрәп, күзгә кереп тордымы – «хуш, авылым, сау бул». Минем приём бар: шаярып сөйләшергә яратам бит инде. Шаяруга ияреп, кайбер хатын-кызлар әрсезләнә башлый. Иярергә кирәкми. Тыныч кына елмаеп тор син.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Әгәр хатын-кызның күзендә яшь күрсәм, бөтен кылган гөнаһын кичерәм. Мин түзә алмыйм аңа. Яшь чакта хатынга да: «Минем белән әрләшсәң яхшырак булыр иде», – дия идем. Яшь күрсәм, күңелем йомшара минем. Рәнҗеттем бит дип уйлый башлыйм.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Хыянәтне! Кеше бер хыянәт иттеме, ул гел хыянәт итәчәк. Аны кайберәүләр «ялгышлык», диләр. Кешенең аягына ялгыш басарга мөмкин. Ә күрә торып уҗымга чыгу – ялгышлык түгел, хыянәт ул. Безнең гаиләдә андый очрак булган булса, нишләткән булыр идем икән? Әйтергә дә куркам... «Все, гатауллин!» булган булыр иде.

Әнигә сүз әйткән кешене кичерә алмаган булыр идем. Әни минем өчен иң изге кеше булды. Аңа кем сүз әйтүенә карамастан, бугазыннан алган булыр идем. Әни сугыш чорында ялгызы җиде бала үстергән. Җиде малай! Ул – тиңдәшсез хатын. Чибәр, бик үткер иде. Бер очракны хәзер дә көлеп искә алам. Абый Сабантуйда батыр калган иде. Шул бәйрәмдә марҗа кызын озаткан бит. Әни моны белгәч, мич башында яткан итекне алып абыйны кыйнады. Әни – кечкенә генә, абый – ат хәтле. «Әни, мин батыр бит», – ди абый. Әни: «Минем өчен батыр юк», – дип һаман кыйный тегене. Менә шундый иде ул безнең әни. Илаһи хатын!

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Икесе дә. Хатын-кызда бу ике сыйфат та булырга тиеш. Флүрә апагызда икесе дә тупланган. Мин репетиция ясый башлыйм икән, ул әкрен генә башка бүлмәгә чыгып китә. Хатынын мактап утырган кеше бик нормаль кеше түгел инде ул, ләкин мин мактыйм. Мактарлыгы бар! Үзе дә сәнгатьне бик ярата. Университетта укыганда үзешчәннәр ансамблендә биеп йөргән. Оста биюче! Минем белән кавышканнан соң аңа нокта куйды. «Өйдә бер тиле җитә», – дидем мин. Әгәр дә берәрсе сезгә: «Гомерем буе хатынымнан гына илһам алып яшәдем, бүтән кешегә күзем дә, күңелем дә төшмәде», – дисә, ышанмагыз да, язмагыз да *(хәйләкәр елмаеп)*. Мин сезгә дөресен сөйләр идем, хатыным да укыячак бит бу журналны. Сез мине хатын-кызлар буенча шәп белгеч дип уйлыйсыз, ахры. Яшь чакта минем базарым югары түгел иде *(җитди тонга күчеп)*. Шулай да шаярып сөйләшкәннәр күп инде ул. Ләкин өйдә көткәне – бердәнбер *(уйланып)*. Акыллы ир әнә шуны аңлап яшәргә тиеш. Һәм без, ир кешеләр, әнә шул бердәнбердән илһам алып яшибез дә бугай инде.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әлбәттә. Ничек булмасын инде? Хатын дус та, таяныч та. Өйгә борчылып кайтып керәсәң дә, аның белән күзгә-күз очрашасың бит. Хатынга сөйләми, кемгә сөйлисең тагын? Мин сер яшермәдем. Ул да яшермәде. Шулай да артык чәчелергә дә ярамыйдыр инде ул. Кирәген болай да ишеттерәләр аның *(хәйләкәр елмаеп)*.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Без аның белән театрда очраштык. Мин яңа гына гастрольләрдән кайткан, кояшта янган, матур кулмәктән... Ул вакытта инде танылган актер идем. Шамил Зиннурович театр директоры түгел иде әле, студент кына, сәхнә эшчесе булып эшләп йөри иде. Аның белән сөйләшеп торганда Ул килеп басты. Элек алар бергә үзешчәннәр коллективына

йөргәннәр икән. Хәзер уйлыйм: мине танып, мөгаен, бер сәбәп табып кына килгәндер ул безнең янга. «Бу нинди кыз икән?» – дип аңа карап куйганым исемдә. Бик чибәр иде бит! Ходайның рәхмәте, кайтырга дип трамвай тукталышына килгән идем – Ул басып тора! Бер якка кайттык та, озатып куйдым инде. Яңа гына университет тәмамлаган кыз икән. Әлмәт ягына, Колшәрип дигән авылга укытучы булып эшләргә китте. Ел буе хатлар алыштык. Аның хатлары әле дә миндә, минекеләр анда саклана. Бер ел эшләде дә ыжгырып кайтып җитте *(рәхәтләнеп көлә)*. Бүтән кешегә өйләнмәгәе бу дип ашыкты бугай. Юк, үзем дә берәр авыл егете эләктермәсен, дип курыкканмындыр. Бик чибәр иде бит. Инде еллар үткәч: «Сине күргәч, башка кешегә күземне дә күтәреп карамадым», – дигәне булды *(канәгать елмаеп)*. Казанга кайтып эшкә урнашкач: «Бир паспортыңны, илтеп бирәм», – дидем. Ул алды да бирде. «Чыкмыйм», – дип карышып торсынмыни *(шаяртып)*?! «Ә, шулаймыни? Ярар, алайса, хуш, авылым, сау бул», – диячәк идем бит. Аннары гөрләтеп туй ясадык.

7 **Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?**

– Бу гыйбарә хак бит! Әни дә бик тырыш, бик чиста хатын иде. Яратып кабул итте киленен. Флүрәне күргәч: «Менә монысына өйләнәсең инде», – диде. 24 ел бергә яшәдек. Кадер-хөрмәттә яшәп, бакыйлыкка күчте әни.

8 **Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?**

– Миңа калса, бу очракта хатын үзен дөрес тотарга тиештер. Акчаны шәп эшли икән, ирен кимсетмәсен. Мин-минлек дигән нәрсә бар бит ул. Ире: «Ярый алайса, акчаң белән яшә», – дияр дә китәр. Китмәсә дә, читкә йөри башлар. Безнең гаилә өчен ят хәл бу. Мин бит эшләргә яраттым. Көне-төне эшли идем. Сукырлар җәмгыятенә барып китап укуның сәгате – 3 сум. Алтышар-җидешәр сәгать укып кайтам. Ул вакытта 18 тәңкә акча иде. Университетта да эшләп алдым. Гаиләне тәэмин итү – ир кешенең бурычы. Мин студент вакыттан ук ач булмадым. Һәрвакыт кесәмдә чәйлек-шикәрлек бар иде. Флүрә финанс-икътисад институты китапханәсендә эшләде, аннан соң сукырлар китапханәсендә редактор булды. Минем аннан беркайчан да акча сораганым булмады. Ул да: «Кайда акчаң?» – дип төпченмәде. Яшь чакта күңел ачкалап та йөрдек... «Ник болай йөрисең?» – дигәне булмады. Хезмәт хакын тулысы белән өйгә алып кайта идем. Анысы – гаилә хакы. Халтурада эшләнгән, ягъни «пистон кесәсе»ндәге акчага бәйрәм ителде. Рәхмәт Флүрәгә, сабыр итә белде күңел ачуларыма.

9 **Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтә идегез?**

– Беренче класстан ук әйбәт укыдым. Бик шук идем. Кызларның сызым да сызасы, рәсем дә ясыйсылары бар. Ә мин бик оста ясый идем. Художник булыр дип көттеләр мине. Ә классташ кызлар мине егеткә дә санамады бугай. Кечкенә генә малай идем. Ә алар – җиткән кызлар. Ну яраталар иде үземне. «Татваленка»да эшләгәндә үзешчән ансамбльгә йөрдем. Анда нинди генә кызлар юк иде! Алар янында мин хөрмә төше кебек булдым.

10 **Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?**

– Килешәм. Флүрә апагыздан кала, артык чибәрләр туры килмәде. Әйе, яратам чибәр хатын-кызларны. Тик минем күз төшү белән генәмени?! Тәкәббер чибәр булса, куркырлар да шул. Акыллы хатын-кыз матурлыгы белән масаюын беркайчан да сиздермәсен инде ул. Андыйларга яратып әйтә торган сүзем бар: «Хуш, авылым, сау бул!» Көчле гүзәл затлар кемнәргәдер ошыйдыр, әлбәттә. Үземә, мәсәлән, минемчә яши торган кеше кирәк. Юлбарыс белән арыслан булып яшәп булмый ул гаиләдә. Әгәр ир-атның зур эшләр башкарырга көче җитми икән, хатын йогынтысына керми, кая китсен... Хатын дилбегәне үз кулына ала инде. Шулай да хатын-кыз ирдәүкәләнеп йөрмәсен иде, табигате белән үк нәфис, йомшак булырга тиеш бит ул. Аның бөтен көче дә хатын-кыз булуында.

11 **Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез?**

– Бераз сабыр итәргә кирәк. Башында булса, аңлый ул. Хәдистә әйтелгәнчә, хатын-кыз кәкре кабыргадан яратылган, турайтмакчы булсаң, сындырырсың. Бу хатын-кызның кирелегенә ишарә инде *(хәйләкәр елмаеп)*. Шуны гына әйтәм: мин үз дигәнемне эшләми калмыйм. Хатын-кыз киреләнәме-юкмы, анысы – аның эше.

12 **Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым дип, диванда кырын ятып тора. Сез нишлисез инде? Кафега чыгып китәсез яки пиццага заказ бирәсез? Тиз генә үзегез берәр нәрсә пешерәсез?**

– Бер дә аптырамыйм. «Ял итәсеңме, хатын, ярар, ял ит», – дим дә, нәрсә бар, шуны җылытып ашыйм. Мин ул эшне генә эшләмәслекме әллә? Җылытып ашарга да булмасамы? Ничек өйдә ризык булмасын инде? Анысын күз алдыма да китерә алмыйм. Юк икән – печенье белән чәй. Аның өчен тавыш чыгарасы түгел инде. Үзем әзерли белмим. Кабыклы бәрәңге белән йомырка пешерүдән узмый минем аш пешерү осталыгым.

13 **Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан. Бу сезнең ачуны китерәме? Китерә икән, бу хәл белән ничек көрәшәсез?**

– Бусы да табигый инде. Ул бит хатын-кыз. «Ашыга төш», – дип әйтәсең инде. Флүрә апаң минем гадәтне белә ул, шуңа да алданрак киенеп куя.

14 **Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?**

– Мин бу мәсьәләдә идеаль ирдер, мөгаен. Бер конфет бирсә дә күңелем була. Бүләкне дөрес бирмәдең, пешергән ашың ошамады дип хатынны рәнҗетергә кем дип белдегез мине? Бар ул хатын-кызның җанын ашый торган ирләр. Аннан да зур хурлык юк ул хатын-кызга. Алай зур бүләкләр бирешмәдек бугай без. Ул бик зәвыклы, әйбер сайлый белә. Флүрә алып биргән киемне тузганчы киям. Үзем дә бүләк бирергә яратам. Чәчәкләр ярата ул. Үзе дә чәчәк кебек минем хатын.



Замана чире

Артык авырлык, тазару кайчак өлкәннәрне генә түгел, балаларны да сагалый. Сабый чакта үзләрен кабартма дип сөйсәк тә, гәүдә калынаю беркемгә дә сәламәтлек өстәми шул инде. Бүгенге туклану культурасы, хәрәкәтнең азлыгы яңа төр чиргә – артык авырлык җыюга китерә. Хәер, аның сәбәпләре болар гына да булмаска мөмкин. Югары категорияле балалар табибы, эндокринолог, медицина фәннәре кандидаты Мария ШӘЙДУЛЛИНА шул хакта сөйли.

Симерү – организмда май тукымасының артык күп тупланууы ул. Өлкәннәргә генә түгел, хәзер хәтта балаларга да хас бу. Артык авырлык пациентның һәм физик, һәм психосоциаль сәламәтлегенә тискәре тәэсир итә. Икенче яктан, симерү үзе дә эндокрин системадагы чатаклыкны күрсәтергә яки генетик синдром булырга мөмкин. Шуңа да әти-әниләр балаларының организмында артык май тукымасының булу-булмавын белеп торырга тиеш.

Кызганыч, симерү һәм гәүдәнең артык авырлыгы бүген күп илләрдә җитди мәсьәлә булып тора. Россиядә кызларның – 5, ир балаларның 7 процентында артык авырлык күзәтелә. 2019 елның 1 гыйнварына Татарстанда һәр өченче бала симерү диагнозы белән табиб күзәтүенә алынган.

Организмда май тукымасы микъдарын махсус аппаратсыз билгеләве кыен булганлыктан, артык авырлыкны ачыклау өчен гәүдә массасы индексы (ИМТ) кулланыла. ИМТ = авырлык (кг)/буй^{2}(м). Гәүдә массасы индексының организмдагы май тукымасы микъдары белән турыдан-туры бәйләнеше булуы инде расланган.

Артык авырлыкның сәбәпләре күп булырга мөмкин. Кергән энергия белән тотылган энергия арасында баланс булмаудан килеп чыга ул. Нәселдәнлек тә роль уйный. Артык авырлыгы булган һәр икенче баланың – әтисендә йә әнисендә, һәр өченче баланың әтисендә дә, әнисендә дә әлеге проблема күзәтелә. Әлбәттә, артык авырлык проблемасы нәселдән килгән очракта гәүдә авырлыгын нормада тоту күпкә авыррак. Ләкин әлеге генетик үзенчәлек даими рәвештә артык калорияләр кулланганда гына үзен сиздерә. Һәм моңа баш миебезгә кереп урнашкан принциплар да гаепле: имеш, сәламәт бала тулы тәнле, алсу йөзле булырга тиеш, тәлинкәдә ризык калдырырга ярамый. Кайчак әти-әниләр ризыкны баланы тынычландыру яки бүләкләү сыйфатында да куллана. Мондый очракта гәүдәнең артык авырлыгына генетика гаеплеме, әллә бу гаиләнең гадәтләренә бәйлеме икәнен ачыклау кыенрак. Шунысын истә тотыгыз: көн саен кирәгеннән тыш ашалган бер бутерброд ел буена 2-3 кг артык авырлык булып туплана.

Артык калорияләр кулланудан һәм нәселдәнлектән тыш, организмның энергияне аз сарыф итүе дә симерүгә китерүче сәбәпләрнең берсе. Балалар һәм яшүсмерләрнең физик активлыгы соңгы елларда коточкыч кимеде. Алар күп вакытларын виртуаль дөньяда уздыра, урамда туп типкән баланы сирәк очратасың.

Гәүдәнең артык авырлыгы, әйткәнебезчә, нәселләрендә организмның май әйләнеше бозылган туганнары булган балаларга һәм яшүсмерләргә күбрәк яный. Рационында югары калорияле ризыклар (майлар, рафинадланган углеводлар) өстенлек иткән, көн дәвамында сирәк, ләкин зур порцияләр белән тукланучы (аеруча кичке якта һәм төнгә каршы) балаларда да бу патология күзәтелергә мөмкин. Әлеге ихтималлык физик активлык киму белән тагын да арта.

Гәүдәнең авырлыгын нормада тоту өчен профилактика чаралары бик гади. Аның принциплары һәркем өчен дә бердәй. Бу – дөрес һәм балансҗлы туклану, югары калорияле ризыклар белән мавыкмау, актив хәрәкәтләнү. Баланың рационы мөмкин кадәр төрле булырга һәм аның энергетик кыйммәте тотылган энергиядән артмаска тиеш. Җиләк-җимеш, яшелчә, кузаклылар, чикләвек, балык һәм чистартылмаган бөртектән әзерләнгән ботка-икмәк ризыкларына өстенлек бирегез. Ә менә рафинадланган углеводлар (шикәр һәм ак бодай оны кушып әзерләнгән барлык ризыклар да шушы төркемгә керә), терлек майлары (казылык ише әзер ит ризыкларының составында андый майлар күп), баллы сулар һәм ясалма соклар мөмкин кадәр азрак булсын. Шулай ук тозны куллануны да чикләргә кирәк, ул тәүлегенә 5 мг артырга тиеш түгел. Ризыкны дөрес әзерләү дә бик мөһим.

Дәвалауга килсәк, ул табибка күренүдән башлана, чөнки әлеге халәт ниндидер бер чирнең башлануын да белдерергә мөмкин. Кирәк дип тапса, балалар табибы эндокринолог һәм генетикка юллама бирә.

Моны белү мөһим

- Бөтендөнья Сәламәтлек саклау оешмасы биргән тәкъдим буенча, балаларга көненә ким дигәндә 60 минут физик активлык кирәк;
- гәүдә авырлыгы арту белән бергә, баланың буйга үсеше әкренәю һәм акыл үсешенең тоткарлануы әти-әниләрне сагайтырга тиеш.



Диастаз

Идеаль фигуралы булырга күпләр хыяллана. Өстәвенә, мода индустриясе дә хатын-кызның сылулыгына югары таләпләр куя. Зифа буйсынлы булу һәр заманда хупланган анысы. Ә менә тырышып-тырышып та билең нечкәрмәсә, киресенчә, юанайса?! Бәлки, монда сәбәп бөтенләй дә артык май тукымасында түгел, ә мускуллардадыр? Республика клиник хастаханәсенең микрохирургия бүлеге мөдире, Казан дәүләт медицина академиясенең пластик хирургия курсы җитәкчесе, профессор Андрей БОГОВ белән күпләрнең колагына ят диагноз – корсакның туры мускуллары диастазы турында сөйләшәбез.

Корсакның туры мускуллары – кабырга дугасы белән аек сөяге (лонная кость) арасында урнашкан ике вертикаль мускулдан гыйбарәт. Уң һәм сул мускуллар үзара ак төстәге юка һәм үтә нык сеңерле мембрана белән тоташкан, шуңа да ул табиблар телендә «ак линия» дип йөртелә. Ул эчнең өске ягында калынрак, ә аска таба тарая, кайчак хәтта булмаска да мөмкин. Әлеге ак линиянең зәгыйфьләнүен һәм юкаруын, нәтиҗәдә, ике мускулны тиешле халәттә тотып тору сәләтен югалтуын корсакның туры мускуллары диастазы дип әйтәләр.

Ешрак ул бала тапкан ханымнарда күзәтелә, чөнки әлеге халәт 50–90 процент очракта йөклелек аркасында килеп чыга.

Корсак куышлыгының алгы як стенкасы җитәрлек өлгереп бетмәгәнлектән, яңа туган сабыйларда, аеруча җитлекми туган балаларда да булырга мөмкин.

Сирәгрәк булса да, корсакның туры мускуллары диастазы бала тапмаган хатын-кызларда һәм ир-атларда да очрый. Бу очракта моңа кешенең тумыштан килгән физиологик үзенчәлекләре сәбәпче була.

Табибларга күбрәк йөклелек аркасында килеп чыкканы белән очрашырга туры килә. Үз тәҗрибәм күрсәткәнчә, ул ешрак корсак тирәсенә май тукымасы тупланган юантык гәүдәле ханымнарда күзәтелә. Какча гәүдәле ханымнарда да булырга мөмкин, ләкин аларда сирәгрәк очрый. Минем практикамда корсакның туры мускуллары диастазы белән пластик хирургка мөрәҗәгать итүчеләрнең 90 проценты – хатын-кызлар, нибары 10 процент кына – ир-атлар.

Әлеге диагнозны хатын-кыз үзе дә бик җиңел ачыклый ала. Аның иң беренче билгесе – никадәр генә тырышсаң да, эч мускулларын катыра алмау. Икенчесе – эчнең уртадан бүлтәеп чыгып торуы; физик күнегүләрнең файдасын күрмәү, прессны ныгытуның нәтиҗәсе сизелмәү. Шулай ук авыр әйберләр күтәргәндә эчтә ниндидер дискомфорт тоелырга мөмкин. Еш кына эчәклекнең эшчәнлеге бозылу, күңел болгану кебек күренешләр күзәтелә. Кайчак бүсер барлыкка килә.

Үзегездә мондый үзгәрешләр сизсәгез, беренче чиратта хирургка күренергә кирәк. Тулы диагнозны һәм аның стадияләрен бары табиб кына билгели ала.

Дәвалау алымнарына килгәндә, без, пластик хирурглар, профилактика һәм физик күнегүләр ярдәмендә дәвалау белән шөгыльләнмибез, андый тәҗрибәбез юк. Бу, беренче чиратта, хатын-кызның йөклелек чорын күзәтүче акушер-гинекологның бурычы. Корсакның туры мускуллары аерылуны булдырмау чараларын, физик күнегүләрне, бандаж ише саклык чараларын ул билгели. Ә инде пациент пластик хирургка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булган очракта, билгеле, операция ясала. Аның да төрле төрләре бар. Һәр очрак индивидуаль, һәм аны пациентның хәлатенә карап, бары табиб кына билгели ала.

Моны белү мөһим

- Корсакның туры мускуллары диастазы күзәтелгәндә эчне ныгытуга юнәлдерелгән физик күнегүләрнең кайбер төрләрен ясаудан тыелырга кирәк. Әйтик, бик популяр булган пресс ныгыту, планка күнегүе, «күпер» ясау бу очракта файда бирмәскә, киресенчә, эчнең туры мускулларына булган басымны гына көчәйтергә мөмкин.
- Бу очракта корсак мускулларын эчкә таба тартып, билгеле бер вакыттан соң җибәрү кебек күнегүләр ясарга киңәш ителә.
- Әлеге диагнозны бала тапкан хатын-кызларга ешрак куялар. Ул ничә бала тудыруга карамый, бәлки, мускулатураның торышына бәйле. Корсакның туры мускуллары диастазы йөклелекнең өченче чорында күпчелек хатын-кызда күзәтелә, әмма бәби тапканнан соң ел дәвамында мускуллар кире үз хәленә кайтырга тиеш. Әгәр бу күзәтелми һәм физик күнегүләр дә булышмый икән, корсак мускулларын тикшертергә кирәк.
- Табиблар фикеренчә, яшьтән физик яктан чыныккан һәм корсак мускулатурасы нык булган хатын-кызларга бу диагноз сирәк куела. Шуның өчен дә иң яхшы профилактика ул – спорт, физик күнегүләр.

«Кышкы чия» пирогы

Кыш уртасында җәйне сагынган бер кичтә суыткычтан катырырга куйган чияне алабыз да, «Кышкы чия» пирогын пешереп, гаилә белән бергәләп мәтрүшкә, кипкән җиләк, карлыган яфраклары кушылган шифалы чәй эчәбез. Ир-атларыбызга багышланган бәйрәм табынына куярга да менә дигән тәмле күчтәнәч! Татлы ризыкны алар да ярата бит. Әлеге тәмле пирогны безгә Гөлнара ХӘМЗИНА әзерләп күрсәтте. Гөлнара – ашханәләр системасында эшли. Чит илләрдә сәяхәт итәргә ярата, аннан төрле ризык рецептларын алып кайта да, үзе эшләгән ашханәдәге менюга кертә. Ә менә «Кышкы чия» пирогы – аның иң яратканы! Әйдәгез, бу пирогны бергәләп әзерләп карыйк!





Кирәк

Камыр өчен:

- 10 г чүпрә;
- чүпрәне күпертер өчен бераз гына сөт;
- 100 г маргарин;
- 1 бал кашыгы шикәр комы;
- 1 данә йомырка;
- бер чеметем тоз;
- чама белән он.

Эчлек өчен:

- 120 г шикәр комы;
- 2 йомырка;
- 100 г каймак;
- 250 г эремчек;
- бер чеметем ванилин.

Пирогның өстен бизәр өчен:

- 350 г катырылган чия;
- 70 мл су;
- 1 кап желатин.



Фото: Анна Арахамия

Эш барышы

■ Чүпрәне сөттә 10–15 минут күпертәбез.

■ Кирәк әйберләрнең барысын бергә кушып, уртача йомшаклыктагы камыр әзерлибез.

■ Эремчек, шикәр, йомырка, каймак, ванилинны бертөрле массага килгәнче блендерда күпертәбез.

■ Уртача зурлыктагы табаны майлап, кырыйларына менеп торырлык итеп камыр җәябез.

■ Камыр өстенә эремчекле эчлекне салып, 160 градуска кадәр кызган духовкага 25 минутка куябыз.

■ Пирог пешкәнче, өске өлешкә куела торган чияләрне әзерли торабыз. Моның өчен катырылган чияләргә су кушабыз һәм кайнап чыкканчы плитә өстендә тотабыз. Кайнап чыгуга, плитәдән алып суын башка савытка агызабыз һәм чияләрне суытырга куябыз. (Чияләрнең төше алдан ук алына.)

■ Желе әзерләү өчен чия пешкән суны кулланабыз. Аңа желатин салып, күпергәнче тотабыз. Шуннан шикәр комы кушып болгатабыз да кайнатып чыгарабыз.

■ Ул арада духовкадагы пирог та пешеп чыга. Аны суытырга алып куябыз.

■ Пирог суынгач, өстенә чияләрне тезәбез һәм тигез итеп желатинлы сироп салабыз.

■ Барысы да әзер булгач, пирогны 3-4 сәгатькә суыткычка куябыз.

■ Чәй янына чыгарганда чияләр өстенә шикәр пудрасы сибеп җибәрәбез. Пирог күз алдында үзгәрә. Әйтерсең лә чияләр өстенә әле генә февраль кары явып узган. Чәйләрегез тәмле булсын!



Дөрес туклanganда баллы ризыктан ваз кичү кирәк тә түгел. Баллыны ашарга ярый һәм ул кирәк тә. Ләкин... алар «дөрес» тәмтом булсын. Чынлыкта, традицион конфетларга бик күп альтернатива бар бит. Шундыйларның берсен Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА тәкъдим итә.

Ногыт борчагыннан... конфетлар



Ногыт борчагы (төрек борчагы) – Урта Азия кузаклыларыннан. Төрек борчагы Россиядә бик киң таралмаган. Ә менә аның составы сыйфат ягыннан гади борчакныкыннан өстенрәк. Нәрсәсе белән файдалы соң ул? Ногыт борчагында бик күп микъдарда витаминнар һәм минераллар бар. Ул безнең йөрәк-кан тамырлары системасына булыша, канны яңарта. Составындагы лизин иммунитетны ныгыта, җәрәхәтләнгән тукымаларның төзәлүен активлаштыра. Ә антиоксидантлар организмны чистарта. Ногыт борчагындагы тимер һәм фолий кислотасы хатын-кызлар өчен аеруча файдалы. Мондый борчакны даими куллансаң, ул катарактаны кисәтә.

Ногыт борчагын сайлауның махсус кагыйдәләре юк: шома, бөтен һәм тапларсыз гына булсын.

Нәрсә әзерлибез? Пешерелгән ногыт борчагыннан котлетлар, фалафель әзерлиләр, ашка, гарнирларга кушалар, элегрәк журналыбызда ул борчактан хумус әзерләргә өйрәткән идек. Бу юлы ногыт борчагыннан... конфет ясыйбыз! Бу конфет – сәламәт туклануны сайлаучыларга менә дигән табыш. Үзе туклыклы, файдалы һәм тәмле.

Кирәк:

- 200 г ногыт борчагы;
- 2 аш кашыгы какао;
- 1 аш кашыгы бал;
- вакланган чикләвек йә кокос.

Фото: www.pixabay.com

■ Башта ногыт борчагын төнгә җебетергә куеп калдырабыз. Җебетелгән борчакны 1 сәгать дәвамында пешерәбез.

■ Пешкән борчакны блендердан йә иттарткычтан үткәрәбез.

■ Килеп чыккан катнашмага какао порошогы, төшсез хөрмә җимеше һәм бал өстибез.

■ Тагын блендердан йә иттарткычтан үткәрәбез.

■ Әлеге массадан кечерәк шарчыклар ясап, аларны чикләвек йә кокос вагында әвәлибез.

■ Бу катнашмага вакланган әфлисун кабыгы да, арахис пастасы да, вакланган күрәгә яки кара җимеш тә кушарга ярый. Анысы сезнең фантазиядән тора.

■ Әзер конфетларны суыткычка куеп суытып алабыз.

Чәйләрегез тәмле булсын!

Кучкар. Сөенечле вакыйгаларга бай ай булыр. Мөмкинлекләрегездән дөрес файдалансагыз, зур уңышларга ирешерсез. Ялкауланмагыз гына! Язмыш сезгә күңелле сюрпризлар әзерли.

Үгезбозау. Акча өчен уңайлы ай. Тик акчаны уңгасулга чәчү, күңел ачулар турында онытырга туры килер. Вак-төяк проблемаларны озакка сузмый гына тиз арада хәл итәргә тырышыгыз.

Игезәкләр. Уңышлы ай башлана. Алда күп ишекләр ачылыр – файдаланып калыгыз. Кеше сүзенә карамыйча, үзегезне тыңлап яшәгез. Карарларны нык лап уйлап кабул итәргә тырышыгыз.

Кысла. Яңа үрләр яулар вакыт җитте! Дусларыгыз кызыклы, акчалы уртак эш тәкъдим итсә, курыкмыйча алыныгыз. Чөнки дусларыгыз авыр чакта ташлап калдырмас, ә сезнең аларга карата ышанычыгыз тагын да артыр.

Арыслан. Йолдызлар сезгә ерак сәфәр вәгъдә итә. Авыр уйлардан арынып, тынычланып кайтырсыз. Рәхәтләнеп ял итегез, күптән барлап куйган китапларны укырга җай табыгыз. Бу сезнең тынычлану, хәл җыю вакыты.

Сөмбелә. Моңа кадәр яшеренеп яткан энергиягез тышка бәреп чыгар. Яңа идеяләр белән илһамланырсыз, һәрвакыт игътибар үзәгендә булырсыз. Якыннарыгыз турында да онытмагыз, аларның да сезнең җылылыкны тоясы килә.

Үлчәү. Хис-тойгылар дулкынына күчеп, сөю утында янарсыз. Тик башыгызны югалтмагыз, алда сезне мөһим эшләр көтә! Нәтиҗәсе куандырырлык булыр. Гайбәтләргә колак салып, күңелегезне төшермәгез, алар сезгә зыян сала алмас.

Чаян. Дөреслек өчен көрәшергә туры килер. Хаклык сезнең якта булыр, шуны онытмагыз. Эмоцияләргә бирелеп, эшегездә дә проблемалар килеп чыгарга мөмкин. Проблемага ничек карасагыз – нәтиҗәсе дә шундый булыр.

Укчы. Ялгыз Укчыларның үз парын очрату мөмкинлеге бар. Күңел тынычлыгын сакларга тырышыгыз. Финанс ягыннан тотрыклылык килер. Сәламәтлеккә игътибарны арттыру комачауламас.

Кәҗәмөгез. Уйлап йөргән идеяләрегезне тормышка ашырырга тырышыгыз. Күтәренке кәеф тормышыгызга да, эшегезгә дә уңай тәэсир итәчәк. Күңелегезгә якын кешеләр белән күбрәк аралашыгыз.

Сукояр. Мөнәсәбәтләрдә ихласлык саклагыз, хисләрегезне белдерүдән курыкмагыз. Якын кешегезнең күңелен күрегез, бүләкләр бирегез. Житәкчегез белән низаг килеп чыгарга мөмкин, шуңа сабыр һәм тыныч булырга тырышыгыз.

Балык. Киләчәккә кыю атлагыз: мөһим карарлар кабул итү вакыты килеп җитте. Бәлки, сезгә эшегез, яшәү рәвешегез туры килмидер? Шуңа күрә тормышыгызда булачак үзгәрешләргә әзер торыгыз.

тест

ГАИЛӘГЕЗНЕҢ ХӘЛЕ НИЧЕК?

Түбәндәге сорауларга «әйе» дип җавап бирсәгез – **«+»**, «юк» дип җавап бирсәгез – **«–»** куеп чыгыгыз. Җавапларны астагы «ачкыч» белән чагыштырып чыгыгыз.

1. Минем кәефем күбрәк өйдә бозыла.
2. Гади генә вак-төяк тә безнең гаиләдә ызгыш чыгара.
3. Күңелсезлекләр килеп чыкса, үземне яклаучысыз хис итәм.
4. Ялгыз булуга караганда, тормыш иптәшем белән бергәләп ял итәргә яратам.
5. Иремә үз эшләрем турында сөйләргә яратмыйм.
6. Миңа авыр чакларда ул аеруча игътибарлы.
7. Иремнән бервакытта да күңелгә тиярлек авыр сүз ишеткәнем юк.
8. Иремне кайгырту миңа бик ошый.
9. Туйдан соң ир белән хатынның мәхәббәте сүнә.
10. Мин – иремнең иркә хатыны.
11. Безнең ызгышулар матур итеп дуслашу белән тәмамлана.
12. Һәр елны туй көнебезне билгеләп үтәбез.
13. Авыр чакларымда иремә сыена алам.
14. Иремнең дуслары да миңа ошый.
15. Минем кайгыртуларга иремнең исе китми.
16. Дусларым белән иремнән башка гына очрашырга яратам.
17. Ирем минем эш урынымны бәяләми.
18. Башкаларның гамәлләрен бәялəгәндә ирем белән бертөрле фикер йөртәбез.
19. Безнең уртак кызыксынуларыбыз күп.
20. Иремә ошамаганын белсәм дә, үземнең гадәтләремне үзгәртергә җыенмыйм.
21. Миңа калса, хокукларыма караганда, гаиләдә бурычларым күбрәк.
22. Гаилә минем ирегемне кыса.
23. Ирләргә юл куярга ярамый, бу хатын-кызны түбәнсетә.
24. Көнкүреш проблемаларын үземә генә чишәргә туры килә.
25. Гаиләгә шулкадәр вакыт һәм көч китәр дип уйламаган идем!
26. Интим мөнәсәбәтләр – бәхәстән соң дуслашу этабы...
27. Иремнең кәефе белән исәпләшмичә ярамый!
28. Үземнең начар кәефемне өйдә күрсәтмәскә тырышам.
29. Әгәр гаилә тормышы башта ук килеп чыкмый икән – аерылышу хәерлерәк.
30. Ирем мине башкаларга караганда әйбәтрәк аңлый.

«Ачкыч»: «+» – 4, 6–8, 10–14, 18, 19, 26–28, 30;
«–» – 1–3, 5, 9, 15–17, 20–25, 29.

«Ачкыч» белән тәңгәл килгән һәр җавапка 1 балл куегыз да, нәтиҗәләрне укып карагыз.

0–6 балл. Гаиләгез таркалу чигендә. Нәрсәнедер бергәләп үзгәртергә тырышканда гына гаилә бәхетен саклап калырга мөмкин.

7–14 балл. Вакыт-вакыт мөнәсәбәтләрдә киеренкелекләр булса да, бер-берегезгә булган хөрмәт, юл куя белү – мөнәсәбәтләргә очкын салып, ялкынландырып җибәрә ала әле.

15–24 балл. Гаиләдәге мөнәсәбәтләр – югары дәрәҗәдә, сез позитив атмосферада яшисез. Бәхәсләр чыкса да, аларны чишү юлларын бергәләп таба беләсез. Сез – бик матур гаилә үрнәге.

25–30 балл. Сезне иң бәхетле гаилә дип атарга була!

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Раилә ХӘЯЛИЕВА әзерләде.







ТӨСЛӘР ҖЫРЫ

«Син музыкант. Картиналарыңнан үзенә бер көй агыла», – диләр аңа. Һәм бу чынлап та шулай! Рәссам Фәрит Суюров тамашачыны картиналарының тәмам эченә алып кереп китә белә. Шыгырдавык кар сукмакларыннан атлап киткәндәй буласың, ерактан күгелҗемләнеп күренгән урман ешлыгына кереп югаласың, агач яфракларын лепердәткән җил тавышына колак саласың, су, үлән исен тоеп рәхәтлек кичерәсең... Аны лирик картиналар, шәһәр пейзажлары остасы дип йөртәләр. Картиналары нигезендә натурадан ясалган этюдлар ята. Идел, Кама буйлары, Илет, Мишә, Нократ елгалары, Мари урманнары, Казанның борынгы урамнары, Габдулла Тукай тормышы һәм иҗаты белән бәйле урыннар, мәчетләр... Туган як табигате әнә шулай илһамландыра аны. Барысы да таныш, күз ияләшкән күңелгә якын урыннар... Ул аларны тасвирлап кына калмый, шулар аша тирән кичерешләрне дә бирә. «Идел симфониясе», мәсәлән, Идел пейзажы сериясенә карый. Бөек елганың җиде төсмере, җиде халәте төрле вакытларда, төрле урыннарда, төрле төсләрдә чагылып, нәфис сагыштан ашкынулы бер дулкынга күчә – Иделнең тулы бер образы белән очрашасың.

Эри башлаган карга җиңелчә зәңгәрсу һәм шәмәхә күләгәләр төшкән. Язгы рәшә бакчаларны куе томанга төргән, тирә-юньгә эңгер-меңгер иңгән. Шул тынлыкта тыйнак бакча өйләре оеп утыра... Кемдер инде көпшәк карда сукмак салып өлгергән... Монысы – «Март».

Тыныч кич, энҗедәй җемелдәгән күк йөзе иртәгә көзге матур көн вәгъдә итә. Кояшның җылы нурлары су өстендә уйнаклый, алтындай ялтырый. Тирә-якта тынлык, җан рәхәте, шул ук вакытта бераз моңсу да. Мондый тымызык кичләр күпләргә таныш. Салкын һәм җылы төсләрне тыгыз гармониядә кулланып, хисләрен менә шундый колоритта бирә белә рәссам. Ул гадәттә акварель, майлы буяулар, пастель кулланып эшли.


Фәрит Суюров картиналарындагы җылылык, шигърилектә тамашачы аның холкын да үтәли күрә сыман: йомшак күңелле, лирик җанлы, тирән кичерешле рәссам ул! Пейзажлар остасы булуы, табигатьне бөтен барлыгы белән тасвирлап бирү сәләте исә балачактан ук килә. Биек Идел ярлары, Казансу тугайлары кечкенә Фәрит күңеленә матур сурәт булып төшә бара...

5-6 яшьтән рәсем ясап, мәктәптә укыганда плакатлар эшләп йөргән егет урта мәктәптән соң сынлы сәнгать училищесына укырга керә. Зәйдә, Казан мәктәпләрендә укыта. Аннары Чабаксар пединститутының графика факультетында белем ала. 5 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбен җитәкләү, Н. И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы, Татарстан Сәнгать фонды директоры булу Фәрит Суюровның зур педагогик тәҗрибәсе турында сөйли. Картиналары Россиядә генә түгел, Төркия, Голландия, Бөекбритания, Финляндия галереяларында саклана.

Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Бакый Урманче исемендәге премия лауреаты, Россия сәнгать академиясенең алтын медаль иясе Фәрит Суюров картиналары күргәзмәсе дә тикмәгә генә «Туган җирем Татарстан» дип аталмаган. Үзе инде арабызда булмаса да, Суюровның иҗади мирасы тамашачыны сокландыруын дәвам итә.

Эльмира ЗАКИРОВА












Фото: Елена Сунгатова

ФӘРИТ СУЮРОВ

ТАССР

Празднование 100-летия Татарской АССР

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү

1920-2020



Илдус ДӘҮЛӘТОВ,
Оренбург өлкәсенең
Законнар чыгару җыелышы
депутаты,
Оренбург өлкәсенең
Татар милли-мәдәни
мохтарияте рәисе

Кайтабыз сиңа, кайтабыз, Казан,
Учак янына җыелган сыман...

Бу җыр юллары йөрәкләребездәге хисләрне ача да сала инде! Гомер-гомергә Казанга, Татарстанга тартылдык. Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының 100 еллык бәйрәме Оренбург татарлары өчен дә зур вакыйга. Урал якларыннан, Кенәле, Сакмар, Җаек буйларыннан, атаклы Әсәкәй, Татар Каргалысы, Абдулин, Богырыслан, Илек, Саракташ, Шарлыклардан сәлам юллап, милләтебезнең Оренбургтан чыккан асыл улларын искә төшерәм. Батырлык символына әйләнгән Герой-шагыйрь Муса Җәлил... Әдәбиятыбыз, театр сәнгатебез тарихында тирән эз калдырган Мирхәйдәр Фәйзи, Хәлил Әбҗәлиловлар... Йөз еллык республика тарихында аларның исемнәре дә лаеклы урын алып тора! Татарстан Республикасын торгызуның һәм үстерүнең мөһим тарихи этабында алар шулай ук үзләреннән зур өлеш керткән. ТАССР оешуның 100 еллык юбилее уңаеннан Оренбург шәһәр-авылларында, мәдәният йортларында, мәктәпләрдә төрле форумнар, конференцияләр, бәйрәм чаралары уздырыла. Без бу олы вакыйганы горурланып каршылыйбыз!

